Безнең МИРАС

10

октябрь 2014

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ



Үткәннәргә кайтып барышыбыз...

Солтан Исхаков фотолары

25 СЕНТЯБРЬДӘ, ХӘТЕР КӨНЕ АЛДЫННАН, «ТАТМЕДИА» ААҖ БАШЛАНГЫЧЫ БЕЛӘН, БЕР ТӨРКЕМ ЖУРНАЛИСТЛАР ҺӘМ ГАЛИМНӘР БАЛЫК БИСТӘСЕ РАЙОНЫНДАГЫ БОРЫНГЫ ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЛЕГЕНӘ ГАМЬЛЕ СӘФӘРГӘ ЧЫКТЫ.

(Бу хакта журналыбызның киләсе санында галим Фаяз Хуҗинның тәфсилле язмасы дөнья күрәчәк.)

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнең МИРАС 12 +
10(33)
октябрь 2014

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

48

29 **СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ.** *Габделбарый Баттал*

108 **МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ.** *Адлер Тимергалин*

ЭЧТӘЛЕК

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

3 Хәтере барның — әйтере бар!

КАЗАН — ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ 2014 ЕЛДА МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ

4 **Рәештәге рәвеш.** *Ркаил Зәйдулла*

ТАРИХИ МИРАС

10 **Уртак мирас.** *Фәйзелхак Ислаев*
18 **Сөенбикәне сагыну.** *Һади Атласи*
20 **Хәтер көне байрагы.** *Мәсгуд Гайнетдин*
22 **Төрек вә татар тарихы.** *Йосыф Акчура*
29 **Сөембикә манарасы.** *Габделбарый Баттал*
40 **Г.Батталның «Сөембикә манарасы» хезмәте хакында.** *Җәүдәт Миңнуллин*
43 **Мишәрләр.** *Зариф Бәшири*
48 **«Сугышта вәйран була газиз башлар...»** *Раиф Мәрданов*

ДИНИ МИРАС

58 **Көтебе ситтә вә мөәллифләре.** *Ризаэддин бине Фәхреддин*

ҖИҢҮ — 70!

62 **Беренче гвардиячеләр.** *Шаһинур Мостафин*
65 **Бабаларым, әбиләрем...** *Алмаз Хәмзин*
69 **Дәһшәтле еллар хатлары.** *Әлфия Шамова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

74 **Сүз һәм сурәт.** *Газинур Морат*

ӘДӘБИ МИРАС

76 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
80 **Солдат.** *Гаяз Исхакый*
88 **Язмыш йөртә кешене.** *Тәлгат Галиуллин*

93 **Ачы тәҗрибә авазы.** *Габдулла Тукай*
96 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*

ХӘТЕР САГЫНДА

98 **Милли музей хәзинәләре.** *Руфия Мөхетдинова*
100 **Кыштым афәте.** *Александр Филиппов*

ТАБИГЫЙ МИРАС

106 **Акташ упкыны**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

108 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

100 ЕЛ ЭЛЕК

112 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның октябрь ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Көлке куа килә...**

119 **Мирасворд**

120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Октябрь*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закир
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Ирек Миннәхмәтов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Техник хезмәткәр
Данил Салихов
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №А-2554. **Тираж** – 1548 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 1.10.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Солтан Исхаков, Ленар Гобәйдуллин төшергән һәм Абдулла Дубин, авторларның архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә – «Чистай шәһәре урамы». Кәгазь, акварель. 2011. *Э.Мостафина рәсеме.*

ХӘТЕРЕ БАРНЫҢ — ӘЙТЕРЕ БАР!

Милләтнең бәхетсезлеге — хәтерсезлектә.

***

Тарихка кайту — кунакка кайту түгел ул.

***

Юлдашың елак булса, юлың ерак булыр.

***

«Милләт! Милләт!» дип кычкырудан гына милләтнең хәле яхшырмый.

***

Хәтта тәхеттәге бәхетнең дә гомере ләхет белән чикләнә.

***

Тукайдан ераклашкан саен, без Тукайга якынаябыз.

***

Җиңү көне — кемнәргәдер Олы Шатлык булса, берәүләргә — Авыр Кайгы ул.

***

Кешене үткәнгә хәтере алып кайта.

***

Тишек хәтерне ямап булмый.

***

Күңелемнән хәтер очырдым — үрсәләнеп сагыш кычкырды.

***

Үткәнемә карасам, киләчәгем күз алдыма килә.

***

Авыру илдә сәламәт яшәп булмый.

***

Манкорт татарга кытайча белү мәҗбүри түгел.

***

Хәтере барның — әйтере бар! Мин әйттем!



РӘЕШТӘГЕ РӘВЕШ

Ркаил Зәйдулла

Әдәби багланышларның әһәмиятен кем генә инкяр итәр икән? Бигрәк тә без – төрки телле әдәбиятларның вәкилләре, кан кардәшләр, даими аралашып, үзара киңәш-табыш итеп яшәргә тиеш. Бүгенге глобальләштерү заманында төрки халыкларга әдәби багланышлар гына түгел, ә бәлки үзара мәдәни берегү дә кирәк.

Чөнки һәркемгә мәгълүм, «глобальләштерү» дигәндә, кешелек белән идарә итүчеләр төрки дөньяның берләшүен, геосәяси дөньяда аның үзенә лаек урын биләвен һич тә күздә тотмый. Бердәм Төрк дөньясын хасил иткәндә генә татар милләте дә, үзенең мәдәниятен, телен-денен саклаган хәлдә, киләчәккә өмет итә ала. Төрле мәдәниятләр диалогы, халыклар дуслыгы, толерантлык хакында күпме генә сөйләмик — әлбәттә, болар шушы нәни генә планетада исән калуның, кешечә яшәүнең алшарты булып тора! — тарихка күз салсак, ул төрле мәдәниятләрнең өзлексез көрәшеннән гыйбарәт. Һәркем үз мәдәниятенең җиңеп чыгуын тели. Көчсезләр, иртәме-соңмы, тарих сәхнәсеннән төшеп кала. Безгә көчле булырга кирәк. Һәм бу көрәштә бер тамырдан шыткан тугандаш халыклар бер сафта атламаса, мәдәни аралашмаса, гайре табигый булыр иде. Хәер, без «пантюркизм» карачкысы белән куркыткан заманнарны да хәтерлибез. Билгеле,

Төрки телдәге әдәби журнал мөхәррирләре Муса Җәлил һәйкәленә чәчәк сала

Изге Болгар җирендә. Сулда – Якуб Омәроглы

Изге Болгарга юл тотучы мосафирлар хөрмәтенә Фатих Кутлу җыр суза

Шигърият анда чын-чынлап халык эше, шигырь язучы теләсә кем бәйрәмгә катнашып китә ала, «кем соң бу, моңарчы күренмәде?» – дип сорасаң, «халык шагыйре!» – диләр, дөрес бит! Шагыйрь халык арасыннан килеп керә, халык авазын җиткерә.

үз-үзеңне юатырга була: көрәштә өстен калган мәдәният, һичшиксез, җиңелүче хисабына да байый, берни дә эзсез-нисез юкка чыкмый. Без бит еш кына татар чыгышлы дип урысның күп кенә бөек язучылары, мәдәният эшлеклеләре белән дә горурланырга яратабыз. Толерантлык дигәннәре — җиңелгәннәрнең юанычы ул, һәм шактый ук көпшәк таяныч. Көчле булсаң гына, киң күңелле булу рәхәт.

Төрки телле журнал мөхәррирләренең, язучыларның август ахырында Казанда үткән җыены шушы бәйләныш җәһәтеннән күркәм адым булды. Андый форумнар Төркиядә еш үтә. Татарстанның да, хуҗа булып, бу эшкә алынуына сөенмичә мөмкин түгел. Әлеге җыенның мондый эшчәнлектән шактый читтә торучы **«ТАТМЕДИА»** җәмгыятенең җитәкчелегендә үтүе дә шактый гыйбрәтле булды. Әлбәттә, Татарстан хөкүмәтенең химаясен дә онытмаска кирәк. 2014 елда Казанның халыкара **«ТҮРКСОЙ»** тарафыннан төрки дөньяда мәдәният башкаласы,

Якуб Омәроглы Сөмбел Таишевага истәлек бүләге тапшыра

дип игълан ителүе дә этәргеч булгандыр. Шунысын да әйтергә кирәк: мондый эшләрдә җаваплылыкны аерым кешеләрнең үз өстенә алуы мәслихәт. Безнең яктан «ТАТМЕДИА» ААҖнең генераль директоры урынбасары **Сөмбел Таишеваның** һәм Төркиядән Ауразия язучылары берлеге рәисе **Якуб Омәроглының** бу җыенны үткәрүгә көч кызганмауларын әйтеп китү фарыз.

Әдәбиятны милли фикерләүнең югары бер формасы дип танысак, ул мөмкин кадәр күбрәк бәйсезлек, мөстәкыйльлек таләп итә. Татар әдәбияты һәм тагын күп кенә төрки әдәбиятлар озак гасырлар дәвамында андый бәйсезлеккә, иркенлеккә ия була алмады. Алай гына да түгел, «төрки әдәбиятлар» үзләре үк бәйлелекнең, үз язмышыбызга үзебез хуҗа булмауның нәтиҗәсе түгелме соң? Урта гасырларда бит «төрки әдәбиятлар» дигән төшенчә бөтенләй юк. Фәкать бербөтен төрки әдәбиятны гына белгәннәр. Биш-алты еллар элек Төркиядә төрки әдәбиятларның антологиясе чыккан иде. Анда безнең әдәбиятларның тарихын, кайберләренең хәтта XX гасырга кадәр, бер үк авторлар, бер үк әсәрләр тәшкил итә.

Моннан өч йөз ел элек Казан шагыйре **Габди** болай язган:

Әрәешкә кием кимә,
Башка кимә яхшы бүрки.
Мескен Габди барчадин ким,
Шәһре — Казан, теле — төрки.

Бу гасырда түрк халыкларының кимсенеп яшәү дәвере тәмамлансын иде. Рәешкә киенеп, рәвешләнеп, менә шулай бергә җыелуыбыз зур мәгънәгә ия. «Яхшы бүрки» безнең әсәрләребез булырга тиеш. Язучыларның үзара танышулары, иш янына куш булулары, ахыр чиктә әдәбиятларның да якынаюына юл ача.

Төрки әдәбиятларның үзара берегүе, һич булмаса, якынаюы хакында безгә кадәр дә хыялланганнар. **Исмәгыйль бәк Гаспралы** хәтта уртак **«Тәрҗеман»** телен дә тәкъдим итеп караган. Уртак бер дәүләт булган очракта, ул бәлки тормышка да ашкан булыр иде. Ул чакта да зыялылар «Тәрҗеман» телендә аралашуның, уку-язуның бер кыенлыгын да күрмәгән. Әлеге газетаны Кырымда да укыганнар, Үзәк Азиядә һәм Госманлылар дәүләтендә дә алдырганнар, Идел-Урал буйларында да ул күп таралган. Ләкин уртак бер әдәби тел, уртак әдәбият идеясен XX гасырда башланган сәяси, социаль үзгәрешләр, катаклизмнар юкка чыгара. Дөрес, сәбәпне тирәннәнрәк тә эзләргә кирәктер. Ни

Кыргызстан Язучылар берлеге рәисе Омар Солтановның (уңда) олпат галимебез Хатыйп Миңнегуловка әйтер сүзләре күп

генә әйтмә, әдәбият гади халык арсыннан шытып чыга, ул асылы белән демократик; аны тукландырып, сугарып торучы да — гади халык үзе. Һәм кулланучысы да... Ике мең еллар элек үк, бик зур территорияләрне биләү сәбәпле, төрк теле берничә тармакка бүленгән. Вакытлар үтү белән шактый ук аерма да пәйда булган. Бүгенге чынбарлыктан чыгып караганда, ниндидер ясалма бер уртак телне гамәлгә кую мөмкин булса да, ул барлык төрки илләргә тарала алмас иде. Күп сәбәпләрне искә алмаганда, безнең бит һәрберебез үзен бөек саный, һәркем үз туган телен камилрәк, баерак дип ышана. Аннары күптән түгел бәйсезлек алган төрки илләрдә үз телләрен, шул илгә исем биргән телне үстерү милли идея булып тора. Безгә исә, татарларга, элекке амбицияләрне читкә куеп, телебездән бөтенләй язмау хакында кайгыртырга кирәк. Зыялыларга үзара аралашканда уртак тел итеп хәзерге төрек телендә аралашырга мөмкин. Хәер, без, кыпчак теллеләр, бер-беребезне арадашчысыз да төшенәбез.

Төркиядәге кардәшләребезнең төрки телле мәдәниятләрне аралаштыруда, якынайтуда башкарган гамәлләрен биредә тәшәккүрләр әйтеп искә алу зарур. Анда һәр елны байтак шәһәрдә Халыкара төрк шигърияте көннәре, сәнгать форумнары үтә. Мин үзем дә ун ел элек **Илазы** шәһәрендә, күптән түгел **Токатта** булган шундый шигырь бәйрәмнәрендә катнаштым. Төркиядә шигъриятькә булган ихтирамлы мөнәсәбәткә сокланмый мөмкин түгел. Мондый форумнар анда югары кимәлдә — вәлиләр (губернаторлар), шәһәр башканнары катнашында үтә, бик күп очрашулар була, кайберләрендә хәтта шәһәр урамнары буйлап шигъри йөрешләр оештыралар. Шигърият анда — чын-чынлап халык эше, шигырь язучы теләсә кем бәйрәмгә катнашып китә ала, «кем соң бу, моңарчы күренмәде?» дип сорасаң, «халык шагыйре!» диләр, дөрес бит! Шагыйрь халык арасыннан килеп керә, халык авазын җиткерә. Анда йөзләрчә (меңнәрчә булмаса әле) шигырь китаплары, журналлар чыга, йөзләгән хосусый нәшриятлар эшли. Шагыйрьләр атна саен тәгаенләнгән бер бинага җыела. **Каһраман Мараш** шәһәрендә «Шагыйрьләр өе» дип аталган йорт та бар хәтта. Анда **Марсель Галиев** белән иллеләп шагыйрь каршында чыгыш та ясаган идек. Соңыннан алар да кимен куймады. Очрашу биш сәгатькә якын барды. Үзләре Марашны, үзе дә шунда

туган Фатих Кутлуның әйтүенә караганда, «шагыйрьләр шәһәре» дип атыйлар икән.

Бездәге берәр «белгеч», мәгънәле елмаеп: «Ә хөкүмәтнең ярдәме бармы?» — дип сорар. Хөкүмәтнең химаясеннән башка андый халыкара форумнар үткәреп булмый, билгеле. Ләкин анда бездә булмаган тагын да мөһим институт бар — вакыфлар. Төркиядә, бигрәк тә **Анадолуда**, динле халык яши, һәммәсе зәкәт бирә һәм аны асылда шул вакыфларга илтә.Дини вакыфлар, мәдәни вакыфлар... Октябрь фетнәсенә кадәр татар мәгарифе, татар мәдәнияте дә байларның зәкәтенә бәйле булуын онытмыйк. Ә халык шагыйрьләренә хөкүмәт ярдәме нигә? Алар шул килеш тә халыкныкы — укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре. Шигырь исә аларның табигатеннән килә.

дә Казан матбугатында ешрак нәшер итәргә тиеш, билгеле. Бу эш күпмедер башкарыла да... Төркиядә байтак татар баласы белем алып кайтты. Хәзер төрекчәдән татарчага аударучыларны табуы читен түгел. Эш бары тик фидакярлеккә һәм акчага барып терәлә.

Егерменче йөзнең башына кадәр һәр татар зыялысы төрек телендә мөкәммәл белсә дә, аннан соңгы чорда аралар суынып (махсус суытканнар: күпме әдәбият-сәнгать эшлеклесе «төрек шпионы» булуда гаепләнеп харап булган, патша властеның төшенә дә кермәгән мөмкинлекләр!), без бүген дә әлегә тел җәһәтеннән ярлы, без арадашчыларга, ягъни тәрҗемәчеләргә мохтаҗ. Шушы җаваплы эшне Татарстанда **Фатих Кутлу** үз өстенә алды. Соңгы елларда төрек теленә ул шактый гына чәчмә әсәрләр тәрҗемә итте, алар Төркиядә

Төркиядә, бигрәк тә Анадолуда, динле халык яши, һәммәсе зәкәт бирә һәм аны асылда шул вакыфларга илтә.Дини вакыфлар, мәдәни вакыфлар... Октябрь фетнәсенә кадәр татар мәгарифе, татар мәдәнияте дә байларның зәкәтенә бәйле булуын онытмыйк.

Казандагы җыенга Якуб Өмәроглы **«Каләмдәшләр»** дигән портал тәкъдим итте. Әлеге порталга төрки телләрдә чыккан төп әдәби журналларның электрон варианты куелачак, андагы әсәрләр башка төрки телләргә дә тәрҗемә ителәчәк. Бу гамәл безнең багланышларны тагын да ныгытачак, билгеле.

Али Акбаш мөдирлегендә нәшер ителгән **«Кардәш каләмнәр»** журналын да бу җәһәттән искә алырга кирәк. Инде ничә еллар анда төрле төрки халыкларның әдәбияты лаеклы урынын ала. Шул исәптән күп кенә татар шагыйрьләренең, язучыларының да әсәрләре биредә дөнья күрде. Ә **Габдулла Тукайга** багышлап алар махсус сан чыгарганнар иде.

«Кунак ашы — кара-каршы», ди безнең халык. Диңгезгә тиң төрек әдәбиятының гүзәл үрнәкләрен без биш китап булып нәшер ителде. Балалар өчен язылган татар хикәяләрен туплап чыгарган китабы белән әле күптән түгел генә **Албаниянең** бер нәшрияты кызыксынган. Димәк, иң яхшы татар әсәрләрен төрек телендә нәшер итү ул зур дөньяга чыгу юлында бер мөмкинлек тә икән.

Урыс шагыйре **Василий Жуковский** (бу урында әнисенең төрек булуын да әйтеп үтәсе килә) проза әсәрен тәрҗемә итүчене авторның иптәше дип атаса, шигырь тәрҗемәчесен авторның көндәшенә тиңләгән. Безнең инде Фатих Кутлу дигән иптәшебез бар, киләчәктә көндәшне табасы гына калды.

Совет чорында шушы илдә яшәгән төрки халыкларның язучылары үзара барышып, әдәби әсәрләрне азмы-күпме тәрҗемә итешеп яшәсә дә, империя таркалгач, бу багланышлар кинәт өзелде. Ләкин бер генә әдәбият та аерым-аерым

«Йолдыз» журналының баш мөхәррире, кырым-татар шагыйре Диләвер Осман чыгыш ясый

яши алмый. Дөрес, һәр әдәбиятның үз хәле хәл, кимәл дә, мөмкинлекләр дә төрлечә. Ләкин көчлерәк әдәбиятның йогынтысын кичерергә туры килгәндә дә, һәркем аны үз казанында кайнатып, үзләштереп кабул итә. Төрки әдәбиятларга бу юлны Тәңребез үзе кушкан. Аралашып, бер-беребезне баетканда гына без тарихыбызга, мәдәниятебезгә лаек әсәрләр яза алырбыз.

Якынаюның төрле юллары бар. Мәсәлән, татар әдәбияты белән башкорт әдәбияты тагын ничек якыная ала? Егерме ел элек Татарстан һәм Башкортстан дәүләт нәшриятлары **«Кардәшлек киштәсе»** дигән серия булдырган иде. Алар татарчадан, без башкортчадан аударып, дистәләрчә китап чыккан. Игелекле эш дәвам итә. Бәлки XX гасырда иҗат ителгән татар-башкорт шигърияте антологиясен нәшер итәргә дә вакыт җиткәндер. XX гасыр дим, чөнки аңарчы безнең әдәбият татарга, башкортка аерылмаган.

Тугандаш халыкларның шигъри энҗеләрен газиз телебезгә тәрҗемә итүдә фидакярләрчә эшләгән күренекле шагыйребез **Рәдиф Гаташны** бу язмамда искә алмасам, язык булыр. Ул бөек казах шагыйре **Магҗанның** китабын төзеп чыгарды (тәрҗемәләрнең дә күбесе аныкы), бөек үзбәк **Чулпанның** китабын татарчага тәрҗемә итте.

Минемчә, телләре нык якын булган нугай, кумык, карачай-балкар, кырым-татар әсәрләрен үзебезчә чыгару безгә зур кыенлык тудырмый, татар телен яхшы белгән һәр язучы, шагыйрь бу эшне башкара ала. Хәзерге татар әдәби телен баету ягыннан да моның әһәмияте зур булыр иде.

Бер-беребезне өйрәнү, бер-беребезгә якынаю юлында төрле ысуллардан файдаланырга кирәк. Мәсәлән, Испания тарафыннан иң яхшы дип табылган испан телле әсәр авторына ел саен халыкара **Сервантес премиясе** тапшырыла. Ауразия язучылары берлегенең иң яхшы төрки хикәяләр ярышы үткәрүе, җиңүчеләргә **Мәхмүт Кашгарый** исемендәге премия бирү турындагы белдерүен без шундый юлда бер адым дип кабул иттек. Киләчәктә бу мәсьәлә төрки дәүләтләр кимәленә күтәрелсә, төрки әдәбиятларның да дәрәҗәсе бермә-бер артыр иде.

Йөзебез төрле булса да, үзебез бер булыйк. ■

Фәйзелхак Ислаев,
тарих фәннәре докторы

УРТАК МИРАС

Меңьеллык тарихлы татар халкының мирасы искиткеч бай һәм күпкырлы. Республикабызда гына да рәсми рәвештә мең ярым тирәсе тарихи һәм мәдәни ядкяр (һәйкәл) теркәлгән, ә теркәлмәгәнен Аллаһ үзе генә белә. Талантлы халкыбыз күп гасырлар дәвамында бик бай матди һәм рухи мирас туплаган.

Дәүләтчелеген югалткан милләт булуга да карамастан, тарихи-мәдәни мирасны туплау, аны фәнни өйрәнү һәм халыкка җиткерү өчен хәл кадәри эшләр эшләнгән һәм ул хәзер дә эшләнә. Тик шулай да тарихи-мәдәни мирасны барлау, аны фәнни өйрәнү, һәрдаим пропагандалау, бигрәк тә татар халкында тарихи аң формалаштыру буенча эшлисе эшләр, кыласы гамәлләр — әйтеп бетергесез.

Галим-голәмә һәм дә җәмәгатьчелек тарафыннан ярдәмгә мохтаҗ тарихи мирасыбызның бер тармагы — татар тамгалары. Моннан йөз ел чамасы элек, әле XX гасыр башында гына да татар халкын ифрат үзенчәлекле, үзенә генә хас сурәтле тамгалардан аерып күз алдына китереп тә булмас иде. Тамгалар, менә шушы йөз ел эчендә, өч буын яшәү дәверендә, халыкка күп еллар кирәкле хезмәт күрсәткәннән соң, тормышта кулланылмыйча, юкка да чыкты. Әлбәттә, тарихта бик күп нәрсәләрнең дөньяга тууы, яшәве һәм юкка чыгуы мәгълүм. Мондый аяныч хәлне мәдәният, мәгърифәт казанышлары белән аңлатып була булуын, тик шулай да халык мирасының аерылгысыз бер өлешен мәңгегә югалту моңсуландыра… Ә кызыксынган кеше тамгаларны архив киштәләрендә тузанланып яткан язмаларда, борынгы тәңкәләрдә, музей экспонатлары булып хезмәт иткән борынгы әйберләрдә, чигү үрнәкләрендә, зиратта сакланган кабер ташларында, яисә агач казыкларда очрата ала. Кызганыч, хәзерге заман кешесе тамга сурәтенә бөтенләй игътибар итми диярлек. Күп очракларда ул аңа кытай-япон иероглифларына охшаган аңлаешсыз сурәт, символ итеп кенә карый.

Ә бит башка милләтләрнең шактые тамгаларны кабатланмас тарихи-мәдәни мирас итеп кабул итә һәм аларны фәнни өйрәнү буенча системалы эш тә алып бара. Кардәш төрки халыклардан — кырым татарлары, башкорт, казах, нугай, чуваш галимнәре — тамгаларны махсус өйрәнәләр, төрле фәнни хезмәтләрдә еш файдаланалар. Тамгалар белән Кавказ халыклары да шактый кызыксына. Бу яктан татар тамгалары бөтенләй фән дөньясыннан читтә кала, дисәк тә дөрес булыр сыман. Сәбәбе — аның төрлечә, тик менә үзеңне артык мәгърифәтле, укымышлы халык итеп күрсәтергә теләү шундый аяныч нәтиҗәгә дә китерә икән. Татар тамгаларына багышланган махсус фәнни хезмәт бүгенге көнгә кадәр язылмаган. Моннан файдаланып, кайбер китап-язмаларда татарның үзенчәлекле мирасы булган тамгаларны башка халыкларныкы итеп күрсәтү очраклары да бар. Татар мирасын башкаларның үзләштерүе яхшы күренеш булмаса да, без аның белән ризалашырга мәҗбүрбез, чөнки биредә үзебезнең дә гаеп зур.

Шулай да, тамгалар хакында азмы-күпме мәгълүматны тарихчылардан **Һарун Йосыпов, Миркасыйм Госманов, Вахит Хаков, Дамир Гарифуллин, Дамир Исхаков, Әлфирә Сөнгатуллина, Геннадий Макаров** һәм башкаларның хезмәтләреннән табарга була. Тик бу хакта газета-журналларда мәкаләләр бик сирәк басыла. Шушы кимчелекне искә алып, бу язмада татар тамгалары хакындагы кайбер иң мөһим мәгълүматлар махсус әзерләнде. Тамгалар — безнең ифрат та үзенчәлекле,

борынгы, ләкин онытылган ядкяребез икәнен һәр кеше белергә тиеш, дип уйлыйм. Бәлки укучылар, яшь галимнәр арасында татар тарихының шушы үзенчәлекле тармагын өйрәнүне фәнни эш юнәлеше итеп алучылар да табылыр, ә шәхсән үзем исә хәл кадәри бу өлкәдә тупланган тәҗрибәм белән уртаклашырга әзер.

Тамга... Шушы кыска гына сүздә берничә мәгънә ята. Сызып, кисеп, киртләп яки көйдереп төшерелгән

Бәлки укучылар, яшь галимнәр арасында татар тарихының шушы үзенчәлекле тармагын өйрәнүне фәнни эш юнәлеше итеп алучылар да табылыр, ә шәхсән үзем исә хәл кадәри бу өлкәдә тупланган тәҗрибәм белән уртаклашырга әзер.

сызыклардан торган **шартлы билгене** аңлата ул. Тамгаларның килеп чыгышы фәнни яктан бик ачыкланып бетмәсә дә, аңлашыла ки, борынгы төркиләрдә һәр ыру-кабиләнең үз тамгасы очрый. Соңыннанрак тамгалар, шартлы билге сыйфатында, һәр ир-атта булган. Архивларда сакланган документларда, кабер ташларында хатын-кыз тамгалары да, сирәк булса да, бар. Борынгы традиция буенча, ата (эти) үз тамгасын кече улына үзгәртмичә тапшырып калдырган. Тамга шактый еллар имза ролен дә үтәгән. Халык хәтерендә «тамга салу», «тамга кую» төшенчәсе дә сакланган. Шул рәвешле элекке заманда имза салу-кул куюны аңлатканнар.

«Тамгачы» дип VIII гасырда ук хан мөһерен саклаучыны, секретарьны атаганнары да билгеле. Бу хакта Күлтәгин истәлегенә куелган кабер ташында (VIII гасыр) мондый сүзләр язылган: *«...он ок углым тюргеш каганта Макарач тамгачи, Огуз-билге тамгачи келти...»*[1]. Кайбер мәгълүматларга караганда, Алтын Урда чорында сатылган товардан алынган салым «тамга» дип, ә салымны җыючы түрәләр «тамгачы» дип аталганнар. Тамгачылар сатыла торган товарга билге сукканнар.

Урта гасырлардан сакланып калган тамгаларны тарихчы-археологлар, төрле табылдыклар арасыннан табып, фәнни яктан өйрәнү белән шөгыльләнә. Бик күп хан тамгалары урта гасырда чыгарылган тәңкәләрдә һәм мөһергә төшерелгән һәм алар ханнарның династия символы булып хезмәт иткән. Бу хакта кызыклы махсус фәнни хезмәтләр дә бар. Хәзерге заманда еш кулланыла торган «таможня», «таможенник» сүзләренең нигезендә «тамга» сүзе ятканы бәхәссез.

Тамгаларның килеп чыгышы турында галимнәр арасында бәхәсләр хәзерге көнгә кадәр дәвам итә. Тарихчылар фикеренчә, тамга борынгы заманнарда ыру-кабилә билгесе булып кулланылган. Алар үзләренең җир биләмәләрен башкаларга охшамаган билге-тамга белән күрсәткән. Мондый гадәт хәзерге көнгә кадәр сакланган, чөнки һәрбер дәүләт үз чиген гербка әверелгән тамгалы казык белән билгели.

Галимнәр арасында тамгаларны рун язмаларының калдыклары, варислары итеп карау өстенлек итә. Енисей якларында төрки Орхон язмалары табылганнан һәм укылганнан соң, шактый галимнәр арасында рун язмалары тамгаларда сакланган, дигән фикер йөри башлый. Төрки рун язмаларын тамгалар белән чагыштырып карaганда, аларның бер-берсенә гаҗәеп охшаган булуына игътибар ителә. Татар галимнәреннән танылган тел белгече профессор Вахит Хаков шундый фикердә иде. Чагыштырып карау өчен түбәндә берничә рун хәрефенең һәм тамгаларның сурәтен китерәбез.

[1] Тугушева Л.Ю. Тюркские рунические письменные памятники из Монголии. М., 2008. с.34.

РУН АЛФАВИТЫ ҺӘМ ТАТАР ТАМГАЛАРЫ

Орхон-Енисей билгеләре									
Латин хәрефләре	A	C	K	L	P	R	S	T	Z
Татар тамгалары									

Тик рун язмалары тамгаларда гына сакланган, дигән фикер белән без килешә алмыйбыз. Сәбәбе — Эльэтмиш-ябгу истәлегенә куелган кабер ташында (VIII гасыр) рун язмалары белән рәттән тамга да сурәтләнгән. Димәк, тамга белән рун язмасы бер үк вакытта ук кулланылган. Бу мисал рун язмасының тамгалардан алда кулланылуы хакында дәлил булып тора алмый. Киресенчә, рун әлифбасы иҗат ителгән чорда тамга сурәтләре файдалану мөмкинлеге турында фикер туа.

Тамгалар хакында сүз алып барганда, укучыга шуны хәтергә төшереп китү мәслихәт булыр, дип уйлыйм: VII-VIII гасырга караган беренче 36 төрки тамгасы Кытай елъязмаларында (Тан империясе чоры) сурәтләнгән. Борынгы кытайлылар төркиләрдән затлы сугыш атларын, ә төркиләр алардан кием-салым өчен ефәк сатып алганнар. Атның базар бәясе бик югары исәпләнгән, бер ат өчен 15-20 кисәк ефәк бирергә туры килгән. Сатып алынган атларга тамгалар да сугылган булган. Алар төрки ыру-кабилә билгесенә охшаган. Кытай елъязмаларында сүз төрки кабиләләренең тамгаларны мал-туарга сугып, үз хайваннарын башкалардан аеру өчен куллануы хакында сүз барса, кытайлар ул билгеләрне төрки кабиләләрдән сатып алынган атларның чын мәгънәсендә затлылык, сыйфатлылык билгесе итеп кабул иткән.

Тамганың килеп чыгышын көндәлек хуҗалыкта файдалануы белән дә бәйләп була. Моңа Үзәк Азиядә язып алынган риваять дәлил булып тора. Бу риваятьтә 92 туган тырыш хезмәт нәтиҗәсендә баеп киткән һәм аларның маллары бик күп булган. Ул бихисап маллар бер-берсе белән аралашып, буталып беткән. Малларны бутамас өчен, туганнар, бер-берсе белән килешеп, 92 тамга алган. Бу тамга алган кешеләрнең исеме төрки кавем-кабилә исеменә туры килә. Алар арасында Татар, Минг, Конграт, Аргын, Кыпчак, Кыргыз, Казах, Кыят, Кытай, Канглы, Угыз, Меркет, Кары, Төркмән, Уйгыр, Маҗар исемнәре бар. Шушы хикәят нигезендә, тамгалар иҗат итүнең төп сәбәбе итеп, хуҗалык ихтыяҗын күрсәтә алабыз.

Кайбер риваятьләр тамганы Чыңгыз хан үзе кавем-ыру җитәкчеләренә тараткан, алар белән рәттән агач, кош һәм оран бүләк иткәнлеге турында сөйли. Тамга алучылар арасында без Кыят, Кыпчак, Юрмат, Коңгырат, Майкы, Урдаҗ исемнәрен күрәбез. Биредә китерелгән исемнәр хәзерге татар, башкорт, ногай, казах, кыргыз, кырым татарлары арасындагы кавемнәр арасында булуы мәгълүм. Бу риваятьтә тамгаларны бөек Чыңгыз хан исеме белән бәйләү дә очраклы түгел, чөнки шул рәвешле бабалары-

быз тамганың изгелеген, аңа булган ихтирамны аңлаткан.

Нәсел тамгалары буыннан буынга тапшырылган, димәк, әтисе үзенең төпчек улына тамганы үзгәртмичә тапшырган. Мондый традиция тамгаларга бик күп еллар үзгәрмичә яшәргә мөмкинлек биргән. Шуңа күрә тамгалар татар халкының этник тарихын өйрәнгәндә алмаштыргысыз чыганак булып хезмәт итә алыр иде. Кызганыч, күрше халыклар тамгаларны этнографиядә еш кулланса, безнең этнограф-этнологлар исә бу чыганакка бөтенләй дә диярлек игътибар итми.

Тамгалар, әлбәттә, вакыт үтү белән, аз булса да, үзгәргән. Сәбәбе дә гади: элекке вакытта гаиләләр ишле булган. Яшьләр, яңа гаилә корып, ата-аналарыннан аерылып башка чыкканда, яңа тамга да хасил булган, яшь гаилә яңа тамга белән яши башлаган. Гадәттә, яңа гаилә тамгасы элекке тамгага бер сызык өстәү белән ясалган. Ә ул сызык элекке тамганың сурәтен нигездә үзгәртмәгән. Үзебезнең тамгалар коллекциясеннән бертуганнарның тамга сурәтләре хакында берничә мисал китерәбез. (Тамгаларның үзгәрүен күп нокталы сызык белән бирәбез):

белән алмаштырырга, тамганың бер өлешен озынайтырга, яисә кыскартырга мөмкин. Башта гади генә булган сурәт вакыт үтү белән шактый катлауланган. Шуңа күрә вакыт үтү белән катлаулы тамганы гадиләштерү процессы башланган, дип әйтеп була. Дөресрәге, ата-бабаларыбыз тамганы үзгәртү традициясен яхшы белгән һәм шул традиция буенча тамганы үзгәрткәннәр дә. Әлбәттә, тамга сурәтендә кешенең шәхси фикере, аның дөнъяга карашы, фәлсәфәсе дә чагылган. Кызганыч, бу хикмәтләрне әлегә без дөрес итеп аңлый алмыйбыз.

Тик тамга үзгәртүнең бер генә чикли торган традициясе сакланган — ничек кенә кеше үз тамгасын үзгәртсә дә, ул нәсел тамгасының төп сурәтен үзгәртә алмаган. Хәзерге заман кешесе тамгаларны үзгәртү традициясен, ысулларын ачык аңлый алса, тамгалар чын мәгънәсендә үзләренең меңъеллык тарихын хәзерге заман кешесенә сөйләп бирер иде.

Тамгаларны өйрәнү, аңлау юлында беренче адым булып аның исемен, атамасын ачыклау тора. Кызганыч ки, замана кешесе аның исемен, атамасын белми, чөнки алар кулланылмаганлыктан, күптән онытылган инде. Шулай

	Кырымсарай Боюрганов		Казынбирде Колманов	
	Акъегет Боюрганов		Кияубирде Колманов	

Тамга сурәтләре күрсәтүенчә, Кырымсарай һәм Акъегет Боюргановларның тамгалары бер сызык белән генә аерыла; шундый ук хәл — Кызынбирде һәм Кияүбирде Колмановларда.

Тамганы үзгәртү ысуллары берничә булган: аны әйләндереп, кыек итеп борырга, туры сызыкны кәкре сызык

да, халкыбызның бу онытылган мирасын яңадан кайтарырга телибез икән, тамгаларның исем-атамасын төрле язмалардан табып, киң катлам укучыга җиткерергә тиешбез. Бигрәк тә сүз катлаулы тамгалар турында бара. Алар, гади тамгаларны үзгәртү нәтиҗәсендә дөньяга тусалар да, һәрберсенең үз исем-атамасы бар.

ТАМГАЛАРНЫҢ СУРӘТЕ ҺӘМ АТАМАСЫ

Тамга						
Атамасы	Тарак	Чүкеч Тырнавыч	Борган чүкеч	Кыргыч	Тырма	Сәнәк

Тамга							
Атама	Казаяк	Уңга борган казаяк	Ябык казаяк	Тавык аягын борган	Кош аягы	Әвернә	Әвернә астан ябык

Тамга						
Атама	Хач төре	Ачамай	Әлиф; таяк; буразна	Куш әлиф	Кабырга	Кош кабыргасы

Тамга						
Атама	Өч киртек; Өч тамга	Куян колагы	Өй	Тәрәзә	Бөти	Балта

Күренгәнчә, һәрбер тамга үзенә генә хас, кабатланмас сурәте һәм атамасы белән аерылып тора. Шулай булуга да карамастан, байтак тамгаларда шактый охшашлык чагыла, аларны чагыштыру нәтиҗәсендә, тамгалар уртак бер тамырдан түгел микән, дигән фикер туа.

Халкыбыз борын-борын заманнан бирле ай, кояш һәм йолдызларга табынган һәм алар тамгаларда үзенә генә хас чагылыш тапкан. Вакыт үтү белән ай-тамга мөселман халыкларының символына әверелеп, ислам дәүләтләренең гербларында һәм дә байракларында

Вакыт үтү белән ай-тамга мөселман халыкларының символына әверелеп, ислам дәүләтләренең гербларында һәм дә байракларында сурәтләнә башлаган.

сурәтләнә башлаган. Татарларның дуга, дага, түгәрәк, чүмәлә, урак, кылыч тамгаларын шушы ай һәм кояш тамгаларының бер үзенчәлекле варианты, дип тә фараз йөртеп булыр иде.

Татарлар арасында чүмечкә яисә кашыкка охшаган тамгалар бар. Алар да кояш тамгасының бер варианты булгандыр. Чүмеч-тамга төрлечә утыртып та, яткырып та, авыштырып та ясала.

Тарак тамга — татарлар арасында киң таралган тамгаларның берсе. Бу тамганың килеп чыгышы риваятьләрдә кешенең профессиясенә бәйләп карала: имештер, тарак тамгалы кеше ат чистартучы яисә ат караучы булырга тиеш. Бу тамга хан тамгалары рәтенә керә һәм хан символы булып исәпләнә. Казан ханы Олы Мөхәммәд, Кырым ханнары Гәрәйләрнең тамгалары берберсенә нык охшаган. Шунысы кызык, өч тешле тарак тамгаларны ногайлар хан тамгасы, ә казахлар һәм кыргызлар солтан тамгалары дип атыйлар икән. Бүгенге көндә Украина дәүләтенең гербы да шул ук Кырым ханнары Гәрәйләр тамгасының бер вариантын хәтерләтә.

Т-хәрефенә охшаган тамгалар татарлар арасында шактый киң таралган. Аның килеп чыгышын тамга хуҗасының профессиясе — тимерчелек — белән дә бәйлиләр. Әлбәттә, чүкеч тамгалы һәр кеше тимерче була ал-

мый. Мондый тамга төрле төбәкләрдә төрлечә атала. Бу тамганың сурәте дә төрлечә ясала, йә вертикаль, йә горизонталь, йә авыштырып куела.

Казаяк тамгасы борынгы төркиләр арасында изге итеп исәпләнгән каздан, яисә урманда үсә торган казаяк үсемлегеннән калган булуы ихтимал. Төрле төбәкләрдә бу тамганы да төрлечә атыйлар: чебеш аяк, суер аяк, әтәч аяк тамга.

Тәрегә охшаган тамгалар татар, башкорт, кыргыз, казах, ногай, чуваш, магул халыклары арасында киң таралган. Аларның атамалары да төрле халыкта төрлечә.

Свастиканы хәтерләткән тамгалар татарлар арасында шактый очрый. Кайбер галимнәр бу сурәтне очкын чыгара торган чакмага охшата. Тик аларның хачка өстәгән юнәлеше төрле якка карый торган була. Мондый тамгаларны пермь татарлары, истәкләр, башкортлар, мордвалар, магуллар арасында очратып була.

Әлбәттә, китерелгән тамга атамалары һәм сурәт вариантлары чиксез. Татар халкының төрле этнографик группасына караган тамгаларны чагыштырып карасак, халкыбызның этник нигезе бер икәне тулысынча раслана. Татар тамгаларын башкорт, ногай, казах, кырым татарлары тамгалары белән чагыштыру да шул ук нәтиҗәгә китерә.

Бүгенге көндә Украина дәүләтенең гербы да шул ук Кырым ханнары Гәрәйләр тамгасының бер вариантын хәтерләтә.

Татар тамгалары — халкыбызның меңъеллык тарих көзгесе, аны башка милләтләрдән аерып торган үзенчәлекле мирасы, тарихыбызның әлегә чишелмәгән сорауларына җавап бирә торган тылсымлы чыганак та ул! Тамгаларны фәнни яктан тирәнтен өйрәнеп, кардәш төрки халыкларның бу өлкәдәге казанышларын да исәпкә алып, халкыбызга кайтарсак иде! Җиде бабабызны белү традициясе белән бергә, үз тамгабызны да онытмасак, бик яхшы булыр иде кана! ■

ҺАДИ АТЛАСИНЫҢ «СӨЕН-БИКӘ» КИТАБЫ БАСЫЛУГА 100 ЕЛ

СӨЕНБИКӘНЕ САГЫНУ

Һади Атласи

Сөенбикә, үзенең матурлыгы илә бөтен Казанда атаклы булдыгы кеби гакыллылыгы илә дә атаклы иде. Кыз-хатыннар арасында аңа тиң булырлык матурлар булмадыгы кеби, андый гакыллылар да юк иде[1]. Ул, үз файдалары өчен генә тырышмаенча, бөтен «йорт»ның файдасы өчен тырыша, һәр кешегә яхшылык итәдер иде. Казанның олуглары үзләренә тиешле булган сыйларны Сөенбикәдән кирәгенчә күрдекләре кеби, Казан халкының урта һәм түбәнгеләре дә үзләренә тиеш булган сыйны Сөенбикәдән күрәләр иде[2].

Сөенбикәнең яхшылыклары кояш нуры кебек Казан халкының һәрберсен каплаган, һәртөрле кешегә шул яхшылыктан өлеш чыккан иде. Сөенбикә ханлык файдасын бик яхшы төшенә, «йорт» өчен ничек эш итәргә кирәклекне бик ачык белә, шуңа күрә халыкның һәртөрлесен риза итү уенда иде. Ул шулай уйласа да, шул эш өчен бар көче илә тырышса да, казанлылар аны чынлап таный алмадылар, аның кадерен кирәгенчә белмәделәр. Менә шушы танымау һәм белмәүләр аркасында Сөенбикә руслар кулына тоткын ителде. Кызганыч, Казан ханлыгы үзе өчен иң кирәкле булган тиңсез бер башлыгын югалтты. Сөенбикәнең тоткын ителүе бер хатынның тоткын ителүе иде исә дә, чынлавында бөтен ханлыкның тоткын ителүе иде. Сөенбикәнең кем икәнлеген казан татарлары белә алмасалар да, руслар аны бик яхшы беләләр, аның нинди хатын икәнлегенә бик ачык төшенәләр иде. Шуңа күрә алар Сөенбикәне кулга төшерергә тырыштылар, сатлык казанлылар аркасында үзләренең теләкләренә җиттеләр. Сөенбикәнең тоткын ителүе руслар өчен бик зур саналганга күрә, митрополит Макарий 1552 нче елның 21 нче маенда Зөядәге рус башлыкларына язган үгетендә: «Тәңре Тәгалә безнең сөекле падишаһыбыз

[1] Истор. о Казан. цар. (Соловец. сп.), стр.80; Истор. о Казан. цар. (сп. Румянц. музея). стр.343.
[2] Истор. о Казан. цар. (Соловец. сп.), стр.81; Истор. о Казан, цар. (сп. Румянц. музея), стр.345.
[3] Никон. л., т.5, стр.183; Цар. кн., стр.482; Татищев, т.5, стр.313.

илә аның христиан сөюче гаскәрләренә, һичбер кан түкмәенчә, үзләренең дошманнарына өстен булырга, Казан ханлыгын җиңәргә насыйп итте. Казанның падишаһысы илә Сөенбикәне безнең падишаһыбызның кулына бирде», — диде[3]. Сөенбикә Казанда чагында аны санга санаган кеше аз иде исә дә, ул Казаннан китә башлагач, аның кадерен белүчеләр күбәйде. Сөенбикә киткәндә Казан халкының ире, хатыны, кызы, зурысы һәм кечкенәсе Казан елгасына чаклы озата барулары, ачы яшьләрен агыза-агыза үксеп еглаулары, күп кешенең Зөягә чаклы Сөенбикә артыннан барулары — барысы да Сөенбикәнең Казан өчен сагынырлык кеше булганлыгын аңлаталар иде. Казанлылар өчен Сөенбикәне озату бик авыр булдыгы кеби, аңардан башка тору да авыр булды. Озак елларга чаклы Казан кешеләренең күзләреннән яшьләре кипмәде. Казан халкы һәрвакыт Сөенбикәне искә төшерә, аны сагынадыр иде.

Атласи Һ. Сөен-бикә. – Казан: Типо-лит.: «Умидъ», 1914

Чынлап та, Сөенбикә сагынырлык хатын иде. Казанның борынгы падишаһлары ханлыкның кайсыбер сыйныфларын алда тоталар, үзләренең күбрәк багышлауларын шуларга гына багышлыйлар, халыкның күбрәген исә коры калдыралар иде. Сөенбикә исә алай булмады. Ул, Казан олугларын дәрәҗәләренә карап багышладыгы кеби, Казанның урта һәм түбән дәрәҗәдәгеләрен дә онытмыйдыр, һәркайсына үзенең сыеннан өлеш чыгарадыр иде.

«Йорт»ның түбән дәрәҗәдәге кешеләре, Казан ханнарыннан күбесенең күңеленә дә кереп чыкмадыгы хәлдә, Сөенбикә аларны күңеленнән чыгармый, анларга җиңеллекләр күрсәтә иде[4]. Аның шушы эшләре Казан халкының күңеленә бик нык урнашкан булганлыгы өчен, алар Сөенбикәне тиз генә оныта алмадылар. Казан ханнарыннан күбесенең исеме онытылдыгы хәлдә, Сөенбикә исеме онытылмады. Ул үзе күңелләрдә калдыгы кеби, аның исеме дә телләрдә калды. Аны үз заманасының кешеләре сагынып сөйләдекләре кеби, соңгы заманнарда да ул сагынылып сөйләнер булды. Ул хәзерендә дә сөйләнә ки, аңа һәркем чын хатын диеп карый. Татар хатыны тагы да шундый булдыклы хатыннар тугдырсын иде, диеп теләктә була. ■

[4] Истор. о Казан. цар. (Соловец. сп.), стр.80-81; Истор. о Казан. цар. (сп. Румянц. музея), стр.344-345.

ХӘТЕР КӨНЕ БАЙРАГЫ

Мәсгуд Гайнетдин



1905 ел революциясе – хөррият хәрәкәте җиңелә. 1907 елның 3 апрелендә икенче Дума куып таратыла. Илдә реакция режимы урнаштырыла. Ирек, хокук таләп итүдә, царизм һәм бюрократия «кытыгына кагылучылар»ны Төньякка, Себергә сөргенгә куалар.

Ильяс Фәйзуллин. «Казан шәһәрен Явыз Иван гәскәрләреннән саклау (Апофеоз)», Киндер, майлы буяу. 2005 ел

Күп кенә татар зыялылары 1908 елда Төркиядә «Яшь төрекләр» революциясе җиңү сәбәпле, Төркиягә качып, Себер сөргеннәреннән котылып кала. Россия революциясе тәҗрибәсе белән баеган Й.Акчураны «Яшь төрекләр», элеккеге көрәштәш иптәшләре кабат үз араларына тартылуын өнәмиләр. Муса Акъегетзадә, Габдерәшит Ибраһимов, Хәлим Сабит кебек татар эмигрантлары белән якынаеп, Й.Акчура игътибарын азатлык хәрәкәтендә төрки халыкларның интернациональ бердәмлеген оештыру эшенә карата. Татар зыялылары радикал төрек зыялылары белән берлектә «Төрек дернәге» (бердәмлеге) дигән оешма төзи. Зур кыенлыклар белән шул ук исемдә журнал чыгару эшенә керешсәләр дә, 7 сан гына чыгара алалар. Й.Акчура мөмкинлек тапканда төрле төрек газета-журналларында мәкаләләр бастыргалый. 1913 елга кадәр Русиядә татар газеталарында (башлыча Оренбургның «Вакыт» газетасында) әсәрләре басылгалап тора. 1911 елда Төркиядә «Төрек йорты» дигән иҗтимагый оешма оештыралар, шул исемдә журнал чыгаралар. Бу гомумтөрки оешма һәм басманы мәйданга китерүдә Й.Акчура иң актив җитәкчеләрдән була. 1918 елга кадәр журнал редакциясен дә ул җитәкли. Бу елларда аның иҗади эшчәнлегендә Идел буе татарлары проблемалары үзәк урынны биләп тора.

Й.Акчура хөррият (1905 ел революциясе) көннәрендәге иҗат эшчәнлегендә татар халкы азатлык хәрәкәте стратегиясен һәм тактикасын формалаштыру югарылыгына күтәрелә. Реакция елларында да ул, көрәш көннәрендә ирешкән югарылыкта калып, кара көчләр тудырган шартларда яшәгән көнкүрештә алгарыш, тәрәккыятьне, җанлылык, хәрәкәтне мөмкин булган форматында дәвам иттерүнең идеологиясен, стратегиясен ачыклауга, тактикасын билгеләүгә җитди игътибар карата. Максат, кыйбла, төп принциплар шул ук — көрәш көннәрендә өйрәнгән, ирешкән уңышлар. Юк мөмкинлекне бар итеп, шул максатка тугрылыклы булып калырга! Ирешелгән уңышларны мөмкин кадәр ныгытырга, үстерергә-яшәтергә өйрәнергә кирәк... Фәнни карашларны массалаштыру, җәмәгатьчелектә ирешелгән бердәмлекне саклау, ныгыту — максатка ирешүнең ачкычы. Шуңа күрә Й.Акчура бу яңа этапта фәнгә — иленең-халкының үткәнен, тарихын өйрәнүгә, бар итүгә җитди игътибар карата.

Х.Әмирхан, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхреддин, М.Рәмзи, Х.Габәши, К.Халитовлар хәрәкәтен яңа югары баскычка күтәреп, Й.Акчура белән бервакытта диярлек Һ.Атласи, Ә.Вәлиди, Г.Баттал һ.б. кебек тарихчылар мәйданга чыга. Й.Акчураны шул тезмәнең иң алдынгы һәм иң затлы, кыйммәтле тәүге мәрҗәне дип атап була.

«Төрек йорты» журналының беренче санынннан унберенче санына кадәр (1911 ел, ноябрь — 1912 ел, апрель) Й.Акчураның «Чыңгыз хан» исемле шактый күләмле тарихи монографиясе басылып чыга. Әлеге затлы хезмәте белән галим урта гасырлар татар тарихында мифлардан һәм легендалардан укмаштырылган «Чыңгызнамә»ләр — фольклорлаштырылган сөйләкләрне (риваятьләрне) бу атаклы шәхеснең фәнни биографиясе белән алыштырып татар фәне түренә утырта. 1912 елның июль (№18) санында Ә.Вәлидинең «Төрек вә татар тарихы» исемле дәреслегенә язылган рецензиясе яңа тарих китапларына тәнкыйть мәкаләләренең беренче классик үрнәге саналырлык язмасы дөнья күрә. Ике хезмәттә дә галимнең үз иҗаты бәясен кимсетү-төшерү тенденциясе сиземләнә кебек. «Чыңгыз хан» монографиясендә моны ул әсәрнең исеменә үк чыгара: «Мөәррих (тарихчы) Леон Каһун вә мөгаллим Бартольдка күрә Чыңгыз хан», гүя бу язмада Й.Акчураның бернинди иҗади һәм фәнни хезмәте юк. Телгә алынган дәреслек исеме белән чыгарылган мәкалә алдына шунда ук, җәя эчендә «Әхмәдзәки Вәлиди әсәре» дип күрсәтелгән. Журналның шул елда басылган мәкаләләр библиографиясендә дә әдип-мөхәррир Й.Акчура үз мәкаләсеннән баш тартуын искәрткәндәй: «Әхмәдзәки Вәлиди хезмәте» дип язган. Мәкаләдә автор «Госманлы» (Төркия) тарих фәненең аяныч хәлдә булуыннан үртәнә: ««Төрек тарихы» диярлек бернәрсә мәйданга килмәде...» — ди. «Төрек-татар тарих»ын күкләргә күтәреп мактый: «Әхмәтзәки әфәнденең тулысынча гыйльми һәм намуслы хезмәт сызыгында эш йөртүе...»

Шул ук рецензиядән укыйбыз: «Төп максат — милли тарихны тикшерү һәм мәйданга чыгару...», «Милли тарихка караган оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләр бик аз күрелде...» Йосыф Акчура «Төрек йорты» журналының 1912 елгы 9 нчы (август) санында дәвам иткән бәяләмәсендә: «Казан ханлыгының соңгы көннәрен тасвирлаган өлешеннән кайбер битләрен нәкъ авторның үзендәгечә тоташ текст итеп күчереп үтүне муафикъ күрдек», — дип яза.

Акчура, байтак язмаларындагы кебек үк, бу язмаларын да «фәнниләндерү» белән генә чикләнми, укучылары галәменә якынайтыр өчен сәнгатьләндерә, затлыландыра, матур итә. Язманы үлчәмлелеге, камиллеге, фәнни системалылыгы, мантыйк көче генә түгел, авторның рухи халәте, хисләре өермәләнүләре чагылышы булган актив эмоциональ импульслар да куәтләндерелә. Тотрыклы активлыкта алар Й.Акчураның стиль үзенчәлегенә

әйләнәләр. «Казан ханлыгының соңгы көннәре» язмасын әлеге стиль күренешенең төенләнеш ноктасы дип билгеләп була. Стиль формалаштыру материалы биредә мәкаләнең темасына, сюжет-эчтәлек материалына әйләндерелгән. Бу инде стильгә ниндидер тышкы тәэсир генә түгел, реаль материаль гәүдәгә керү, мәкаләгә, әсәргә әйләнү. Мәкаләдә галим бар игътибарын тарихта билгеле булган фактлар нигезендә ханлык эчендә бердәмлек булмау, эчке таркаулык, мәгънәсез аңсызлык ролен ачыклауны сызык өстенә чыгара…

25 ел инде Казан ханлыгының соңгы көне Хәтер көне буларак билгеләп үтелә. Бу көндә фаҗигале рәвештә шәһит киткән бабаларыбыз рухына Коръән укып дога кылына. Игътибарыгызга әлеге мәкаләне тәкъдим итүебез дә шушы фаҗигане искә алып, бабаларыбызны онытмаска тырышу факты булып аңлашыла. Олы галимебезнең бу атаклы язмасы Хәтер көне килгәнне искәртүче бер билге, символ, «байрак күтәрү», «барабан кагу», әлеге бөек көнне авазландыру, массалаштыру кебек бер гамәл булып калсын иде.

ТӨРЕК ВӘ ТАТАР ТАРИХЫ[1]

Йосыф Акчура

Җиде-сигез еллар элек Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих укытучысы идем. Мәдрәсәнең югары сыйныфларында беренче дәресемдә кереш сүз рәвешендә сөйләшүне шундый фикер белән башладым: «Әфәнделәр! Төрек тарихы эшләнеше соң чиктә түбән дәрәҗәдә! Бик аз эшкәртелгән. Бик зур тырышлыклар, бик зур көч сорый торган хезмәт. Госманлы төрекләре арасында җитди рәвештә, төрек тарихын язу эшенә керешкән, һичьюгы шуңа нигез булырлык материалларны, әсәрләрне барларга, җыярга тырышкан җан иясе юк дәрәҗәсендә бик аз. Нәҗиб Гасыйм әфәнде, Көнбатыш әсәрләреннән файдаланып, бу өзеклекне күпмедер капларга тырышлык күрсәткәндәй булды. Бүгенге Госманлы дәүләте тоткан сәясәтне ачыктан-ачык яклаучы материал күрмәгәннәре, тапмаганнары сәбәпле, аның нәтиҗәсе аз булды. «Төрек тарихы» дип атарлык бернәрсә мәйданга килмәде. Бары-югы, әсәренең беренче томын бастырып чыгара алды. Рәсми яки ярым рәсми «Төрек тарихы җәмгыятьләре» кебек җәмгыятьләр мөстәкыйль төрек дәүләтендә дә юк. Нишләмәк кирәк? Төрек кавеменең өлешсезлеген, дөньяда яшәү өчен, бәхет өчен, милләт өчен тарихның ни дәрәҗәдә кирәк икәнен тикшерергә, аңлатырга җыенмыйм. Тирә-ягыгызга күз салып, башка милләтләрнең үз тарихларын тикшерү-ачыклауга, камилләштерүгә күпме тырышлык, күпме көч куйганнарын күрерсез, бу эшнең бер мәгънәсезлек түгеллеген аңларсыз. Һәр җирдә, һәр милләт эчендә күпме халыклар бөтен гомерләрен, барлыкларын шул хезмәткә багышлыйлар. Кайберсе ялгыз үзе фидакярлекләр күрсәтә. Кайберләре, бу максатка ирешүне җиңелләштерер өчен, түгәрәкләргә, җәмгыятьләргә берләшеп, эш йөртәләр. Кайсыбер хөкүмәтләр бу тырышлыкларның, бу гайрәтләрнең милли бер эш икәнен аңлап, үзләре үк шундый җәмгыятьләр төзиләр яки

[1] Әхмәдзәки Вәлидинең 1912 елда Казанда «Милләт» матбагасында дөнья күргән «Төрек вә татар тарихы» әсәренә бәяләмә.

бар булган җәмгыятьләрне яклашып, аларга һәртөрле ярдәмнәр оештыралар. Әлбәттә, бу тырышлыклар, бу гайрәтләр нәтиҗәсез калмый».

Мин бу фикерләремне тыңлаучыларга ишеттергән көннәремнән бик аз вакыт кичте. Шул аз вакыт эчендә дә, Аллага шөкерләр булсын, төрек галәме милли тарихын тикшерү, язу юлында тырышлыклар күрсәтте. Бүген төрек галәменең телгә алырлык үзәкләрендә милли тарихны тудыру эшенә җитди игътибар күрсәтүчеләр, хәтта җәмгыятьләр инде бар, дип әйтә алабыз. Төрек солтанының мөбарәк тәшәббесе (инициативасы) белән корылган «Госманлы тарихы җәмгыяте» — шундый оешмаларның мөһимнәреннән. Шуның белән бергә, иркенләп эшләүләренә һичнинди административ киртә булмаган «Конституцияле монархия» («Мәшрутият») дәверендә госманлыларның төрек тарихы өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре, башта өмет иткәннән аз икәнен дә искәртеп үтәргә тиешбез. Төп максатларыннан берсе — милли тарихны тикшерү һәм мәйданга чыгару булса да, «Төрек дөрнәгә» җанлы, нәтиҗәле яшәеш юлына чыга алганы юк әле. Милли тарихка карашлы оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләр бик аз күренде. Госманлы тарихчыларының бу юнәлештә тырышлыклары сүлпәнлегеннән туган борчулы тәэсирләребезне шималь төрекләренең (татар галимнәренең) гайрәт һәм җанлылыклары бераз йомшарта. Шималь төрекләренең Казан, Оренбург, Уфа кебек мәдәният үзәкләрендә соңгы өч-биш ел эчендә «Мөфәссаль тарих кавем төрки», «Төрек ыруглары», «Болгар тарихы», «Казан тарихы», «Сибирия тарихы» һәм, ниһаять, «Төрек-татар тарихы» кебек эзләнү, гомумиләштерә тораган хезмәтләр мили тарихның бер өлешен яктыртуга юнәлдерелгән. Ягъни гомумтөрки тарихның кайбер өлкәләрен кузгалткан мөһим әсәрләр мәйданга китерелде. Хәтердән чыгармыйк, болар — эзләнү-тикшерүләр белән тудырылган хезмәтләр. Төрле китаплардан күчереп тарих язу, аз-маз француз телен белүдән файдаланып, хакмыхаталанумы икәнен уйламастан гына, тарих китабы тәрҗемә итү түгел. Чыганаклар актарып, фактларны чагыштырып, тәнкыйди тикшереп нәтиҗә чыгара белү элек-электән тарихны тикшерү һәм язуның төп ысулы саналган.

«Төрек-татар тарихы» да үткәннәрне өйрәнүгә әмәл итеп, гыйльми саналган ысуллар файдаланылып язылган. Автор китабын моңарчы билгесез булып килгән фактларга гына нигезләми, андый дәгъва белдерми. Икенче кулдан, ягъни тарих китапларында тупланган фактлардан файдаланып язганын ачык искәртә. Китапның башында, озын исемлек рәвешендә файдаланылган чыганакларны күрсәтә. Текст эчендә дә, уңышлы күрелгән өзекләрне сүзгә-сүз, үзгәрешсез китерә, астөшермәдә чыганакларын тәкъдим итә. Хезмәт башында чыганаклар библиографиясен китерү, һәр биттә файдаланылган өзекләрнең чыганакларын астөшермәләрдә күрсәтү — тарих язу эшендә табигый һәм тиешле бер ысулдыр. Плагиатлыкка, укучыларның белмәвеннән файдаланып, башкалар казанышын үзенеке итеп күрсәтергә гадәтләнгән җаһил даирә матбугаты (Истанбул матбугаты) белән көн дә очрашып торган бер заманда, мөхтәрәм Әхмәдзәки әфәнденең тулысынча гыйльми һәм намуслы хезмәт сызыгында эш йөртүе аерым бер алкышлауга лаек. Төрек тарихы белән кызыксынучыларга бер файдасы тимәсме дип, «Төрек-татар тарихы»ның иң мөһим чыганакларын телгә алып үтәргә уйласам да, аларның күбесе русча булып, русча белүче госманлы төрекләре бик аз булганга, ул фикердән ваз кичәргә туры килә. Тик шуны искәртеп үтәм: төрек тарихын тикшерү белән җитди шөгыльләнергә уйлаган кешеләргә рус телен белү мотлак шарттыр, чөнки төрек тарихына кагылышлы рус телендәге әсәрләр Ау-

рупа телендә язылганнарның барчасы арасында өстенрәге.

Авторның «Төрек-татар тарихы»н язуда алдына куйган изге, әһәмиятле ягы бар. Аның игътибары үз милләте булган Казан төрекләренең бу көнгә кадәрге тарихи үткәннәрен яктыртуга каратылган. Тарихының төп өлешен яктыртуга керешкәнче, ул бөтен төрекләр (төркиләр) тарихының иң борынгы чорын тәшкил иткән гомумтөрек дәвере тарихына туктала. Казанның хәлләрен сурәтләүдә тарихчы аерып алу алымын куллана. Гомумтөрек дәверен сөйләгәч, сүзне аерып алынган Казан төрекләре (татарлары) хәлләренә күчерә. Башка төрекләр язмышы бәяннан читтә кала. Мондый чикләү максатка муафикъ булса да, «Төрек-татар тарихы»н барлык төрек-татар кавеме тарихы дип булмый. Шуңа да карамастан, Әхмәдзәки Вәлиди әфәнденең әсәре моңарчы язылган барлык тарихларыбызның иң уңышлысы булып чыгуы куанычлы хәл. Китапта төп тема Казан булганлыктан, хезмәтне томнарга бүлүгә дә Казан нигез итеп алынган. Казан өчен иң мөһим вакыйга булган мөстәкыйльлек Әхмәдзәки әфәнде хезмәтен ике томга аера. Әсәрнең хәзергә беренче томы гына басылган. Казанны Русия яулап алудан бүгенге көнгәчә булган вакыйгалар томы — икенче том алдагы кышта басылачак, дип вәгъдә ителә. Беренче том, әйткәнебезчә, гомумтөрек тарихындагы бөек үзгәрешләрдән башланып, Казан ханлыгының егылуы белән тәмамлана. [...]

Казан ханлыгының яшәү дәвере бик кыска: 1439-1552 еллар. Автор бу бик аз гомерле төрек дәүләтенә, үз ватаны булганы өчен, аерым бер фасыл биреп, вакыйгаларга аерым-аерым туктала. Казан тарихы, башлыча өч вакыйгага кайтып кала. Русия белән башы-азагы күрелмәгән сугышлар. Ил эчендәге төркемнәр арасында ызгышлар. Сәүдә. Русия белән сугышларда ханлык әүвәлләре өстенлекләр күрсәтсә дә, соңра, күбесенчә, җиңелә. Казан ханлыгы аксакаллары, өченче ханнары заманыннан башлап, ике төркемгә бүленәләр, өзлексез ызгышып яшиләр. Бу эчке гаугаларына күршеләре Мәскәү дәүләтен дә аралаштыралар, руслардан ярдәм, хәтта хан сорыйлар. Казанның соң дәверендәге бу ике төркемнең берсе — Мәскәү яклы, берсе — Кырым ханлыгы яклы. Кырым ягы ханлыкның мөстәкыйльлеген куәтли, Мәскәү партиясе исә Казанны рус идарәсе астына кертү өчен тырыша. Вәлиди әфәнде бу төркемнәр гаугаларын ачык, тулы бәян итә. Мәскәү дәүләте һәм аның яклы төркем башында йөргән хан, мирзаларның ватаннарына хыянәтләрен ачыктан-ачык фаш итә. Әмма бу төркемчелек низагларының асыл сәбәпләрен ачмый, язмый, күрсәтми. Нигә казанлылар ике төркемгә бүленделәр? Ни өчен бер төркем — ханга һәм ханзадәләргә, бик һәм мирзалар үз ватаннары мәнфәгатьләренә каршы хәрәкәт итәләр? Дошман интригаларына җирлек-мөмкинлек биргән әмәлләр нәрсәдән гыйбарәт? Бу сорауларга канәгатьләндерерлек җавапларны Вәлиди әфәнде әсәреннән таба алмыйбыз. Казан ханлыгының Мәскәү патшалары тарафыннан басып алынуы — төрек һәм урысларның гасырлар буенча хөкем сөргән үзара талашларының сәбәпләреннән берсе. Шул яктан карaганда, автор әсәренең беренче томында йомгак рәвешендә бу мәсьәләгә җитди кагылуы гомумтөрек-татар карашы ноктасыннан да әһәмиятле санала. Әмма Казан камалышлары сугышларына күп битләр урын биреп тә, Казан ханлыгының икътисады, сәүдәсе, гыйльми-мәдәни тормышы темаларына җиңелчә генә кагылуын кисәтеп үтү сорала. «Төрек-татар тарих»ының болардан башка да кайбер җитешсезлекләре бар. Автор кереш сүзендә моны үзе дә әйтә. Шул ук вакытта Әхмәдзәки әфәнденең бу әсәре, кабатлап әйтәм, төрек-татар тарихы турында бүгенгә кадәр төрекчә (татарча) язылган әсәрләр арасында иң уңышлысы, дияргә була.

КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ

(Вәлиди әфәнденең) әсәре хакында тулы бер фикер тусын өчен, Казан ханлыгының соңгы көннәрен тасвирлаган өлешеннән кайбер битләрен нәкъ авторның үзендәгечә тоташ текст итеп күчереп үтүне муафикъ күрдек.

«Сафагәрәй хан, казанлылар чакыруы буенча, икенче мәртәбә хан булып килгәнендә (1535 ел), тәхет куркынычсызлыгы өчен, үзе белән берникадәр Кырым гаскәрен алып килде. Чөнки Сафагәрәй хан казанлыларның үзенә тугрылыгына ышанычын берникадәр җуйган иде. Аерым алганда, Казандагы Мәскәү тарафдарлары, ачуларыннан: «Синең безгә кирәгең юк!» — дип дау кузгатачаклары котылгысыз иде. Хан булыр-булмас, Сафагәрәй хан Җангали ханнан тол калган Сөембикәгә өйләнде. Мәскәү тарафдарлары Мәскәүгә: «Казан халкы арасында бик күбесе Сафагәрәйнең хан булуын теләмиләр. Әгәр сез Шаһгалине хан булырга күндерсәгез, халык аны бик хуп күреп каршы алачак», — дип яздылар. Мәскәү кенәзе Иван һәм боярлар, Шаһгалине чакырып, гаскәр кушып, Казанга каршы җибәрергә теләсәләр дә, Сафагәрәйнең тәхетне ныклап биләвен ачыклап, бу хәрәкәтләреннән ваз кичтеләр. Казан бикләре һәм асылзадәләре үзара мыж килә иде. Кайберләре, Сафагәрәйгә каршылык белдереп, Мәскәү кенәзләре белән тоташ хәбәрләшеп торалар. Казанның югары катлау кешеләре арасында ышанырлык җан иясе калмаган иде. Күбесе, юк-бар сәбәп белән, иленең дошманы булган Мәскәү хөкүмәтенә сыгыналар иде. Бу заманнарда Казанның мәшһүр галимәләреннән Гршаднә* бикә кенәз Иванга язган бер хатында: *«Казанның иң һәлакәтле заманы. Бар халкының башы түнгән. Казан ханлыгының бик якын заманда егылачагында шөбһәм юк»,* — дип яза. (Бикә — бик сүзенең хатын җенесенә карата куллану формасы. Гршаднә исеме урыс тарихларыннан алынганга, руслар ялгыш язган булулары мөмкин. Казан тарихчыларыннан Гайнетдин әфәнде бу исем хакында: «Гаҗәп?! Дөресе Хөршид ана түгел микән?» — дип яза («Казан тарихы», 73 б.) Русчада, кайчак «Гур шадна» дип, кайчак «Гуршанда» дип язылуына карап мин дә «Хөрсәндә» (шат-канәгать) түгелме икән, дип уйланам. (Й.А.)) Бу хатын кайберәүләргә: *«Казанның ун еллар да яшисе юк, юкка чыгачак»,* — дип сөйли икән. Гаҗәп инде: Сафагәрәйгә кадәр хан булган Җангали ханны үтерү хәрәкәте башында торган Булат мирза, инде Сафагәрәйгә дә каршы килә. Туры килгәндә, бу башбаштаклыклардан тетрәнгән Сафагәрәй хан да, үзе китергән кырымлылар файдасына, казанлылар белән бәрелешүләрдән тыелмый.

1536 елда Мәскәү хөкүмәте Казанга каршы ике колонна итеп гаскәр җибәрде. Бу ике отряд, Казан янында кушылып, тирә-як авылларны яндырып йөрделәр. Халыкның малларын таладылар, үзләреннән әсирләр алдылар, һичбер тарафтан бернинди каршылык күрмәенчә, Мәскәүгә кайтып киттеләр. Сафагәрәй хан бу вакыйгада Казан әмирләренең хыянәтен күреп, аларны эзәрлекләргә керешә. Моңардан Казанда зур фетнәләр купты. Казанлылар Сафагәрәй кул астындагы кырымлыларны үтереп бетерделәр. Сафагәрәй үзе Нугай урдасына, каенатасы Йосыф мирза янына качты. Хан киткәннән соң, казанлылар арасында: «Инде эшне нәрсәдән башлыйбыз?» — мәсьәләсендә янә ызгышлар купты. Кайсылары — Истанбул солтанына буйсынуны, кайсылары — Русия хөкүмәтенә буйсынуны, кайсылары Кырымнан икенче бер хан чакыруны якладылар. Мәскәү яклылар күпчелек иде. Сәед углан, мирза

* Ә.Вәлиди китабында Гуршаднә.

һәм аларның ишләре, Мәскәү кенәзенә илче җибәреп, Иваннан Шаһгалине Казанга хан итеп җибәрүен сорадылар.

Бельский һәм Полицкий атлы рус кенәзләре Шаһгалине Казанга китереп, ханлык тәхетенә утырттылар. Казан аксөякләренең максаты, Шаһгалине Казанга рәсми рәвештә генә хан итеп, ил белән идарәне үз кулларында тоту иде. Шаһгалине хан сарае тоткыны иткәндәй, һичкем белән очраштырмас, сөйләштермәс булдылар. Чура исемле бер мирза, Шаһгали яклы булып, каршы тарафка күп үгет-киңәшләр итсә дә, тәэсире булмады. Шаһгалине кысуны дәвам иттерделәр. Ниһаять, тагын Нугай урдасындагы Сафагәрәйне чакырасы иттеләр. Шаһгали, Чура морза киңәше белән, Мәскәүгә качты. Сафагәрәй хан, Казан халкы исеменнән тәхеткә чакырылмаса да, көч кулланып, Казанга кереп тәхетен кайтарыр өчен, нугайлардан һәм кырымлылардан зур гаскәр туплаган иде. Казанга шул гаскәре белән кайтты. Мәскәү тарафлыларны үтертте. 76лап мирза һәм түрә Мәскәүгә качтылар һәм анда аларга, Казанга чакырып, мөрәҗәгать иттеләр, Казанның эчке тотрыксызлыгы турында күп мәгълүмат бирделәр. Казандагы бетмәс-төкәнмәс ызгышлардан интеккән Казанның иң ышанычлы ярдәмчеләре булган чирмешләр дә ялыккан, боеккан иделәр. Чөнки Казан түрәләре, башсызлыктан файдаланып, чирмешләрне авыр салымнар белән талыйлар… Чирмешләр дә кенәз Иванга үз илчеләрен күндереп, инде аңа итагать белдерделәр.

1549 елда Сафагәрәй хан вафат булып, ике яшьлек улы Үтәмешгәрәй белән хатыны Сөембикә тол калды. Көчле ханнарга хөрмәт, итагать күрсәтмәгән казанлылар Үтәмешгәрәйне хансызлыктан хан итеп билгеләделәр. Казан идарәсе Үтәмешгәрәйнең анасы Сөембикә кулына күчте. Әмма казанлыларның: «Кемне хан итсәк икән? Кемгә буйсынсак икән?» — сәүдәсе-ызгышы өзелмәде, тукталмады. Бу тартышулар әледәнәле канлы бәрелешләргә кадәр үсә, җиңелүчеләр илне ташлап качарга мәҗбүр була иде.

Мәскәү яклылардан ун меңләп кеше, Казанны ташлап, Мәскәүгә китеп, Мәскәү кенәзенә хезмәткә керде. Мәскәү хөкүмәте Казандагы башбаштаклыклардан кичегүсез файдаланып калырга, бу форсатны Казанны яулап алу максатына карату фикерендә иде. Мәскәү кенәзе зур гаскәр туплап өлгерде. Кенәз Юрийны, Шаһгали ханны, Казаннан күчеп килгән мөселманнарның һәммәсен шул гаскәренә кушып, Казан өстенә йөрде. Бу яуга башка сугышлардагыга караганда күбрәк гаскәр тупланган иде. 1550 елда Иван гаскәрләре Казан стеналары алдына килеп тупланганда, һөҗүмгә әзерләнгәндә, Казан ханын тәрбиячеләре бишектә тирбәтә, Казан олылары исә, кара-каршы ике төркемгә бүленеп: «Кырыммы, Мәскәүме?» — ызгышын кызулатканнан-кызулата бара иделәр. Мәскәү яклылар бу бәдбәхет көннәрдә ватаннарына ябырылган, шәһәрләрен камаган кенәз Иван каршысына барып, аңа хезмәткә керү белән мәшгуль. Казанлыларның иҗтимагый, сәяси, әхлакый таркалуы менә шул дәрәҗәгә төшкән, төрекләргә (төркиләргә) хас хәрби гайрәтләре юкка чыккан иде. Казанның баганалар бастырып ясалган агач ныгытмасын урыслар өзлексез тупка тоталар. Кенәз, ныгытманы җимерү өчен, кулында булган чараларның барысын кулланды. Ничә көннәр өзлексез туп аттырды. Ләкин һич нәтиҗә чыкмады. Кенәзнең үз командалыгы астында 60 меңлек рус гаскәре ныгытмага һөҗүм башлады. Әмма казанлылар русларны шәһәр капкаларыннан арыга үткәрмәделәр. Бу куркыныч мизгелләрдә Казанның гайрәтле мәликәсе Сөембикә үзе дә ныгытма койма өсләренә чыгып сугышчыларга киңәшләр биреп йөрер иде. Ун көн өзлексез һөҗүм булды. Әмма шәһәр каршылыгын киметмәде. Февраль азаклары иде. Көннәр җылынып,

карлар эри башлады. Рус тарихчылары сүзләренә караганда, юллар өзелүдән куркып, яшь кенәз гаскәрне сугыш кырыннан алып, башкаласы Мәскәүгә кайтып китте. Ләкин үзен куркаклыкта гаепләмәсеннәр өчен, казанлылар һөҗүме ихтималы булмаганын белә торып, үзенең сакчы отрядын гаскәрнең арьергардында калдырды.

Мәскәүлеләр һөҗүм иткәндә шәһәрне шанлы рәвештә саклый белгән казанлылар араларында, дошман киткәннән соң, бер-берсенә дошманлыклар, хыянәт, икейөзлелекләр тагын да куәтлерәк рәвештә башланып китте, һичкем икенче берәүнең сүзен колакка элми, кабул итми, һәр кеше үз ниятен генә бердәнбер дөреслеккә чыгара. Сөембикә, бу хәлне күреп, еглаудан башка чара таба алмый, нинди генә чарага керешсә дә, ул тырышлыклары нәтиҗәсезлек белән тәмамлана иде. Җәмәгатьчелек тагын ике төркемгә бүленгән. Берсе, руслар һөҗүме кабат башланачагын искәртеп, сугышсыз, каршылыксыз гына Мәскәү хөкемен кабул итүне яклый. Икенчесе, үткәндәге уңышларны хәтерләтеп, Мәскәү яклылар тәкъдимнәренә катгый каршылар. Бу төркем җитәкчесе Кошмак углан исемле Кырым мирзасы, Сөембикә куәтләвенә таянып, соңгы сулышкача ватанны яклау фикерен алга сөрә иде. Бөтен Кырым партиясе Кошмак мирза тирәсенә укмашкан. Кошмак, кылычын күтәреп: *«Кяфергә без, шул кылычтан башка, бернәрсә дә бирмәячәкбез, без — урыска кол булмыйбыз!»* — дияр иде. (Карамзинның русча тарихыннан алынган.) Казанлылар исә аңа каршы: «Син Үтәмешгәрәй ханны һәм үзеңә каршы булганнарның барысын үтереп, Сөембикәгә өйләнеп, үзең хан булырга телисең!» — дип шомлануларын белдерәләр. Кошмак углан һәм кырымлылар үзләренә Казанда артык ышаныч калмаганын, үзләренә яклау таба алмаячакларын аңлап, Казанны ташлап киттеләр. Юлларында рус гаскәре белән очрашып, 300 атлы булганнары хәлдә, 45 кеше калганга кадәр сугыштылар. Бу 45 кешене руслар, әсир итеп, Мәскәүгә алып киттеләр һәм көчләп чукындырырга теләделәр. Һичберсе христианлыкны кабул итмәгәч, барысын астылар». Асылганнар арасында Кошмак мирза да бар иде. Бу хәлләрдән соң, Казан бер еллар гына мөстәкыйльлеген саклый алды. Казанның хәтта соңгы камалу эчендә калганында да, халкының ике төркемгә бүленгәнен күрәбез. Бер яктан, Камай дигән мирза, кенәз Иван алдына килеп, Казан эчендәге барлык хәлләрне сөйләп бирә: «Без Русиягә тапшырылырга телибез. Әмма безгә каршы як безне төрмәгә яба, җәзалый. Бер мин качып котылдым. Голямалар рәисе мулла Кол Шәриф*, Ирниш мирза, Чапкын, Аталык, Ислам, Галкәй, Нарик исемендәге мирзалар** халыкны Русиягә буйсынырга үгетлиләр», — ди.

Әхмәдзәки әфәнде бу хәлләр турындагы фикерен йомгаклап, үзара ызгышларны Казан ханлыгы егылуының иң төп сәбәпләренең берсе итеп күрсәтә: Казанда, сәяси мәсьәләләрдә һәрчак килешмәүчәнлек булды, шуннан ызгыш, гаугалар туды. Өзлексез дәвам иткән бу гаугаларда шәхси өстенлекләре, мәнфәгатьләре өчен ватаннарын — илен, халкын корбан итәргә әзер кешеләр дә аз түгел иде. Андыйлар, китеп, Мәскәү кенәзләренә хезмәткә керделәр. Үзләренә каршы торганнарны җиңәр өчен, Казан ханлыгын юкка чыгаруга ярдәмләштеләр.

Төрек теленнән ***Мәсгуд Гайнетдин***
тәрҗемәсе ■

*Алга таба Ә.Вәлидинең «Төрек вә татар тарихы» исемле китабында: «(26 августта) Сугышта Казанның зурларыннан Ислам, Сөнчәли мирза, Нариков кебиләр шәһид улдылар», — дип язылган. — Кара: Б.248. (Ред.)

**Шул ук китапта: «Мелла Кол Шәриф бер микъдар шәкертләр илә мәдрәсә өстенә менде, шуннан торып, руслар илә каты сугышып, руслар(ны) мәдрәсә түбәсеннән санчеп төшереп, җөмләсен үтерделәр», — дип яза. — Кара: Б. 255. (Ред.)

Казан мөселман хәрби комитеты[1], революция заманыннан файдаланып, 1917 нче елның 2 нче сентябрь утырышында Казанда крепость эчендәге, татарлар арасындагы «Хан мәсҗеде» дип, руслар тарафыннан «Сөенбикә манарасы» дип аталган тарихи манараның башындагы бөркет (орёл) сурәтен алып, аның урынына ай куярга карар биргән вә шул карарына бинаән[2], сентябрьнең 16сында корбан гаеденең өченче көнендә орёлны төшергән, ләкин ай куярга өлгерә алмаган иде.

Шул мөнәсәбәт белән ошбу манара хакында Казанда төрле кыйль-каллар[3], рус голямалары[4] тарафыннан манараның татар әсәре булмавы хакында сүзләр күтәрелде. Шул рус голямаларының төрле яктан протестлары явып торган көннәрдә, Казан хәрби комитеты, манара хакында рус матбугатында чыгарыр өчен, бер мәкалә язуны тәклиф[5] итеп, миңа мөрәҗәгать кылды һәм бер кечкенә генә җыелыш вакытында иптәшләремнән Газиз әфәнде Гобәйдуллин[6] миңа бу манара хакында бер лекция укырга киңәш итте. Лекциядән, матбугат өчен мәкалә чыгару һәм мөмкин булачагын игътибарга алып, мин бу киңәшләрдән соңгысын тыңладым; аннан килгән файданың бөтен Русия мөселман укытучылары берегенең[7] мәркәз[8] бюросына бирелүенә карар кылдык.

Лекция ике бүлек итеп укылды. Ошбу бүлекләрне күрсәтер өчен I һәм II сурәтендә рәкымнәр[9] куелган. Лекциянең әсаслары[10] ошбулардан гыйбарәттер:

I — Сөенбикә манарасыннан бөркетне төшерү мөнәсәбәте илә булган хәлләр:

Асаре гатика[11] җәмгыятенең игътиразы[12], вилаять[13] комиссарының катышуы, пайтәхет[14] газеталары. Шәһәр думасы, Казан һәм вилаять мөселманнарының карашы. Бабаларыбыздан калган әсәрләребезне сагыну. Борынгы Казан шәһәренең урыны, диварлары вә капкалары. Чиркәүгә әйләндерелгән Мөрали [Нургали] мәсҗеде хакында мәгълүмат кайдан алына?

---

[1] Казан мөселман хәрби комитеты — Казан округы мөселман комитеты, 1917-1918 елларда Казан губернасында эшли, рәисе — Х.Сафиуллин.
[2] Бинаән — нигезләп, таянып.
[3] Кыйль-кал — имеш-мимеш.
[4] Голяма — галим.
[5] Тәклиф — көчләп кушу.
[6] Газиз Гобәйдуллин — Гобәйдуллин Газиз (Габделгазиз) Салих улы (1887-1937), тарихчы, әдип, җәмәгать эшлеклесе, профессор.
[7] Русия мөселман укытучылары береге — Бөтенроссия мөселман укытучылары береге, 1917 елның 25 апрелендә Казанда оеша.
[8] Мәркәз — үзәк.
[9] Рәкым — цифр, сан.
[10] Әсас — нигез, база.
[11] Асаре гатика — археологик истәлекләр.
[12] Игътираз — каршы төшү, кире кагу.
[13] Вилаять — өлкә, губерна.
[14] Пайтәхет — башкала.

Габделбарый Баттал

СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ

Бу манара хакында Шиһаб хәзрәт[15], Гайнетдин Әхмәрев[16], Зәки Вәлиди[17] вә Һади Атласов[18] фикерләре. Манараның тарихын тикшерүнең читенлеге. Манара хакында рус мөәррихләре[19] Баженов[20], Рыбушкин[21], Платон Заринский[22], профессор Шпилевский[23]. «Сөенбикә манарасы» мәсҗед манарасымы яки башка максат белән салынган манарамы? Бу хакта Шпилевский, Мәрҗани, Пинегин[24], Атласов, Невзоров сүзләре. Манара хакында дәхи бер мәсьәлә. Манара хакында Платон Заринский, профессор Загоскин[25], Папас [поп] Невзоров фикерләре.

II — Манараны рус әсәре дип дәгъва[26] кылучылар: профессор Эрдман[27], академик В.Суслов[28], Игорь Грабарь[29], П.Дульский[30]. Манараның рус әсәре булуына китерелгән дәлилләр. Стиль мәсьәләсе. Николай Витзен[31] китабындагы Казан манзаралары хакында. Манараның татар әсәре булуына дәлилләр. Князь Курбский[32] сүзе. Авыз риваятьләре. Бу риваятьләр хакында профессор Шпилевский, профессор Загоскин сүзләре. Дәхи Шиһаб хәзрәт. Татар Казанында таш биналарның булуы. Нәтиҗә.

Бу лекциядә Сөенбикә манарасы хакындагы сүзләрнең һәммәсен җыярга тырышылды һәм бер татар угылы тарафыннан ошбу тарихи әсәр хакында җитди бер адым атланды. Әгәр ошбу манара хакында мин күрмәгән мәгълүмат булса, белгән кешеләр өстәрләр.

Г.Баттал.
Казан, 1917 ел, 9 октябрь.

СӨЕНБИКӘ МАНАРАСЫ — ТАТАР ӘСӘРЕ![33]

Мөхтәрәм ханым вә туташлар вә мөхтәрәм әфәнделәр!

Ничәмә-ничә йөз еллардан бирле татар йөрәгендә кадерле бер урын тотып килгән, үзенең газимәте[34] белән урыс Казанына да зиннәт булып торган сәйяхләрнең[35] вә асаре гатика мөхибләренең[36] дикъкатьләрен җәлеп иткән,

[15] Шиһаб хәзрәт — Мәрҗани Шиһабетдин (1818-1889), илаһият галиме,тарихчы, мәгърифәтче.
[16] Әхмәрев Гайнетдин — Әхмәрев Гайнетдин Нәҗметдин улы (1864-1911), тарихчы, археограф, педагог, җәмәгать эшлеклесе.
[17] Вәлиди Зәки — Вәлиди Әхмәтзәки Әхмәтша улы (Тоган) (1890-1970), тарихчы, тюрколог, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе.
[18] Атласов Һади — Атласов Һади Мифтахетдин улы (1876-1938), тарихчы, педагог, җәмәгать эшлеклесе.
[19] Мөәррих — тарихчы.
[20] Баженов — Баженов Николай Кириллович (1804-1848), төбәк тарихын өйрәнүче, надворный советник.
[21] Рыбушкин — Рыбушкин Михаил Самсонович (1792-1849), тарихчы, нашир.
[22] Заринский Платон — Заринский Платон Егорович (1831-1881), тарихчы, дин эшлеклесе.
[23] Шпилевский — Шпилевский Сергей Михайлович (1833-1907), хокук белгече, тарихчы, профессор.
[24] Пинегин — Пинегин Михаил Николаевич (1865-1935), тарихчы, этнограф, җәмәгать эшлеклесе.
[25] Загоскин — Загоскин Николай Павлович (1851-1912), тарихчы, юрист, профессор.
[26] Дәгъва — низаг, тавыш.
[27] Эрдман — Эрдман Фёдор Иванович (1793 яки 1795-1863), шәркыятьче галим, филолог, философия докторы.
[28] Суслов В. — Суслов Владимир Васильевич (1857-1921), архитектор, рәссам, реставратор, академик.
[29] Грабарь Игорь — Грабарь Игорь Эммануилович (1871-1960), рәссам, сәнгать белгече, академик.
[30] Дульский П. — Дульский Пётр Максимилианович (1879-1956), сәнгать белгече, график, педагог.
[31] Витзен Николай — Витзен Николай Корнелий (1641-1717), географ, голландияле сәяхәтче,
[32] Князь Курбский — Курбский Андрей Михайлович (1528-1583), рус кенәзе, воеводасы һәм рус дәүләтенең Казанга 1545-1552 еллардагы яуларын оештыручыларның берсе.
[33] Казанда Дворянское собрание залында 1917 нче ел октябрь 21ендә Г.Баттал тарафыннан укылган лекция. Шул ук елның декабрь 4ендә Уфада Новый клуб залында укылды.
[34] Газимәт — ниятләнү.
[35] Сәйях — сәяхәтче.
[36] Мөхиб — сөюче, яратучы.

татарларның мазыен[37] вә шәүкәтен[38] искә төшерүче бердәнбер ядкәр булган тарихи бер әсәр хакында башлап лекция уку шәрәфе[39] минем өлешемә төште. Мин үземә бөек бер ифтихар[40] санап, сүзгә керешәм.

Казан мөселман хәрби комитеты 1917 нче ел сентябрьнең 2сендәге утырышта «Хан мәсҗеде» (Сөенбикә манарасы) башыннан, корбан гаеденең өченче көнендә (16 нчы сентябрьдә) бөркет сурәтен алып, аның урынына ай куярга карар биргән вә бу карарын 10 нчы сентябрьдә Казандагы Асаре гатика, тарих вә этнография җәмгыяте вилаять комиссары янына, эшче вә солдат депутатлары советына ирештергән иде. Бөркет сурәтен алырга билгеләнгән 16 нчы сентябрь көнендә «Камско-Волжская речь» газетасында профессор Харламповичның ошбу мәкаләсе басылып чыккан иде[41].

СӨЕНБИКӘ МАНАРАСЫНА СҮӘ КАСД[42] [43]

2 нче сентябрьдә Казан мөселман хәрби комитеты Сөенбикә манарасы башындагы бөркет урынына ай куярга карар бирде һәм эшкә дә тотынды инде. 10 нчы сентябрьдә мәзкүр[44] комитет бу хакта бәгъзе бер мәсьәләләрне, шул җөмләдән, Казан Дарелфөнүне хозурындагы Асаре гатика җәмгыятен дә агяһләндерде[45]. Бу мәсьәләгә башка мөәссәсәләр[46] ничек караганнардыр, тарихи бер әсәрнең тышкы сурәтен үзгәртүгә болай сүә касд кылуга каршы игътираз[47] итәргә бертавыштан карар бирде. Бу игътиразны Казандагы руслар һәммәсе котларга тиешледерләр. Эш менә нәрсәдә: Сөенбикә манарасының исеме татарча булса да, аның татар сәнгатенә вә татар Казаны тарихына һичбер мөнәсәбәте юк. Ул, рус мигъмариясенең[48] ядкәредер ки, үзенең стиле белән тәмам Мәскәү Кремленең башняларын искә төшерәдер. Ул унсигезенче гасырда салынган. Голландияле Витзенның 1692 вә 1705тә басылган «Гарби вә шәркый Татарстан» дигән китабына өстәлгән Казан манзарасында ул манзара юк. Димәк, мөселман комитетына ул манараны үзсенергә әсас юк, аның башына мөселман дине галәмәте булган ай куярга исә, әсла юл юк.

Монда мигъмари шәкелләре[49] вә тарихи дәверләрне саташтыру өстенә, рус халкының дәүләт хокукына да тәгъриз[50] буладыр. Чөнки бөркет Русия дәүләтенең гербы бит. Бу дәүләт хозурында төрлечә кимсетелгән вә зәгыйфьләнгән булса да, татар халкына ул дәүләтне ислам диненең җиңү бәйрәмен итәргә иртәрәк әле. Бинаән галәйһи, хәрби комитет үзенең ашыгычлык белән чыгарган рус әһалисенең[51] бер кыйсеме арасында наразыйлык[52] тудырган карарын туктатсын иде. Юкса, соңга калынган булыр.

---

37 Мазый — үткән, кичкән.
38 Шәүкәт — көч, куәт.
39 Шәрәф — кадер, хөрмәт.
40 Ифтихар — мактау, горурлану.
41 Лекциядә рус гәзитә вә китапларындагы сүзләрнең русчалары да укылган иде. Басылганда җиңеллек өчен тәрҗемәләре генә дәрҗ ителде. Г.Б.
42 Сүә касд — явыз ният, теләк.
43 Харлампович К. Покушение на Суюнбекину башню // Камско—Волжская речь. — 1917. — 16 сентября. — С.3.
44 Мәзкүр — югарыда әйтелгән.
45 Агяһләндерү — искәртү.
46 Мөәссәсә — оешма.
47 Игътираз — кире кагу, каршы төшү.
48 Мигъмари — төзүчелек.
49 Шәкел — форма, тышкы күренеш.
50 Тәгъриз — ризасызлык белдерү.
51 Әһали — халык.
52 Наразыйлык — ризасызлык.

АРХЕОЛОГИЯ ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ ИГЪТИРАЗЫ

Шул ук 16 нчы сентябрь көнендә Асаре гатика, тарих вә этнография җәмгыяте тарафыннан мөселман хәрби комитетына түбәндәге игътираз җибәрелгән иде.

Мөселман хәрби комитетының быел 10 нчы сентябрьдә, 982 нче номерлы кәгазь җибәреп, Сөенбикә манарасындагы бөркет урынына ай кую хакындагы мөрәҗәгате мөнәсәбәте илә, Казан дарелфөнүне хозурындагы Асаре гатика, тарих вә этнография җәмгыятенең советы түбәндәге фикерне әйтүне тиешле таба:

1 — Асаре гатика, тарих вә этнография җәмгыяте Идел-Кама буйларындагы борынгы әсәрләрне күзәтеп торганлыгыннан, комитетның дикъкатен шуңа җәлеп итәдер ки, Казан губерниясендәге борынгы әсәрләрне төзәтү (ремонт ясау), әгәр Петроградтагы Асаре гатика комиссиясеннән махсус рөхсәт алынган булса, Асаре гатика җәмгыятенең рәһбәрлеге[53] астында гына мөмкин.

2 — Сөенбикә манарасы Казандагы борынгы каләме[54] мәшһүр бер әсәр. Ләкин ул хәзерге рәвештә әсла татар әсәре түгел. Ул үзенең стиле вә салыну рәвеше белән, Мәскәү Кремленең манараларын, Боровецкая башняны искә төшерә. Шунлыктан, сәнгать тарихын язучылар, ул манараны, XVII йөзнең ахыргы яртысында салынган дияргә маэлдерләр (Грабарьның «Сәнгать тарихы», 2 том, 324 бит[55]; Сусловның «Борынгы рус мигъмарисенең ядкәрләре» дигән китабы 7 җилд[56], Дульский «Казанның иске заманнан калма ядкәрләре», 1914тә басылган, 7 вә 8 битләр[57]).

Голландияле Витзенның 1692-1705 нче елларда басылган «Шәркый вә гарби Татарстан» дигән әсәрендәге Казан манзараларында бу манара булмаганлыгыннан, ул манараның салынуы, әлбәттә, 1705тән соңгы вакытларда буладыр. Шулай да 1767 нче елдан да соң салынмаган, чөнки шул елны Лиспинис тарафыннан тәрсим[58] ителгән Казан рәсемендә ул манара күренә (Дульский, 5 нче бит[59], Харлампович. Библиографическая заметка о книге Дульского).

Казанның күп яшәгән карты Н.Я.Агафонов бу манараның салынуын XVIII нче гасырның соңгы яртысына нисбәт бирә[60]. Кайбер мөәррихләр Анна Ивановна заманында салынган, диләр. Бинаән галәйһи[61], манараның нигезе генә яки, ихтимал, беренче каты гына татар хөкүмәте заманыннан калган дип фараз кылырга мөмкин.

3 — Менә шул әйтелгән сәбәпләр бинаән, Казан татарлары ай куеп вә тәгъмир[62] итеп, ошбу борынгы бинаның тышкы сурәтен үзгәртергә касд итмәскә тиешледерләр.

Игътиразның фәнни вә тарихи кыйсеме шунда бетә. Моннан соң тарих вә асаре гатика галимнәре сәяси сатыхка[63] күчеп, әйтәләр:

---

[53] Рәһбәр — җитәкче, юл күрсәтүче.
[54] Каләм — стиль.
[55] Грабарь И. История русскаго искусства. Т.II. Архитектура. Допетровская эпоха. — М., [1910]. — С.324.
[56] Суслов В.В. Памятники древнего русского зодничества. Издание Императорской Академии Художеств.— С.Петербург.— 1901.— Выпуск седьмой. — Л.13.
[57] Дульский П. Памятники Казанской старины.— Казань. — 1914. — С.20.
[58] Тәрсим — рәсем ясау, сызу.
[59] Дульский П. Памятники Казанской старины. — Казань. — 1914. — С.5.
[60] Агафонов Н. Материалы к вопросу о переименовании улиц города Казани. Историческая объяснительная записка наименования Казанских улиц.— Казань: Типография губернского правления.— 1899. — С.30.
[61] Бинаән галәйһи — шуңа күрә.
[62] Тәгъмир — төзү, төзәтү.
[63] Сатых — яссылык.

4 — Манарадан бөркетне алырга комитетка хәзерге революция көннәрендә һичбер әсас юк: бөркет, гомуми дәүләт билгесе булып, империя билгесе түгелдер; ул, Романовлар сөяләсе[64] белән дә багланмаган. Революция мәйданга китергән Мәүкыйт[65] хөкүмәтенең зур мөһерендә бөркет сурәте бар (тик таҗ гына юк). Бөркет дәүләтнең берлеге, газамәте[66] вә кәмаләтенең[67] шигаре[68]. Әгәр татарлар ул берлек вә газамәткә касд кылырга теләмәсәләр, ул шигар алар өчен дә лязем нәрсәдер.

5 — Әмма манара башына ай куярга комитетның хакы бигрәк тә юк. Ай татарларның милли шигаре булган тәкъдирдә дә, Сөенбикә манарасы хәзер дә бит элекке шикелле үк бөтен Казан шәһәренең вә аның аркылы бөтен Русия җөмһүриятенең милкедер. Ай кую Казанның православный рус әһалисендә нинди фикерләр кузгатмас? Бу эш татар тәслите[69] исламның истиля[70] планнары хакында шәигалар[71] күтәрмәсме? Бу хәл ансыз да партияләргә бүленеп беткән Казан шәһәре халкы арасында мөнәсәбәтләрнең начарлануына сәбәп, үзара сугыш кузгатуга сылтау булмасмы? Асаре гатика җәмгыяте советының бу куркулары граждан-лык тойгыларыннан гына килми, бәлки халык арасындагы тынычсызлыкларның борынгы әсәрләргә зарар китерү ихтималы да аны хәвефкә төшерәдер, чөнки андый әсәрләрне саклау Асаре гатика җәмгыяте вазифасы.

Бу мөрәҗәгать Казан вилаять комиссариатына һәм Шәһәр Думасына җибәрелде.

Асаре гатика, тарих вә этнография җәмгыяте рәисе М.Хвостов.

Сөенбикә манарасыннан бөркетне төшерү хәзерлекләре күрелгән чакта, мәсьәләгә вилаять комиссары катышып, Мөселман хәрби комитетын ул эштән туктатырга теләгән иде. Ләкин хәрби комитет бу игътиразлар вә мәддахларның[72] берсенә дә илтифат итмәде, үзенең карарыннан ваз кичмәде. Бөркетнең татар солдатлары тарафыннан нинди батырлык вә гайрәт белән төшерелгәнлеге татар газеталарында мөфассал[73] рәвештә язылып үтте. Бөркетне төшерүдә зур фидакарь-лек вә батырлык күрсәтүчеләр солдат Габдулла Исмәгыйлев, тупчы Лотфирахман Габдрахманов, артист Газибәк Салтыковский һәм вәиси Ибраһим Зәйнуллин булды.

Сөенбикә манарасыннан бөркетне төшерү тантанасында хазир булган мөселманнарның рухлары бик күтәренке, алар өчен бүгенге көн бер гадәттән тыш шатлык вә милли бәйрәм көне иде...

Казан урыслары мәсьәләгә бик әһәмият бирделәр. «Казан татарларының тарихи Сөенбикә манарасыннан рөхсәтсез-нисез дәүләт гербы булган орелны төшерүләре» хакында моннан телеграф белән пайтәхеткә хәбәр ителде.

21 нче сентябрьдә шул ук мәсьәлә Шәһәр Думасы мәҗлесендә дә каралды. Ул мәҗлескә руслар бөтен гыйльми вә сәяси көчләрен мобилизовать итеп килгәннәр иде. Профессор Хвостов манараның татар әсәре булмавы хакында озын нотык сөйләде, профессор Гольд-Гаммер, инспектор Юшков мәсьәләгә сәяси ноктаи нәзардан[74] карап кызу вә отышлы нотыклар сөйләделәр, бу нотыклар тәэсире

[64] Сөлялә — династия, нәсел.
[65] Мәүкыйт — вакыт, срок.
[66] Газамәт — бөеклек.
[67] Кәмаләт — өлгергәнлек, җитешкәнлек.
[68] Шигар — билге.
[69] Тәслитъ — власть, хакимлек.
[70] Истиля — басып, алу, җәелү.
[71] Шәига — хәбәр, вакыйга.
[72] Мәддах — арттырып сөйләү.
[73] Мөфассал — тулы, җентекле.
[74] Нәзар — фикер, караш.

белән урыс милләте гласныйлары бик кызганнар иде. Боларның атышын мөселман гласные Фоад Туктаровның нотыгы гына басты. Соңра «Р[усское] С[лово]» газетасының 224 нче номерында татарның Сөенбикә манарасыннан орёлны алуларыннан, аның башына ай куярга теләүләреннән көлеп бер мәкалә язылган. Шунда «Безнең тавыш»тан күчерелеп, «Кояш» газетасының 1163 номерында басылган шигырьнең[75] тәрҗемәсе кертелгән. Мәкаләсенең ахырында «Р[усское] С[лово]» мөхбире: «Так Казанские татары лягнули русскую государственность[76]», — дип куя.

Бу мәсьәлә октябрь башларында Археология җәмгыятендә дәхи дә телгә алынды. Җәмгыять рәисе профессор Хвостов татарлар тарафыннан Сөенбикә манарасыннан орёл алынган көннәрдә җәмгыять советының ниләр эшләгәнлеге хакында хәбәр итте. Гарәп Жузе айның мөселман дине галәмәте булмыйча, төрек солтанының гербы булуы, бинаән галәйһи, татарлар, үзләрен бер дәүләтнең садыйк[77] гражданнары санаган хәлдә, икенче бер дәүләтнең галәмәтен алга сөрүләре урынсыз булуы хакында сүз сөйләде. Профессор Харлампович «Кояш»та басылган шигырьнең русча тәрҗемәсен укып, җәмгыять әгъзаларын хәбәрдар итте.

Сөенбикә манарасыннан бөркетне алуга Русиянең төрле урынындагы мөселманнарның бик яхшы караганлыклары вә аннан шатланганлыклары аңлашыла. Ошбу мөнәсәбәт илә, Мөселман хәрби комитетына түбәндәге урыннардан котлау телеграмы килгән: 1) Баку төрек федералистлары партиясе вә «Мөсавәт[78]» җәмгыяте рәисе Мөхәммәдәмин Рәсүлзадә әфәндедән; 2) Баку мөселман комитеты рәисе Галимәрданбәк Тубчибашевтан; 3) Җидесу вилаятендәге Тукмак «Шураи ислам» рәисе Сатыбалдиннан котлау телеграмы белән бер мең сум акча; 4) Петропавелдан; 6) Нахичеваньнан төрек федералистларыннан; 7) Кавказ җәмгыятеннән тарихи бер ядкәрләрне яңарту өчен рәхмәт телеграмы вә 300 сум акча; 8) Ташкент төрек федералистларыннан рәхмәт телеграмы; 9) Самар мөселманнары хәрби комитеты котлар өчен махсус кеше вә 621 сум 12 тиен акча җибәргәннәр.

Кирәк Казан татарларының бөркет төшергән көндәге шатлыклары, кирәк вилаятьләрдәге мөселманнарның бу эшкә зур бер вакыйгага караган күз белән караулары, күрсәтәдер ки, Русиядәге төрек-татарлар үзләренең тарихи әсәрләренә әһәмият бирәләр вә аларга хөрмәт итәләр икән. Һәм, вакыйган, аз гына татарлар тарихыннан хәбәрдар булган, хәзерге Казан губернасында Казан падишаһлыгы вә шул губернаның баш шәһәре урынында ул падишаһлыкның Казан исемле пайтәхете булганлыгын белгән һәрбер татар угылы вә кызы үз-үзенә: «Соң ул пайтәхет Казан шәһәре кая киткән, безнең татарыбыздан нигә бер дә әсәрләр, гыймарәтләр[79]-фәләннәр калмаган?» — дигән сөальләр бирә, йөрәгендә бераз гына милли тойгы булган, милләтенең мазые-тарихы белән интересланган һәрбер татар баласы бабаларыннан калган әсәрләрне сагына, шуларны күрәсе килә. Һич булмаса, үзенең иске тарихи исемен саклаган, Казанга читтән килгән аңлы татар баласы һәрнәрсәдән элек бу шәһәрдә татар әсәре, татар ядкәре эзли.

Мин уйлыймын ки, Сөенбикә манарасы хакындагы лекцияне тыңлар өчен, ошбу залга җыелган татар балаларының һәркайсының йөрәгендә шул сөальләр[80] саклана торгандыр, алар, әлбәттә, монда шул сөальләргә җавап эзләп килгәннәрдер; бу аудитория, шөбһәсез, миннән шул җавапны көтә.

---

[75] Сөембикә манарасы төбендә гаед // Кояш. — 1917. — 21 сентябрь. — Б.З.
[76] Татары. Башня Сююмбеки // Русское слово. — 1917. — 1 октября (№224). — С.6.
[77] Садыйк — туры, чын.
[78] Мөсавәт — тигезлек, бердәйлек.
[79] Гыймарәт — корылма.
[80] Сөаль — сорау.

Менә шул сәбәпле, мин, бу көнге лекциянең мәүзугы[81] булган Сөенбикә манарасы хакында сүзгә керешүдән элек, борынгы Казан шәһәре һәм чиркәүгә әйләндерелгән «Мөрали (Нургали) мәсҗеде» хакында бераз сүз кылачакмын.

БОРЫНГЫ КАЗАН ШӘҺӘРЕ ХАКЫНДА

Мәгълүмегездер ки, бу ел шушы октябрьнең 2сендә Казан алынганга 364 ел тулды. Бу мөддәт[82] эчендә Казан шәһәре шулкадәр үзгәргән ки, хәзер борынгы татар Казанының нинди кыяфәттә булуын тасвир итү (күз алдына китерү) дә мөмкин түгел.

Русиядә сәяхәт кылган саксонияле Адам Олеарий дигән кеше 1636 нчы елда Казанның агач диварларын, шәһәр әйләнәсендәге манараларын күргән[83].

XVIII гасырның 60-70 елларында диварның урынын билгеләү читен булган: шул чорлардан Казан гимназиясенең директоры фон Каниц мәшһүр «Россиада»ны язучы Херасковның тәкълифе[84] белән тәфтишат[85] ясаганда[86], бу мәсьәләдә читенлеккә очраган. Шул Каниц, ул чактагы эзләр, билгеләр вә аваз риваятьләренә таянып, борынгы Казанның планын ясап калдырган.

Казан урыс кулына кергәч тә, аның тышкы кыяфәте үзгәрә башлаган. Казанны алучы Иван Грозный андагы татар гыймарәтләрен, татарларны искә төшерә торган башка әсәрләрне бар гайрәте белән җимерттереп ташлаган. Бу сүз коры бер дәгъвадан гына гыйбарәт булмасын, татарлык тәгассыбы[87] белән генә әйтелгән дип уйланмасын өчен, кайбер урыс мөәррихләренең сүзләрен китерәм: профессор Н.Загоскин әйтә: «Татарлардан калган гыймарәт әсәрләренең булмавына килсәк, аның сәбәбе — Казанны 1552 нче елда мөхасарә[88] иткән чакта, хосусан, 2 нче октябрьдә штурм (һөҗүм) ясаган чакта, шәһәрнең гаять нык җимерелүедер. Казанны алганнан соң да руслар, киләчәк нәселләрнең тарихи интересларын игътибарга алудан бигрәк, тәкъвалыкка[89] зур әһәмият биреп, башта Казанның татар дәверен искә төшерерлек һәммә нәрсәләрне бик дикъкать белән юк итәргә тырыштылар. Дүртенче Иван (Грозный) Казандагы һәммә мәсҗедләрне бетерергә фәрман чыгарды, яңаларын салудан тыйды. Аның бу эше XVI йөзнең ахырында угылы Фёдорның боерыгы белән ныгытылды[90].

Рыбушкин дигән урыс мөәррихы «История Казани» дигән китабының беренче җилдендә[91] әйтә: «Казанны алучы дәһшәтле патша, Казандагы йортларны юк итү белән генә калмады, бәлки гыйбадәтханәләрне, ханнарның каберләренә кадәр туздырып ташларга кушты, шәһәр эчендәге кайбер мәсҗедләрне җимерде, кайсыларын чиркәүгә әйләндерде»[92].

Янә 1856 нчы елгы «Каз[анские] губ[ернские] вед[омости]» газетасында «Ка-

---

[81] Мәүзугъ — тема, проблема.

[82] Мөддәт — ара, вакыт.

[83] Оларий А. Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию и обратно. СПб., 1906. — С.370.

[84] Тәкълиф — кушу.

[85] Тәфтишат — тикшерү, эзләү.

[86] Херасков М.М. Россиада. С.Петербург: Типография Глазунова, 1895. — С.[VII].

[87] Тәгассыб — фанатизм.

[88] Мөхасарә — басып алу.

[89] Тәкъва — дин кушканны эшләү.

[90] Загоскин Н.П. Спутник по Казани. — Казань: Типо-литография Императорского Университета.— 1895. — С.92.

[91] Җилд — том.

[92] Рыбушкин М.С. Краткая история города Казани. — Казань. — 1848. — С.35.

кой вид имела Казань в XVI веке» дигән мәкаләләр язган кеше әйтә: «Шәһәрдән татарларны куып чыгару вә мәсҗедләрне җимереп ташлау, 1555 нче елда таш крепость, чиркәүләр, татар йортлары урынына рус йортлары салу, бистәләрнең (слободалар) мәйданга килүе — һәммәсе Казанның күренешен үзгәртте»[93].

Монда «бистәләр-слободаларның мәйданга килүе» диелгән. Вакыйган, Казан урыс кулына кереп, бераз торгач та, Болакның аръягында Архиепископская, Ямская, Мокрая дигән слободалар, Проломный урамдагы биек чиркәүнең җәнүбендә[94], иске татар зираты янында «Кирпичная» дигән слобода, Арча кырында Горшечная, Солдатская, Красная дигән слободалар, хәзерге Пятницкая чиркәү янында Глядкова дигән слобода пәйда була.

Казанда еш булып торган зур янгыннар шәһәрнең үзгәрүенә күп ярдәм иткәннәр. 200 ел эчендә (1552-1757) Казанда гаять зур алты пожарлар булган. XIX гасырның яртысына кадәр, ягъни, 300 ел эчендә булган янгыннар саны 10 га тула. Ягъни, 30 елга бер янгын туры килә. 1742 нче елда шәһәрнең мәркәз урыннары янып беткән. 1749 нчы елда бөтен шәһәр диярлек янып беткән.

Ниһаять, Пугачёв фетнәсе борынгы Казанны искә төшерерлек һәммә әсәрне бәрбад[95] иткән. Пугачёв һөҗүме мәзкүр слободаларның да югалуына сәбәп булган, тик кайберәүләренең урамнарга бирелгән исемнәре генә калган. Янып, җимерелеп, тар-мар ителгән Казан, Икенче Екатеринаның (Әби патша) боерыгы белән бөтенләй яңа план белән торгызылган. Шул кыяфәт аз гына үзгәреш белән әле дә саклана.

Хәзерге Казан Әби патша әсәре саналса, урыны бар. Хәзерге чикләре белән Казан губернасын мәйданга китерү дә аның эше бит.

XVI гасырдагы татар Казаны бөтенләй җир йөзеннән югалган, дияргә мөмкин. Хәзер никадәр тырышып эзләсәк тә, татар әсәре табу бик читен.

Борынгы Казан шәһәре хәзерге Казаннан бик күп кечкенә иде. Болакның Казан елгасына кушылган урыныннан башлап, Болакны уң кулда калдырып, аның буйлап, аннан акрын-акрын еракләша барып, Балык базары мәйданына хәтле килегез дә, аннан сулга борылып, Балык базары урамы белән югары таба китегез, Николайская площадь бакчасыннан чыгып, Державин бакчасын уңга калдырып, почта алдыннан узып, Касаткин урамы белән төшеп, Нижний Фёдоровский, Засыпкин урамнарын кичеп, крепость асты белән барып, кузгалып киткән урыныгызга, ягъни, Болак белән Казан елгасы кушылган урынга барып туктагыз. Мәгълүмдер ки, шул сез әйләнеп чыккан даирә хәзерге көндә шәһәрнең беренче часте дип йөртелә. Борынгы Казан шәһәре менә шул беренче частьнең урынын гына әшгал[96] итә иде. Шәһәр өч өлешкә бүленеп, беренче өлеше хәзерге крепость урынында булып, калган ике өлешеннән «Таҗик ермагы» дигән тирән чокыр белән аерыла иде. Бу ермак, мәсәлән, Ташаяк ярминкәсе урыннарыннан башланып, хәзерге управа алдындагы Александрийский мәйданыннан үтеп, Казан елгасына барып тоташкан. Управа бинасы артында бу чокырның калдыгы әле дә бар. Мәгълүмдер ки, хәзерге крепость бик калку урында тора. Хан сарайлары, ханнарның төрбәләре, шәһәрнең иң шәп мәсҗедләре — һәммәсе шунда иде. Князь Курбский әйтүенә бинаән, бу мәсҗедләрнең бише таштан булып, күккә чыккан биек манаралары әллә кайдан ерактан, Казанның мөселман шәһәре икәнлеген күрсәтеп торалар иде[97]. Казан Идел буенда чынлап та күрекле вә мәһабәт бер

[93] Исторические очерки Казани // Казанские губернские ведомости. — 1856. — 13 августа (№33). — С.253.
[94] Җәнүб — көньяк.
[95] Бәрбад — юкка чыгару.
[96] Әшгал — шөгыль.
[97] Курбский А.М. История о великом князе Московском // Сочинения князя Курбского. СПб. — 1913.— С.21.

шәһәр иде. Бу һәм татар тәгассыбы белән генә әйтелгән бер сүз дип уйланмасын өчен, бу хакта бер урыс мөәррихының сүзен күчерәм. 1852 нче елгы «Каз[анские] губ[ернские] вед[омости]» газетасында, Казан алынуга 300 ел тулу мөнәсәбәтле мәкаләләр язган мөәррих әйтә: «Кальга эчендә, хосусан хәзерге Кремль торган тау өстендә, биек таш мәсҗедләр вә хан сарайлары бар иде. Шул мәсҗед вә сарайлар белән бизәлгән Казан, аз вә тынычсыз яшәсә дә, байтак шөһрәт алып өлгергән падишаһлыкның «менә дигән» нәмаендәсе булып, дикъкатьләрне җәлеп итеп тора иде»[98].

Шәһәрнең икенче өлеше хәзерге Воскресенский урам яктан тау өстендә вакыйгъ булып, хәзерге Управа, музаханә алдыннан башлана, хәзерге Университетский урамга килеп терәлә иде. Воскресенский урам тавы бер бите белән Болакка таба, бер бите белән Черек күл дип аталган вә рәттән тезелеп киткән күлләргә иңә иде. Бу күлләр хәзерге Николаевский площадь бакчасыннан башлап, хәзерге Управа артларына кадәр сузылалар иде. Воск[ресенский] урам тавының җәнүб як битенең текәлеге хәзерге шикелле Проломный урамда бетми, бәлки Болакка якынрак җиргә бара иде. Болакның үзе хәзерге шикелле җәй көне сасып ята торган бер канау булмыйча, аз сулы, сай гына бер елга иде, буйлары үтә алмаслык сазлык иде.

Шәһәрнең өченче өлеше Черек күлләр һәм Казан елгасы арасында, ягъни хәзерге көндә Черноозёрская, Покровская, Большая Казанская, Нагорная, Попова гора дигән урамнар әшгал иткән урыннарда вакыйгъ иде. Беренче өлешнең өч яктан үз алдына дивары булган кеби, шәһәрнең калган ике өлеше дә дивар белән әйләндереп алынган, дивар ташында исә, бер якта баткаклы Болак, бер ягында бик ярлы Казан елгасы, әмма шәһәрнең кояш чыгышы ягында, хәзерге Рыбнорядская урам, Николайская площадь бакчасы, Театральная урам, Касаткин урамы урыннарында гаять тирән чокыр казылган иде.

Казанның дивары — кальгасы гаять калын имән бүрәнәләрдән ясалган иде, ясалышы менә бу рәвешчә иде: калын имән бүрәнәләрдән, киңлеге дүрт сажин кадәрле буралар бурап, шул бураларны рәттән тезгәннәр дә, шул бураларны куыш калган очлары таш, ком вә балчык белән тутырылган иде. Диварларның өстендә, тышкы кырыенда шәһәрне саклаучыларга сакланыр өчен юка гына агач койма ясалган иде. Агач кальганың тиз януы мөмкин булса да, шәһәрне сакларга аның да күп ярдәме тия иде. Кальганың өстенә баскыч куймыйча менәргә мөмкин түгел иде, әмма баскыч кую бик читен була иде, чөнки сакчыларның кулында дошманны кальга янына якын җибәрмәскә җитәрлек төрле чаралар күп була иде: диварга якын килгән кешеләрнең өстенә таш, кыздырылган ком, кайнар су, эссе май, күкерт, сумала кебек нәрсәләр явып тора иде.

Кальганың урыны-урыны белән капкалары, манаралары бар иде. Манаралар һәр дивар өстенә җирләштерелгән дүртпочмаклы буралардан гыйбарәт, өсләре дүрт битле текә түбә белән капланган була иде, түбән яклардан тар гына ишекләр булып, югарыларында атар өчен тар гына, озынча тәрәзәләр күп иде.

Казан кальгасының менә ошбу капкалары бар иде.

1 — Арча капкасы. Хәзерге почта конторы алдында, Покровский урамының Театр мәйданына чыккан җирендә иде. Ошбу капка мөнәсәбәте илә, Покровский урам, Пугачёв килгәнгә кадәр, Арская (Арча урамы) дип аталган иде. Себер юлы да XVI гасырда «Арча юлы» дип йөртелгән.

2 — Хан капкасы. Арча капкасының җәнүб гареби[99] ягында, хәзерге Николаевская площадь бакчасының кояш чыгышы читендә булган, дип уйлана.

[98] Казанские губернские ведомости. — 1852. — 13 августа.
[99] Гареб — көнбатыш.

3 — Аталык капкасы. Хәзерге Мало-Проломный урамының Балык базарына чыккан башында булгандыр, диләр.

3 — Нугай капкасы. Хәзерге Проломный урамдагы биек чиркәү (Богоявлинская чиркәү) урынында булган. Урыс гаскәре элек Казанның шул капкасын ватарга муафикъ булганлыгыннан, урыслар ул капканы «Проломная ворота» дип атаганнар, «Проломный урам» исеме дә шуннан калган.

5 — Мөрали [Нургали] капкасы. Хәзерге көндә крепость эченнән, Казан елгасы өстендәге күпергә таба чыга торган, хәзерендә Тайницкая ворота дип йөртелгән капка урынында булган.

6 — Алабуга капкасы. Хәзерге Пятницкая чиркәве тирәсендә булган. (Бу чиркәү Большая Казанская һәм Нагорная урамнар барып чыккан мәйданда, Богородицкий кызлар монастыре янында тора).

7 — Забайлы капкасы. Евдокинский чиркәү якынында булган. Бу чиркәү Поперечно-Казанская, Нижне-Фёдоровская, Засыпкин урамнарының кавышкан урыннарыннан вакыйгъдыр.

8 — Кайбат капкасы. Попова гора урамы тирәсендә булгандыр, дип уйлана.

Менә борынгы Казанның төрле тикшерүләр нәтиҗәсендә табылган капкалары шулар. Шуны да әйтеп китәргә тиештер ки, бу капкаларның саннары, исемнәре вә урыннары тәкърибиᅟ[100] генәдер. Бик мөмкиндер ки, болардан башка да капкалар булгандыр. Бик мөмкиндер ки, болардан башка кайберәүләрнең исемнәре башкарак булгандыр, кайсылары монда күрсәтелгәннән башкарак урында булгандыр.

Кальга тышында хәзерге Фуксовский бакча янында, Казан елгасының яры өстендәге кызлар Фёдоровский монастыре урынында бер бистә булган, аның дивар-фәләне булмаган.

Үзебезгә мәгълүм, хәзерге көндә диварлар да юк, теге бистә дә юк. Соң татарлардан калган нинди әсәрләр бар?

Татар әсәре икәнлеге дә ихтилаф[101] булмаган бер бина, хәзерге көндә крепость эчендә сабикъ[102] губернатор сарае белән тоташ булган Дворцовая церковьтыр. Ни өчендер, безнең мөәррихләребез чиркәүгә әйләндерелгән бу мәсҗедкә күп әһәмият бирмәгәннәр. Зәки Вәлиди бу әсәрне телгә алмый, Һади Атласов: «Борынгыда аның (Сөенбикә манарасы) янында бер мәсҗед булган, Казан алынгач, аны чиркәүгә әйләндергәннәр, ул мәсҗеднең кайсы мәсҗед булганлыгы ачык мәгълүм булмаса да, Мөрали [Нургали] мәсҗеде дип аталган мәсҗед булучылыгы аңлашыладыр»,[103] — дип кенә икътифа[104] итә, Мөрали [Нургали] мәсҗеденең хәзерге Сарай чиркәвенең үзе икәнлеген ачык әйтми.

Милли мөәррихләребездән бу турыда ачыграк сөйләгән кеше — Гайнетдин Әхмәревтер. Ул әйтә: «Шул манарага таш баскыч белән тоташтырылган янә бер иске бина бар, ул әүвәлге хан мәсҗеде[105] булып, Казан алынганнан соң, кәнисәгә әйләндерелгән XIX гасыр әүвәлендә ул бинаны кәнисәлектән чыгарып, дары мәхзәне ителгән; шул XIX гасырның урталарында ул бинаны төзәттереп, Губернатор сараена махсус кәнисә ителгән, чөнки 1847 нче елда аның янына Губернатор сарае бина кылынган»[106].

Бу турыда урыс мөәррихләре ни әйтәләр? Аларны тыңлап карыйк.

---

[100] Тәкърибиᅟ — якынча.
[101] Ихтилаф — каршылык.
[102] Сабикъ — әүвәлге.
[103] Атласи Һ. Сөенбикә. — Казан: Типо-литография «Өмет». — 1914.— Б.61.
[104] Икътифа — иярү.
[105] Мәхзән — склад.
[106] Әхмәрев Г. Казан тарихы. — Казан: «Бәянелхак».— 1909.— Б.108-109.

МӨРАЛИ [НУРГАЛИ] МӘСҖЕДЕ – ДВОРЦОВАЯ ЧИРКӘҮ

Профессор Загоскин әйтә: «XVI йөзнең өченче чирегендә тәртип ителгән Писц[овая] книгада, Св[ятая] Благовещения (хәзерге кафедральный собор) каршысында, корал складына әйләндерелгән бер мәсҗед булганлык әйтелә. Әмма, 1768 елдан төзелеп, Казан дарелфөнүнендә сакланган иске бер Казан планында, хәзерге Дворц[овая] церковь урынында мәсҗедтән әйләндерелгән, ул чакта искергән бер чиркәү күрсәтелә. Бу хәбәрләрне чагыштыргач, аңланадыр ки, монда сүз хәзерге Дворцовая чиркәү хакында бара. Димәк, ул чиркәү электә мәсҗед, соңрак корал складлы, аннары XVIII гасырның соңгы яртысында искергән чиркәү булган була. XIX гасырның 40 нчы елларында исә тәгъмир ителеп, хәзерге чиркәү халәтенә китерелгән», – дигәннән соң әйтә: «Менә шулай, хәзерге Кремль эчендәге Сарай чиркәвен, татар Казаны заманындагы архитектура ядкәрләреннән санарга бик нык әсас бар һәм аның Казан алуны сөйләгән китапларда яд ителгән бер кальга бинасының Мөрали [Нургали] капкасы дип аталуына сәбәп булган Мөрали [Нургали] мәсҗеденең үзе булуына бик көчле дәлилләр бар»[107].

С.Шпилевский җәнаблары Виконт де Жульвигур дигән кешегә әснад итеп әйтә: «Сөенбикә манарасы янындагы бинаны Жульвигур «мәсҗед» дип бара һәм ул: бу бина, тышкы кыяфәте белән бөтенләй мәсҗедкә охшый һәм аның манара белән бер стильдә булуы вә бер заманда салынуы күренеп тора»[108].

Баженов дигән кеше Каз[анская] история» дигән китабында ошбу чиркәү хакында: «Ул электә баш мәсҗед иде», – ди [109].

Профессор Шпилевский бу хакта байтак сүзләр күчергәннән соңра болай ди: «Димәк, Сөенбикә манарасы янындагы хәзерге Сарай чиркәве башта мәсҗед булган, Казан алынгач, православный чиркәвенә әйләндерелгән. XIX гасыр башында аның чиркәүлеге бетерелеп, ул бина дары мәхзәне булып хезмәт иткән. 50 нче елларда электә мәсҗед булган бина, дәхи христиан гыйбадәтханәсе булып әверелгән. Менә шул бина нәкъ «Мөрали [Нургали] капкасы» дип аталадыр»[110].

Баженов дигән кеше «Каз[анская] история» дигән китабында ошбу чиркәү хакында: «Ул электә баш мәсҗед иде», – ди[111].

Профессор С.Шпилевский бу хакта байтак сүзләр күчергәннән соңра болай ди: «Димәк, Сөембикә манарасы янындагы хәзерге Сарай чиркәве башта мәсҗед булган, Казан алынгач, православный чиркәвенә әйләндерелгән. XIX гасыр башында аның чиркәүлеге бетерелеп, ул бина дары мәхзәне булып хезмәт иткән. 50 нче елларда электә мәсҗед булган бина, дәхи христиан гыйбадәтханәсе булып әверелгән». Менә шул бинаны нәкъ «Мөрали [Нургали] мәсҗеде» дип әйтергә ярый. Шул тирәдәге кальга капкасы да «Мөрали [Нургали] капкасы» дип аталадыр[112].

Күрәсез, монда мәсҗед Казан алынгач та чиркәүгә әйләндерелгән, соңрак дары мәхзәне булган, аннары дәхи чиркәү булган, диелә. Әмма профессор Загоскин

---

[107] Загоскин Н.П. Спутник по Казани.– Казань: Типо-литография Императорского Университета.– 1803. – С.100.

[108] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. – Казань: Типогрфия Казанского университета. – 1877. – С.471.

[109] Баженов Н.К. Казанская история. Ч.3. – Казань: Типография Казанского университета.– 1847.– С.26.

[110] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. – Казань: Типогрфия Казанского университета. – 1877. – С.471.

[111] Баженов Н.К. Казанская история. Ч.3. – Казань: Типография Казанского университета. – 1847. – С.26.

[112] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. – Казань: Типогрфия Казанского университета. – 1877. – С.472.

элек корал склады, соңрак гади чиркәү, аннары Сарай чиркәве булган, дигән иде, ләкин ничек кенә булганда да, безнең максат чыга: һәр ике профессорның сүзеннән мәсҗеднең чиркәүгә әйләндерелгәнлеге аңлашыладыр[113].

Шул Дворцовая чиркәүнең папасы [побы] П.Невзоров «История Сююнб[екиной] башни» дигән рисаләсендә әйтә: «Чынлап та Дворцовая чиркәүгә бер күз салу белән аның (гәрчә ул берничә янгынга дучар булса да) мәсҗедкә охшавы күренеп тора. Хосусан, түбәсенә кадәр булган урыны. Аның манара белән бер стильдә һәм бер вакытта салынганлыгы да ачык күренә[114].

П.Дульский үзенең «Памятники Казанской старины» дигән китабында туп-туры: «Хан сарае белән беррәттән биш мәсҗед бар иде. Шуларның «Мөрали [Нургали] мәсҗеде» дигәне соңыннан Дворцовая чиркәүгә әйләндерелгән»[115], — ди.

Инде ошбу сөйләгәннәрдән хәзерге Дворцовая церковь дип аталган, сабикъ губернатор сарае белән тоташ, Сөенбикә манарасына күрше булган чиркәүнең бер вакытлар «Мөрали [Нургали] мәсҗеде» булганлыгы яхшы аңлашылган булса кирәк.

Ахыры киләсе санда

*Текстны һәм искәрмәләрне басмага **Җәүдәт Миңнуллин** һәм **Энҗе Сабирова** әзерләде.* ■

Г.БАТТАЛНЫҢ «СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ» ХЕЗМӘТЕ ХАКЫНДА

Җәүдәт Миңнуллин

Кешелек дөньясы символларсыз яши алмый. Борын-борыннан кешеләр берәр идеяне яки абстракт төшенчәне белдергән шартлы билге рәвешендә төрле нәрсәләрне хөрмәт иткән, аларга табынган һәм саклаган.

Татар халкының да символ ролен уйнаган ядкәрләре бар. Шуларның берсе — Сөембикә манарасы. Кайсы дәвердә салынуы хакында фәндә хәзергә кадәр төрле фикерләр яшәп килсә дә, татар аны һәрвакытта үзенеке санаган һәм саный. Әдәби әсәрләрдә, халык авыз иҗатында һәм халык хәтерендә ул менә ничә гасыр инде татарлык символы буларак кабул ителгән. Татар халкы тарихи барышның төрле дәверләрендә дә Казаныбызны бизәп торган бу серле бинага битараф калмаган. Милли азатлык хәрәкәте көчәйгән чорларда ул һәрвакытта игътибар үзәгендә була. Болгавыр 1917 елның 2 сентябрендә Казан мөселман хәрби комитеты Сөембикә манарасы башындагы каракошны алырга карар чыгара. Шул ук вакытта монархистик көчләр, аерым алганда Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте исеменнән чиркәү тарихы докторы, профессор К.В.Харлампович (1870-1932) «Камско-Волжская речь» (1917 ел, 16 сен.) газетасында Сөембикә манарасы башыннан каракошны төшереп, ярымай куюга каршы мәкалә бастыра. Әмма, Казан мөселман хәрби комитетының гаярь егетләре шовинистик көчләрнең каршылыгына карамыйча, манара башыннан каракошны 16 сентябрьдә (иске стиль белән) алып ташлыйлар. Бу эшне солдат Габдулла Исмәгыйлев, тупчы Лотфирахман Габдрахманов, артист Газибәк Салтыковский һәм Ибраһим Зәйнуллиннар тормышка ашыра. 1918 елның 8 мартында манара башына куел-

[113] Загоскин Н.П. Спутник по Казани. — Казань: Типо-литография Императорского университета. — 1805. — С.100.
[114] Невзоров П. О Сююнбекиной башне. — Казань. — Типография губернского правления. — 1894. — С.5.
[115] Дульский П. Памятники Казанской старины. — Казань. — 1914. — С.17.

1917 елның сентябрендә Сөембикә манарасыннан ике башлы бөркетне бәреп төшерүчеләр төркеме. Уртада утырган – Ибраһим Зәйнуллин

ган ярымай 1934 елда алына. Ниһаять, татар халкының Сөембикә манарасына ярымай кую теләге 1990 елның 26 сентябрендә генә тормышка ашты. Бу эш Татарстан Республикасы мәдәният министрының ул вакыттагы урынбасары Габбас Мөхәммәтшин тырышлыгы белән башкарылды. Шулай итеп, манара башында, милли азатлык символы гәүдәләнеше буларак, яңадан ярымай балкый башлады.

1917 елгы февраль инкыйлабыннан соң тернәкләнеп киткән милли-азатлык хәрәкәте лидерлары манараны татарлаштыруга зур игътибар бирә. Ягъни, күренекле тарихчы, әдәбиятчы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Габделбарый Батталның (1880-1969) «Сөембикә манарасы» исемле хезмәте нәкъ менә шушы чорда басылып чыгуы бер дә очраклы хәл түгел. Бу хезмәт Казан хәрби Шура комитеты тәкъдиме һәм аның химаясендә дөнья күрә, хәзерге термин белән әйтсәк, социаль заказ нәтиҗәсе буларак нәшер ителә.Укучыларга тәкъдим ителә торган бу хезмәт, әлбәттә, шул чор тарих фәне казанышларын чагылдыра. Кайбер очракларда авторның дәлилләре белән бәхәсләшергә дә мөмкин булыр иде. Әмма ул безгә шул чор татар тарихи һәм иҗтимагый-сәяси фикеренең ядкәре буларак та кадерле. Бу — бер. Икенче яктан караганда, гарәби хәрефләр белән нәшер ителгән бу хезмәт «Сөембикә» манарасы хакында язучы хәзерге заман галим-голәманың абсолют күпчелегенә таныш түгел. Шуңа күрә, төрле яктан караганда, аеруча тарихи хәтеребезне яңартып торуның әһәмиятен истә тотканда, бу хезмәтне журнал укучыларга тәкъдим итү кирәкле гамәл исәпләнергә тиеш. ■

Үз заманында Зариф Бәшири (1888-1962) татар әдәбиятында шагыйрь булып танылган кеше. Аның чәчмә әсәрләре дә шактый. Аеруча «Чуаш кызы Әнисә» бәяны аңа шөһрәт китерә. Туган авылы Чүтинең (хәзерге Кайбыч районында) тирә-ягында чуаш авыллары булу сәбәпле, Зариф Бәшири бу халыкның телен, гореф-гадәтләрен яхшы белгән.

«Шура» журналында чуаш халкының яшәү рәвешенә, этнографиясенә багышланган «Чуашлар» мәкаләсе дә шуңа бер дәлил. Бу язма мажар (венгр) шәрыкчесе Ю.Мессарошның да дикъкатен җәлеп итә. Бу галим белән күрешү, әңгәмәләшү Зариф Бәширигә нык йогынты ясый. Мессарош, яшь шагыйрьнең мишәр таифәсеннән булуына игътибар итеп, аңа туган кавеменең этнографиясе, көнкүреш мәдәнияте турында язарга киңәш итә. Шушы сүзләрдән рухланган Бәшири, Оренбургта чыга торган «Чүкеч» журналындагы мөхәррирлек эшен ташлап, мишәрләр арасына балалар укытырга китә. «Поезд чаба, мине максатыма тизрәк ирештерергә ашыга сыман. Максатым: Тамбов губернасы Темников өязе Вәрәки дигән авылда балалар укыту, шуның белән бергә мишәрләр турындагы тикшеренүләремне дәвам иттерү!» — дип яза ул соңыннан үзенең истәлекләрендә. Нәтиҗәдә, 1910 елда «Шура» журналында аның «Мишәрләр» дигән хезмәте дөнья күрә. Шактый бәхәсле урыннары булуга да карамастан, әлеге язма бүген дә кызыксыну уята. Аны басмага филология фәннәре кандидаты Салават Галимов әзерләде.Фәннәр кандидатлыгына диссертациясен дә ул Зариф Бәшири иҗаты буенча яклаган иде. Биредә шуны да җиткерү күңелле: тиздән Татарстан китап нәшриятында Зариф Бәширинең «Сайланма әсәрләре» дөнья күрәчәк. Аңа язучының истәлекләре, әдәби әсәрләре тупланды.

Ркаил Зәйдулла

Уңда – Зариф Бәшири, сулда – Галә Ходаяров. Кисловодск курортында. 1926 ел

МИШӘРЛӘР

Зариф Бәшири

1.

Колагымда мишәр сүзе уйнау илә минем күкрәгемдә ихтыярсыз, бертөрле мактану вә горурият калка. Фәкать бу горурлыгым җенсият дәгъвасе, милли низаг вә изү кеби инсаниятсезлекләрдән пакьтер. Нигездә, мишәр халкында бу мактану гомуми бер гадәт буларак искедән канга сеңеп калгандыр.

Яшь вакытларымда мәдрәсәдә укыганда, мишәр талибәсе илә казан татарлары дип әйтелмеш татар талибәсе арасында, бер-беренең гадәт вә телләрен тәнкыйть әйтеп низаглашулар бер-бер артлы булып торуы гадәт хөкемен алган иде. Мишәрләр исә казан татарларының асыл сөйләшләрен, казан татарлары исә мишәрләрнең рус сөйләменә тартым сүзләрен вә тавышларын тәнкыйть итә иделәр. Моннан шул аңлашыла: һәр милләт вә һәр җенес, нинди дәрәҗә мәдәни булуына карамастан, үзенең ана телен сөя вә шуны алгы сафка куясы киләдер.

Татарлар илә мишәрләр арасында мондый тартышларның булуы арадан берлекне югалту вә ул исә безнең өчен бер зарурлык булуыннан отыры, андый мәгънәсез низагларны ташлау кирәклеге вә телләребезне берләштерү тиешле идеге һәр ике тарафның өмете вә теләгедер. Ләкин бу искедән калган бер дәгъва гына, татарлар илә мишәрләр арасында әүвәлдә бер суыклык булуы хәтеребезгә килмидер.

Хәлнең асылын нечкәләп тикшереп караган вакытта, татарларның урыс теленнән һичбер сүзне файдаланмаулары вә соңрак вакытта файдалана башласалар да хозур аз булуы, хәтта урыс теленнән кергән сүзләрнең артикуляциясендә зәгыйфьлек күренә. Мишәрләрнең исә күп сүзләре урысча булып, асыл сөйләшләре дә шуңа охшаган булуы — бу ике җенеснең арасында мөнәсәбәтнең юклыгын, булган тәкъдирдә дә ерак тамырларда гына булуын күңелгә саладыр.

Әгәр хәзерге казан татарлары белән мишәрләрнең милли санаган гадәтләреннән башка искедән калган гадәтләре, тормышлары чагыштырылып каралса, бер-берсенә туры килгән шәйләр бик күптер. Мишәрләрнең кирәк дин вә мәгариф тугрысында булган омтылышлары, сәүдә итү, алыш-биреш вә мәгыйшәт эшләрендәге хәрәкәтләре булсын, казан татаралары белән чагыштырганда бик күп дәрәҗәдә алдадыр. Минем беркадәр горурлыгым — шулдыр. Нигездә мишәр җенесендәгеләр барчасы мишәрлекләрен сөяләр вә үзләренең намусларын саклау юлында аңлаган вә күңелләре җиткән кадәр иҗтиһадларын кызганмыйлар.

Минем бу сүзләрдән мишәрләрдә татар кардәшләребезгә дошманлык вә кырын күз бар икән, дип уйламасыннар. Мишәрләр хакында берникадәр мәгълүмат җыеп язарга мине мәҗбүр иткән нәрсә, горурлыгыбызны куәтләндерүгә сәбәп булган маҗар шәркыятьчесе Мисаруш[1] әфәнде җәнапларының киңәше.

Мисаруш җәнаплары белән беркадәр вакытлар мәҗлестәш булган заманда, сүз арасында «Русиядә гомумән татар исемләнгән әһле ислам арасындагы кавемнәрнең кайсы тәрәккыйга һәвәсле

[1] Ю.Мессарош — венгр шәрыкчесе.

Зариф Бәшири (уртада) уйгыр яшьләре белән Сәмәркандта. 1926 ел

вә голүм мәгарифкә сәләтле?» булуы хакында бәндәләренә бер сөаль такты. Ләкин мин гыйлем вә мәгарифтә түбән вә тәҗрибәдән буш һәм дә милләттәшләрем арасына аз аралашучан булуымнан бу сөальгә катгый җавап бирүне өстемә ала алмадым. Шулай булса да, югарыда яралган фикерләремне бәян иткәннән соң, чама белән мишәрләр белән казан татарлары булуын сөйләргә батырчылык иттем.

Шәркыятьче җәнаплары мишәр халкының башка татар кавемнәре белән чагыштырганда тәрәккый вә мәгарифкә сәләтлерәк кавемнәр икәнлеге турындагы фикере барлыгын бәян иткәннән соң, аларның сәүдәгәр, гайрәтле, җитез икәнлекләре вә эшләрендә чыдамлы, ныклы бер кавем булуларын хуплады. Бары тик аларның алыш-биреш итү эшендә башка милләтләр илә артык аралашуларыннан, элегрәк мәгарифтә зәгыйфьлекләре сәбәпле, телләрен югалтулары вә андый хәлләренең һаман баруы киләчәк өчен куркыныч булуын сөйләде. Шуның белән бергә аларның бу арада яхшы ук укуга ябышканлыкларыннан моның да чарасына керешерләр, дигән өметтә булуын бәян итте.

Шәркыятьче җәнаплары миңа бер хезмәт йөкләү ниятендә булуын белдерде. Моның кебек бөек затларның хезмәтләрен кулдан килә торып та башкармау, әлбәттә, авыр эштер. Фәкать безнең кулыбыздан мондый затларның теләкләренә нинди хезмәт туры килер икән! Бу фикерне, әлбәттә, аңа да аңлаттым.

«Чуашлар» хакында «Шура»да язган әйберләрем төпле тарихлардан алынып язылмавы өстенә, аларның (чуашларның) асыл вә нисбәтләре хакында булмыйча, бәлки үз тәҗрибә вә тикшерүләремнән гыйбарәт булуына карамастан, шәркыятьче әфәнде боларның тарих өчен бөек бер ярдәм икәнен сөйләп, мишәрләр хакында да шушы рәвешле нәрсәләр язуның зарарсыз булуын бәян итте.

«Һәр милләтнең тарихы аларның искедән калган гадәт вә әхлакларын, тел вә мәгыйшәтләрен тикшермәк белән мәйданга чыгадыр. «Шура» журналы кеби әһәмиятле журналга ия була торып та беркадәр авыр, катлаулы эшләрне башкармау иҗтиһад әһеленә языктыр», — җөмләләре минем яшь вә һәвәскәр күңелемне очындырды.

Аның каравы мин бер яшь бала хөкемендәмен вә матбугатта игътибарым

да зәгыйфь. Хак илә ат уйнату кадәр дә булмаганлыгымнан, моны рәткә чалышсам да, бу хакта корыч каләмнәре белән матбугат сәхифәләрендә нурлар уйнатып: «Һәй, эшкә яраксыз, бөекләргә юл бир!» — димәк заманнары булмаганлыктан, бу көнгә кадәр бу хәлнең өмете күренеп тормаганлына ышандым. Шул сәбәпле, беркадәр мөһим эшләремне куеп, мишәр кардәшләремнең гадәт вә телләрен, мөмкин булса иске әсәрләрен дә тикшермәк ният илә Пенза губернасында мишәр боткасы булган Рахманка суы буендагы бер мишәр авылында кыш кичермәк ниятен тоттым.

Мин монда мишәр кардәшләрем белән аралашып, көннәр уздырдым. «Шура» сәхифәләре кабул иткәнчә, иң әүвәл мондагы Тамбов вә Пенза мишәрләре хәлләрен язып, гадәт вә телләрен бәян иткәннән соң, тарихыннан да беркадәр мәгълүмат бирәм. Җәнап хак тугры фикер йөрешендә максадыма ирешүемне насыйп әйләсен…

2

«Күңел белән тоташмаган күз —ботак тишеге» дигән мәкальнең дөреслегенә бу көн артыграк төшендем. Мин үзем — мишәр баласы, мишәрләр арасында туып, мишәр балалары белән уйнап үстем. Ләкин мишәр гадәтләреннән һичберсе диярлек хәтеремдә калмаган. Бары күрше әбиебезнең, башына «чалма» аталган озын вә киң ак бурларны чолгап йөргәне генә күз алдымда тора. Авылда әбинең мине сөйгәнлекләре, кыяк суганнар биреп күрсәткән яхшылыклары исемә төшеп, бөтен торышы белән җанлы картина рәвешендә булган сурәте күз алдыма төшкәч кенә мишәр карчыкларында чалма бәйләү гадәте барлыгын хәтеремә килә. Мин артык татарлашуымнан үземдә мишәр баласы булуыма галәмәт булган бер гадәт таба алмыйм вә шулай ук башкалар да сизә алмыйлар. Тик мишәрләр арасына килгәч кенә, бөтен күңелем хушланып пешкән суган ашавым гына миндә мишәрлек гадәтләреннән табигый булган бер гадәт барлыгын белдерде. Мишәр халкы гомумият илә пешкән суган ашар өчен җан атар. Бу чуашларда да шулай ук.

Мишәрләр вә чуашларның бу көнгә кадәре сакланган урыннары да Русиянең төньяк тарафындадыр. Бу тарафта булган чуашлар белән мишәрләр берберсенә якын булып, һичберсенең арасында татар карендәшләр юкдыр. Әмма башка тарафларда булган мишәрләр вә чуашлар, мәсәлән, Самара, Саратов, Хвалын, Чистай кеби җирләрдә, нык татарлашканнар яхуд урыслашканнар.

Чуашлар хакында күбрәк төньяк чуашлар әхвәленнән язганым кебек, монда да төньяк мишәрләр хәленнән язуны кулаерак таптым.

Мишәрләрнең татарларга караганда чуашларга булган мөнәсәбәтләре, кирәк тормышта вә кирәк гадәттә булсын, бик якындыр. Шушы сүзләремне исбатка байтак кына файдасы булганлыктан, үземнең мишәрләр арасына сәяхәт вакытында булган хәлләремне бераз язып китмәк булам.

Казан вә Мәскәү тимер юлы өстендә булган Шихран[2] станциясендә берәр кич куну теләге белән фатир эзләргә лазем күрелде. Бер чуаш йортына барып тәрәзә кактым да, урта яшьләрдә бер чуаш хатыны кечкенә генә тәрәзә тишегеннән башын тыгып, безне татарлар дип уйлап булса кирәк, каты күңелдән чыккан тавыш белән: «Кайсы авыл татарысыз?» — диде. «Җиңгәй, без татар түгел, Чүти мишәрләре», — җавабын ишеткәч җиңгәйнең сүзләре йомшакка әйләнсә дә, нинди эшле, кем баласы, кайда бару хакында озак сорашкач кына: «Бердән, мишәр вә икенчедән, Шәрәфи абзый баласы да булгач, ачык йөз белән кабул итәбез инде», — диде.

Чуашларда, үзенә килгән кешене генә түгел, бәлки юлда очраган кешене дә начар эшле булмасын дигән курку белән төрлечә сөальләр биреп тикшерү гадәте бар. Алар бу гадәтләре белән кыргыз-казах халкына охшыйдыр. Кыргызларда да узган-барганны туктатып сорашмый җибәрү юктыр.

[2] 1925 елдан Канаш исеме белән аталган.

Югарыда әйтелгән чуаш хатыны, безнең күрше авылдан киткәнлектән татарчага бик оста булуы өстенә, яшь вакытында әткәсе белән бездә берничә мәртәбә чәй дә эчкән икән. Менә шуның өчен дә миңа ничек ихтирам итәргә белми иде. Ихтирамына сәбәп ике төрле нәрсә булды: беренчедән, мишәрлегем вә икенчедән, әткәмнең икмәк-тозыдыр.

Үзенең тукыган тышлы мендәрләрен баш астына салып, сары тунын өстемә яба вә һәр хәрәкәтендә: *«Әй безнең Атау! Мишәрдән бер дә кайтмый иде. Авылыбызга мишәрләр киләләр иде. Мишәр кызлары белән кич утырыша идек, мишәрчә бәетләр (җырулар) әйтә идек. Кыз чакларым хәзер төштә күргән вакытлар кебек кенә булып калды... Монда килгәч тә чуаш телен өйрәнә алмый аптырап беттем*[3]*. Монда чуашлар татарча бик аз беләләр. Элек чуашларда мишәрчә бәетләр әйтү булып, бөтен күңелне өзә иде. Хәзер заман бөтенләй бозылды инде. Аларның берсе дә калмаган»,* — сүзләрен тәкърарлап күз яшьләре белән зарлана вә: «Безнең чуашлар урынсыз җирләргә җумардлык (юмартлык) кылмаганын сез дә белә торгансыз? Әгәр сез безнең җаныбыз тарткан мишәр булмасагыз, мин үзем ята торган мендәрләремне тиз генә сезгә бирер идемме! Әле ярый мондагы чуашлар да мишәрләр өчен өзелеп тора. Кайнатам да, мишәрләр булса, керсеннәр, дип сезнең килүгә ачык йөз бирде», — дип килүебезгә ничек шат булуын белдерә. Хатынның иркә кызы Анна да безгә ничек хөрмәт куярга белми йөри иде. Бу исә чуашлар белән мишәрләр арасында ихласлык белән бер мөнәсәбәт барлыгын белдерсә кирәк.

***

Поездда вакыт югарыдагы хәлләрне уйлап бара идем, каршымда утырган бер татар карчыгы янына яшь кенә бер мишәр егете килеп утырды. Татар карчыгы бу егетнең каты теленнән мишәр идеген аңлагач та: «Җегет сез кайда барасыз?» — сөален биреп, «Ыстанбулга, әбекәй» җавабын алуына бөтенләй гаҗәпләнде вә моңа карап мыскыллы бер тавыш белән: «Анда нишләп йөри икән инде бу мишәр?» — дип, мишәрләрне начар бер халык дип уйлаганын аңлатты. Әбинең аңлатуынча, мишәрләр гаять җалкау, кеше арасына катнаша алмаслык пеш бер халык булдыгыннан, моның да шундый һәйбәт Истанбулга баруы дәрәҗәле бер вакыйга имеш... Минем сөальләремә каршы мишәр егете үзенең Истанбулга башлап баруының сәбәбен сөйли башлады:

— Менә шәкерт! Бездә иң кыен нәрсә — өйләнү. Ул мине егерме бергә чаклы чыкмаган туган-үскән илемнән чыгып, ун еллар читтә йөрергә мәҗбүр итте. Солдаттан калгач өйләнергә теләсәм дә, кыз бәрабәренә бирергә тиеш булган сигез йөз сумны бирергә атамның көче җитмәде. Шул сәбәпле, мин читкә мал табарга чыгып китеп, йөри-йөри ике елдан соң Истанбулга барып чыктым. Анда сигез ел интеккәч, кайтып өйләндем».

Бу егетнең кыз бәрабәренә сигез йөз сум бирүенә гаҗәпсенеп, мин: «Ник ул кадәр кыйммәт? Юкса, сөйгән кызыңны гына алмак булдыңмы?» — дидем.

— Әй шәкерт, кайда ул сөйгән кыз! Нинди булса яраган булыр иде дә, таба алмадым. Бу әле урта бәһасе генә. Бездә кызлар мең йә мең ярым сум була. Шуңа күрә дә егетләре тиз генә өйләнми».

— Соң ул акча кыз атасына буламы?

— Юк, туй расходына, бирнә бүләкләренә бетә, — диде вә бу гадәтнең начарлыгын, шушы сәбәпкә күрә дә, кызларны үзе теләмәгән бай егетләргә кол урынына сатып, бөтен сәгадәтьләрен вәйран иткәнлекләрен бәяли башлады.

— Алай булгач, нигә әллә никадәр маллар түгеп мишәр кызы аласыз, татарда беткәнмени кыз?

Ул күрсенде:

— Әй шәкерт! Үз җенесеңнән аеры-

[3] Урум, Гөбенә суы буенда чуашлар үзенчәлекле сөйләшә.

лу кадәр авыр эш дөньяда бармы икән?! — диде.

Бу әфәнденең дөрес сөйләвенә Пенза мишәрләре арасында чынлап ышандым. Бер мишәр интеллигенты мине үзенең туена чакырды. Бу әфәнде, яхшы гына мәгълүматлы да булганга вә әдәбият җәдидә белән дә һәр ноктасына кадәр төшенеп мәшгуль булганга, хөр вә милли фикерле булып, фикере дә телдән генә булмый эш белән дә булганга зыялы диюгә дә лаеклыдыр. Фәкать ул өйләнү тугрысында гына үзенең фикерен эш белән күрсәтә алмаган.

Ул бу тугрыда: «Мишәрләрнең болай уйланулары вә кыз бирүләре, бердән, кияү белән кызның бер-беренә гүзәл әхлаклы вә тугрылыклы булуларына карамыйча, фәкать зур туй, күп мәһәрне (калым) генә тикшереп, кияү белән кызны бер-беренә күрсәтми вә белдерми, бер-беренә мәхәббәтләре булмастан аларны кычкырыш вә низаг, кайгы вә хәсрәт боткасына боталган мәгыйшәткә ату вә икенчедән өйләнүченең барлы-юклы малын туй расходына түгеп, малы булмаса бурычка чумдырып, калган мәгыйшәтләре вә бурыч газаплары өчен кияүне читкә байлар хезмәтчесе яхуд сәүдәгәр итеп җибәрергә мәҗбүр иттегеннән, аларның ләззәтле яшь гомерләрендә бер-береннән аерылып торуларына, сагынып саргаюларына гына сәбәп була. Шулай булгач, ачы хәсрәтләрне, тәмле шатлыкларны шәрик (уртак) хәят белән уртаклашу, гаилә ләззәтенә алданып мәгыйшәт авырлыкларына чыдау өчен булган бу өйләнү, максатның киресенчә, яңа баштан кайгы вә хәсрәткә чуму, талаш вә кычкырышка юл ачу яхуд өскә артык бурычлар йөкләп тә, нәтиҗәдә бер-берең белән озын гомерләр күрешә алмау дәрте белән тилмереп йөрергә бер сәбәп һәм байларны коршау аша сикертүче, фәкыйрьләрне мәңгелек бурыч астына тыгучы бер бәла гына буладыр», — дип бөтен күңеленнән әрнегәнен, эченнән еглаганын белдерә вә моның начарлыгын таный. Сүз арасында, мисал өчен, алдыбыздагы бер хезмәтчене күрсәтеп: «Күр инде, менә шул әфәнде дә өч-дүрт йөз

Зариф Бәширинең икенче улы Чыгытай һәм кызы Халидә. Ташкент. 1959 ел, август

сумсыз өйләнә алмый бит! Әле җитмәсә шулкадәрле бурыч та яздыра. Кыз атасы аларның киләчәктә мәгыйшәтләрен уйлап та карамый микәнни!» — дип өзелә, шул гадәтне ничек тә булса бетерергә тели.

— Үзең шуның начарлыгын белә торып та ник алай эшләдең?

Поезддагы мишәр кеби бу интеллигент танышым да:

— Шулай алмасаң өйләнми торырга кирәк, башка милләттән алсаң, миллилекне аяк астына салып таптау була, — дип җавап бирде.

Монда кадәрле язган шәйләр мишәрләр хакында булган өч төрле нәрсәне аңлатмак өчен иде ки, алар да: мишәрләр белән чуашларның бер-беренә якынлыклары вә мишәрләрнең өйләнүләре тугрысында булган начар гадәтләре вә миллилекләредер. Әмма аларның бу тугрыда булган миллилекләре ялгыш юл белән булганын киләчәктә язачакмын.

Шура. — 1910. — №1. — Б.5-6.; №3. — Б.74-77.

Дәвамы бар ■

Фоторәсемнәр Татарстан Фәннәр Академиясе, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондыннан алынды: 57 ф., 1 тасв., 75 сак. берәм.

БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫ (1914-1918) БАШЛАНУГА 100 ЕЛ

«СУГЫШТА ВӘЙРАН БУЛА ГАЗИЗ БАШЛАР...»

Раиф Мәрданов

Беренче бөтендөнья сугышы 1914 елның 15 (28) июлендә башланып, 1918 елның ахырына кадәр дәвам иткән. Ул замандагы иң көчле державалардан ике коалициянең: бер яктан Германия, Австро-Венгрия, Төркия һәм Болгария, ә икенче яктан 1907 елда берләшкән Антанта[1] илләре – Россия, Франция, Бөекбритания, Сербиянең коточкыч бәрелеше нәтиҗәсендә бөтен Европа һәм өлешчә башка кыйтгалар да ут, кан, вәхшәт, ачлык, михнәт эчендә калган.

Европадагы союзниклары сугыша башлау сәбәпле, Россиядә 18 (31) июльдә гомуми мобилизация игълан ителгән. Польша, Украина һәм Балтыйк буен тартып алу максаты белән 1914 елның 19 июлендә (1 август) Германия Россиягә сугыш игълан иткән. Патша Россиясе дә Төркияне бүлеп, Кара диңгездән Урта диңгезгә чыгу өчен Дарданелл бугазын үзләштерергә омтылган, шулай ук Константинопольне һәм Австро-Венгриянең бер өлешен тәшкил иткән Галицияне яулап алырга тырышкан. Россия армиясе Балтыйк буе, Галиция һәм Польшада Германия гаскәрләренә, шулай ук Кавказ артында төрек гаскәрләренә каршы сугыша.

1914 елда сугышны чагыштырмача уңышлы алып барган Россия армиясен 1915 елда немецлар шактый чигенергә мәҗбүр иткән. 1915 елның март аенда рус армиясенең Перемышль шәһәрен алуы — ул елдагы иң зур уңышы булган. Шул ук елның апрель аенда немецлар көчле һөҗүм башлагач, бу каланы руслар июнь аенда дошманга калдырып китәргә мәҗбүр була. Корал, артиллерия снарядлары җитмәү, гомумән, тәэминатның начар булуы, немецларның сан ягыннан күплеге (ике мәртәбә артыграк булуы) һәм дошманның көчле артиллерия һөҗүмнәре нәтиҗәсендә рус армиясе Польшаның көньяк өлешеннән чигенергә мәҗбүр була. Аннан соң немецлар рус армиясен Польшаның төньяк тарафыннан да кысрыклый. Ягъни, 1915 елның 26 июнендә Польшада Висла һәм Буг елгалары арасында герман армиясе һөҗүм башлаган. 4 августта Варшаваны немецлар алган. Шул сәбәпле Россия армиясендә гомуми рух төшенкелеге күзәтелгән һәм сугышчылар дошманга күпләп әсир төшкән.

1916 елда Антанта илләре дошман якның һөҗүмнәрен һәм каршылыгын сындыруга ирешкән. Шул ук вакытта Россия гаскәрләре төрекләр белән сугышта уңыш казанган. Ләкин Россиядә 1917 елның февралендәге революция хәрәкәте нәтиҗәсендә армия таркала башлый һәм фронттагы хәлләр кискенләшә. 1918 елның 3 мартында Россия белән Германия арасында Брестта төзелгән солых нигезендә Совет Россиясе сугыштан чыккан. Брест солыхы буенча Россия Польшаны, Балтыйк буен һәм Украина белән Белоруссиядәге җирләренең бер өлешен югалткан.

Тарихта аңарчы күрелгән дәһшәтләр белән чагыштырганда, иң күп үлем һәм җимерекләкләргә китергән бу сугыш Россия империясе өчен аеруча зур хәсрәт булган. 1914-1915 елларда Россиядә 12 миллионга якын (кайбер белгечләр язуынча, 16 миллионлап) ир-егет сугышка мобилизацияләнгән. Шуларның ун процент чамасын мөселман төрки-татарлар тәшкил иткән. Россиядәге мөселман төрки-татарлардан бу сугышка 1-1,5 миллион кеше фронтка алынган. Россия армиясенең 2,5 миллион чамасы гаскәри ир-егетенең үлеме, тагын шулкадәр үк сугышчыларының әсирлеккә эләгүе, толлар, ятимнәр, ачлык, ил хуҗалыгының җимерелүе, хакимият кризисы һәм бүтән бәхетсезлекләр бергә укмашып, яшәеш агымын бик нык какшаткан.

Сугышка мобилизацияләнүчеләр саны буенча Вятка губер-

[1] Антанта — башта Бөекбритания, Франция һәм патша Россиясе тарафыннан оештырылган, ә Беренче бөтендөнья сугышы вакытында күп сандагы дәүләтләрне берләштергән союз.

насы бөтен Россиядә өченче урында торган. Губернада беренче мобилизация үткәрелгәндә (1914 елның 27 июлендә) биш өяздән, шул исәптән Алабуга өязеннән, хәрби хезмәт үтеп кайткан запастагы 45 мең кеше сугышка алынган. Икенче чакырылыш көненнән (3 августтан) бөтен губернадан тагын 70 мең кеше фронтка озатылган. Шуларның 90 проценты крестьяннар булган һәм бер айдан да аз вакыт эчендә Вятка губернасындагы авыллар 100 мең крестьяннан (эшкә яраклы ир-атларның 28%) мәхрүм калган. Сугышка мобилизацияләү вакытының авылдагы кайнар эш чорына туры килеп, бик күп хуҗалыклар төп эшче көченнән аерылу сәбәпле, бөлгенлеккә төшкәннәр һәм ачлыкка дучар булганнар. Өстәвенә, крестьяннарны солдатка алу белән бергә, атлар һәм сбруйлар да мобилизацияләнгән. Бу хәл авылда яшәүчеләрне тагын да хәерчеләткән.

Алабуга өязендәге татар авылларында да хуҗалыкның бөтен эшләре хатын-кызлар, картлар һәм балалар өстенә төшкән. Җитмәсә, аларны Ижевск корал заводы өчен урман кисүгә мәҗбүриләп эшкә куып торганнар. Россиядә икмәк һәм, гомумән, азык-төлек кризисы елдан-ел көчәйгән. Авыллардагы запас ашлыкларның бер өлеше армия һәм дәүләткә җыеп алынган. 1917 елның август аенда ачлыктан интегүче Түбән Новгород, Владимир һәм Кострома губерналарыннан ашлык алырга килгән меңләгән кеше елга юлы буенча Камадагы пристаньнарда һәм тимер юл буенча станцияләрдә төшеп, Алабуга һәм Сарапул өязләрендәге авылларга килеп тулган. Хәлләр аеруча киеренкеләнгән. Бу як авылларына кораллы хәрбиләр китерелгән. Җирле халык белән Түбән Новгородтан килгән меңләп кеше арасында тимер юл станцияләре һәм пристаньнарда бәрелешләр булган. Алабуга өяз идарәсе спекулятив бәягә сатылган барлык ашлыкны армия өчен көч белән йолып алу турында карар чыгара. Өстәвенә, волостьлардан җыелган икмәк өчен тиешле акча бөтенләй түләнмәгән, авыллардагы запас амбарларда һәм халыкның үзендә ашлык беткән. Шулай итеп, 1917 елның көзендә крестьяннарның җир өчен көрәше һәм хөкүмәткә аш-

лык бирүдән баш тартуы көчәя бара. Авыл хуҗалыгы түбәнгә тәгәри. 1916 ел белән чагыштырганда, 1917 елда Вятка губернасындагы чәчүлек җирләр өчтән бер өлешкә кимегән.

Һәр көндә үлем белән очрашкан сугышчыларга туган якларындагы, үз хуҗалыгындагы менә шундый четерекле хәлләр турындагы хәбәрләр ирешеп торган. Сугыш мәхшәре эчендәге бичара солдатларга гаилә хәсрәте дә зур борчулар тудырган. Фронтовиклар командирларына, туган җирләрендәге земстволарга, волость идарәләренә ачлыктан интегүче үз гаиләләренә ярдәм итүне сорап, меңнәрчә хатлар һәм үтенечләр язган. Тик аларны канәгатьләндерү мөмкин булмаган.

Сугышта катнашып исән калган солдатлар, илдәге революцион үзгәрешләрдән соң, 1917 елның ноябрь-декабрендә туган җирләренә кайта башлаганнар. Шактые 1918 елның язында, Брест солыхыннан соң гына кайткан.

Герман сугышында меңнәрчә татар ир-егетләре дә һәлак булган, гарип-горабага әйләнгән, ничаклы балалар ятим һәм хатыннар тол калган. Сугыш афәтенең ни дәрәҗәдәге мәхшәр икәнлеген ул заманда яшәгән кешеләр бик яхшы аңлаган. Тик Герман сугышы туктап җитәр-җитмәс, аның коточкыч фаҗигаләренә 1918 елда илдәге гражданнар канкоешы тоташып киткән.

Илдәге барлык халык өчен дәһшәтле булган бу сугышның зур фаҗигасе, монысыннан да куркынычлырак Икенче бөтендөнья сугышының вәхшәте һәм хәсрәте аркасында гына бераз онытылган.

***

Беренче бөтендөнья сугышы чорында алман әсирлегендә булган татарларның төгәл саны билгесез. Бу мәсьәләне махсус өйрәнгән тарихчы И.Гыйләҗев андый язмышка юлыгучылар дистәләгән мең булган, дип яза. Шулай ук ул Алмания территориясендә урнашкан кимендә 100 хәрби әсирләр лагеренда татар солдатлары булуын билгеләп үткән. Ул чор әсирләре турында мәгълүматлар матбугатта берникадәр чыгып килә. Дөрес, аларның күбесе Берлин янындагы Вюнсдорф һәм Цоссен шәһәрчекләре арасында мөселман әсирләре өчен махсус төзелгән ике лагерьга багышланган. Бу лагерьлар

Габдерәшит Ибраһим

бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булганлыктан, аларны бер исем астында Вюнсдорф лагере дип атау да гамәлдә булган. Мөселман әсирләре өчен махсус лагерьлар төзү мәсьәләсе 1914 елда — сугыш башлану белән үк туган. Аларга әсирләр туплау 1915 елның җаенә хәтле дәвам иткән.

Мәкаләләрдә язылганнарга караганда, Вюнсдорф лагерендагы татар әсирләре кырыклап командага бүленеп, баракларда яшәгән. Анда 1915 елда зур гөмбәзле, биек манаралы мәчет төзелгән, театр өчен аерым бина булган, оркестр һәм китапханә оештырылган. Татар әсирләре өчен 1915-1918 елларда «Әл-җиһад» һәм 1918 елдан «Яңа тормыш», 1919-1920 елларда «Татар иле» исемнәрендәге газеталар, китаплар да чыгарылган[2]. Бу лагерь, Алман хөкүмәтенең мөселман хәрби әсирләре өчен император Вилһельм әмере белән махсус сәяси-пропаганда максатларында оештырылган. Галимнәр язуынча, Алмания җитәкчелеге әлеге лагерьны мөселман илләре алдында гына түгел, ә мөселманнар яшәгән Антанта дәүләтләре өчен дә алман индустриясенең һәм тәртибенең бөеклеген пропагандалау чарасы итеп караган. Вюнсдорф лагерендагы тоткыннарны Антантаның колониаль буйсынуындагы илләрендә мөселманнарны дин нигезендә берләштереп, Алманиянең дошманнарын эчтән таркату, төрле баш күтәрүләр оештыру, хәтта революцион күтәрелешкә әзерләү максаты куелган булган. Шулай ук мөселман әсирләреннән хәрби берләшмәләр оештырып, аларны Антанта илләренә каршы сугышта куллану нияте дә хөкем сөргән. Бу мәсьәләдә төп ышаныч — Германиянең союзнигы һәм ул чорда дөнья мөселманнарының үзәге буларак танылган Төркиягә йөкләнгән. Төркия, үз нәүбәтендә, 1914 елның ноябрендә Бөекбритания, Россия һәм Франциягә каршы изге сугыш — җиһад игълан иткән. Алманиянең мөселман әсирләренә карата сәясәте турында И.Гыйләҗев хезмәтләрендә һәм соңгы күләмле мәкаләсендә тәфсилләп аңлатылган[3], шунлыктан ул мәсьәләгә монда киңәеп тукталу ихтыяҗы юк.

Вюнсдорфтагы әсирләр лагеренда татарлардан тыш, Антанта илләренең армияләреннән әсирлеккә төшкән төрле халык вәкилләре дә тотылган. Россия армиясендәге Идел-Урал буе татарлары һәм шул ук төбәкнең башка халык вәкилләре, әрмәннәр белән грузиннар, нигездә, «Виноград тавындагы лагерь»да (Weinberglager), ә «Ярымай лагере»нда (Halbmondlager) Көнбатыш һәм Төньяк Африкадагы, Һиндстандагы француз һәм инглиз колонияләре әсирләре тупланган. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында

[2] Насыров Т. Татарская эмигрантская пресса // Гасырлар авазы = Эхо веков. — 2004. — №2. — С.119—120.

[3] Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә ә мөселман әсирләре // Казан утлары. — 2014. —№2. — Б.128-132; №3. — Б.167-172; №4. — Б.168-173.

Вюнсдорфтагы «Ярымай лагере» белән Цоссендагы «Виноград тавындагы лагерь»да 1916 елда 15 мең мөселман әсире тотылган. Шулардан Вюнсдорф лагеренда 4000 әсир булган. Вайнберг лагерендагы мөселман әсирләренең төрле вакыттагы гомуми саны 10-13 меңне тәшкил иткән[4]. Бу лагерьлардагы тоткыннар әсир буларак түгел, ә Алман иленең кунаклары кебек сыйфатланган. Аларда әсирләрне яхшы ашату һәм киендерү, алар белән яхшы мөгамәлә кылу, чагыштырмача ирекле яшәү мөмкинлеге тудыру каралган. Чынлыкта да, әлеге лагерьлардагы әсирләр башка тоткыннар кичергән күп төрле җәфаларны күрмәгән.

Немец лагерьларындагы әсир мөселманнарны «җиһад»ка өндәү 1916 елда туктатылган. Алманлыларның бу нияте тормышка ашмаган, Россия мөселманнары немец пропагандасына бирешмәгән.

Ләкин Германиянең бөеклеге һәм Шәрык-мөселман дөньясына карата бик дустанә мөнәсәбәттә булуын агитацияләү эшчәнлеге туктатылмаган. Моның бер дәлиле итеп, 1918 елда Берлинда татар телендә басылып чыккан «Алмания — Шәрык мөнасәбате дөвәлийәсенең үткән вә хәзерге замандагы сафахате белән истикъбальдәге тәрәкъкыйсе» (Алмания — Шәрык дәүләтләре мөнәсәбәтләренең үткән һәм хәзерге замандагы чагылышы белән киләчәктәге тәрәкъкые) исемле китапны атарга мөмкин. «Яңа Шәрык көтепханәсенең татарча көллияте асаре» сериясеннән «Беренче китап» сыйфатында нәшер ителгән бу җыентык зур форматта, 72 бит күләмендә. Аның исеме арткы тышлык битендә немец телендә дә бирелгән. Мәсьәлә тулырак күзаллансын өчен әлеге китапны кыскача тасвирлап үтәбез. Китапта М.Вольф, Фридрих Пршински, Һартман, фон Янсон, Шпатч, Карл Папе... — барлыгы 16 авторның (про-

[4] Гилязов И. Легион «Идель-Урал»: представители народов Поволжья и Приуралья под знаменами «третьего рейха». — Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. — С.84; Гатауллина Л. Религиозно-политическая пропаганда среди Российских военнопленных-мусульман в Германии (1914—1922): автореф. дисс. ... канд. истор. наук. — Казань, 2011. — С.16.

фессор, доктор, генерал һ.б.) Шәрык һәм Германия арасындагы тарихи, сәяси, мәдәни, икътисади бәйләнешләргә багышланган мәкаләләре тупланган. Китапның татар теленә Фәүзия ханым Габдеррәшид тарафыннан тәрҗемә ителгәнлеге күрсәтелгән. Мәкаләләр арасында «Русия вә Шәрык», «Дустлык мөнәсәбәтләренең ныгу ихтималлары», «Алман зирагате», «Алман урманчылыгы», «Алман мәгарифе», шулай ук Беренче бөтендөнья сугышы, Шәрыккә бәйле сәнгать әсәрләре, сәламәтлек саклау, сугыш инвалидларын дәвалау һәм башка темалардагы мәкаләләр бар. Китап бик яхшы сыйфатлы кәгазьдәге 12 данә фото һәм иллюстрацияләр белән бизәлгән. Алар арасында «Пруссия падишаһы Зур Фридрих», «Солтан Мостафа ханның Зур Фридрихка җибәргән бер намәсе», «Алман шагыйре Гёте», «Пруссия падишаһысы Өченче Фридрих Вилһельм», «Сугышта бер аяксыз калган алман гаскәрләренең гимнастик ясаулары», «Сугышта кулсыз калган гаскәрнең сонгый кул белән су ташуы», «Берлин сарае: 1914 елда Алмания — Төркия иттифакы имза ителгән ак зал» һ.б. бар. Бу китапны тәрҗемә иткән Фәүзия ханым — Вюнсдорфтагы мәчеттә берара имам вазифаларын үтәп торган мәшһүр дини, иҗтимагый-сәяси эшлекле, әдип һәм нашир Габдеррәшид Ибраһимовның (1857-1944) кызы булса кирәк.

Германия һәм Совет Россиясе арасындагы 1918 елның 3 мартында имзаланган Брест солыхы нәтиҗәсендә, әсирләр үз илләренә репатриацияләнергә тиеш булган. Ләкин шул елның ноябрендә Германиядә революция кабыну сәбәпле, Брест килешүендә каралган мәсьәләләр гамәлдән чыгарылган. Россия мөселман хәрби әсирләренең барысы да туган илгә тиз генә кайта алмаган әле. Дамир Гарифуллин язуынча, 1919 ел ахырында Германиядә өч мең биш йөзләп татар әсире булган[5]. Вюнсдорф лагерендагы әсирләр 1921 елның июленә туган илләренә озатып бетерелгән һәм бу тоткынханә шуннан соң гына — 1922 елның 1 маенда ябылган. Журнал шәкелендәге «Татар иле» газетасының басылып чыккан сигез саны бергә төпләнеп һәм катыргы белән тышланып, илләренә кайтучы һәр татар әсиренә бирелгән. Әсирлектән кайтучылар һәм аларның туганнарының кулында бу газетаның нөсхәләре, сирәк булса да, сакланган. Лагерьда һәлак булган татарлар Вюнсдорф янындагы мөселман хәрбиләре зиратында җирләнгән. Анда барлыгы 2700 тирәсе кешенең кабере булып, шулардан 1100 кабер Россия мөселманнарыныкы икән. Вюнсдорфтагы зиратның мөселман өлешен тәртипкә китерү мәсьәләсендә «Татарстан» журналы 2006 елда махсус хәйрия акциясе игълан иткән иде. Шул ук журналның Германиядәге штаттан тыш корреспонденты Венера Вәгыйзова немец хәрби архивларыннан тапкан әсирлектә вафат булган йөзләрчә татар кешесенең исемлеген дә бастырды.

Татар матбугатында Вюнсдорф лагере турында шактый күләмле мәгълүматны, беренчеләрдән буларак, язучы Мөхәммәт Мәһдиев бастырган иде. Ул әсирләрнең яшәеш-көнкүрешләрен, мәдәни һәм агарту эшләрен, нигездә, «Татар иле» газетасында дөнья күргән язмалар һәм шулай ук хатирәләр буенча тасвирлады[6].

Беренче бөтендөнья сугышы әсирлегенә бәйле, Вюнсдорф лагереннан

[5] Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Гасырлар авазы = Эхо веков. — 1996. — №1/2. — Б.222.

[6] Мәһдиев М. Герман җире яшел үлән: Беренче бөтендөнья сугышы чорында татар солдатларының әсирлектәге тормышыннан бер сәхифә // Идел. — 1990. — №7. — Б.30-34.

башка төр публикацияләр дә ара-тирә дөнья күреп тора. Мәсәлән, шул ук М.Мәһдиев Мюнхен шәһәре янындагы Пухһайм шәһәрчегенең мөселман зиратында 1915-1919 елларда җирләнгән 42 татар хәрби әсиренең исемлеген бастырып чыгарган иде[7]. Мәһдиевкә ул мәгълүматларны Мюнхенда яшәүче милләттәшебез Фәридә Хәмид тапшырган булган. Әлеге Пухһайм зиратында татар әсирләре истәлегенә куелган кабер ташының бүгенге күренешен И.Гыйләҗев бастырды[8].

Австриядәге Эстергом һәм Эгер шәһәрләре янындагы лагерьларда тотылган татар әсирләре белән галимнәр дә аралашканлыгы мәгълүм. Фольклорчы Игнац Кунош (1860-1945) татарларның авыз иҗаты әсәрләрен (җырлар, әкиятләр) өйрәнгән, тоткыннарның тормышы турында махсус мәкаләләр язган. Ул булган лагерьларда күп меңләгән татар һәм башка мөселман әсирләре тотылган.

Матбугатта чыккан материаллардан элекке Вятка губернасының Малмыж өязе (хәзерге Татарстанның Балтач районындагы) Куныр авылыннан сугышка алынган Солтангәрәй Хәбибуллинның көндәлек дәфтәре һәм әсирлектәге фоторәсемнәрен дә әйтергә тиешбез[9].

«Әсир дәфтәре» исеме белән китап булып чыккан басма аерым игътибарга лаек[10]. Бу җыентыкта Оренбург ягы татарларыннан Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан солдат Гыйззәтулла Яркәевнең Австро-Венгриядәге мөселман әсирләре лагерьларында язылган бәет һәм мөнәҗәтләре, Самара губернасы татарларыннан Гатиятулла Әхмәдуллинның сугыш һәм әсирлек хатирәләре, венгр галиме тюрколог Игнац Куношның «Мөселман хәрби әсирләре лагерьларындагы эш» дигән мәкаләсе тупланган. Г.Әхмәдуллин язмалары кабатлап та басылды[11].

Герман сугышында немец әсирлегенә эләккән татар солдатларының фоторәсемнәре матбугатта чыгып торганлыгын да искә алып китәргә кирәк. Тик ул фотолар төрле максатларда төшерелгән. Вюнсдорфтагы әсир мөселманнарның пропагандистик лагерьларында төшерелгәннәре аеруча үзенчәлекле. Мәсәлән, төркем-төркем кешеләрнең ак якалы күлмәкләр, костюм, эшләпәләр кигән, галстуклар һәм чылбырлы сәгатьләр тагып төшерелгән өч фоторәсеме «Алманиядәге татар әсирләре» дип, «Гасырлар авазы» журналында басылып чыккан иде[12]. Шул ук лагерьдагы мәһабәт мәчет сурәте һәм мәчет мәйданында гает намазы, татар әсирләре, столярлык остаханәсендәге татарлар, мөселман зираты һәм башка күренешләр дә дөнья күрде. Галимнәр андый фоторәсемнәрне Германия пропагандасының уникаль чыганаклары дип бәялиләр.

Ә Эстергом лагерендагы татар әсирләренең күмәк һәм ялгыз төшкән рәсемнәре, шулай ук С.Хәбибуллинның башка әсирләр белән бергә төшкән фотолары башкачарак. Хәбибуллин турындагы публикацияне басмага әзерләүчеләр әсирләрнең үзләрен саклаган кораллы немец солдаты белән бергә төшкән фотосына карата «әле ул чорда әсирләрне Бөек Ватан сугы-

---

[7] Мәһдиев М. Алман-кырда сөякләр ята // Ватаным Татарстан. – 1993. – 26 март.
[8] Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә... – №3. – Б.172.
[9] Ислаев Ф., Нәккаш Н. Солтангәрәй Хәбибуллин – Беренче бөтендөнья сугышы әсире // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2001. – №1/2. – Б.152-157.
[10] Яркәев Г. Әсир дәфтәре / төз.: С.Гыйләҗетдинов, К.Хөснуллин. – Казан: РИЦ «Школа», 2003. – 148 б.
[11] Әхмәдуллин Г. Сугыш хатирәләре // Түгәрәк уен. – 2012. – №1. – Б.32-39.
[12] Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Гасырлар авазы = Эхо веков... – Б.222.
[13] Мәрданов Р. Тарихта тибрәлгән Тәбәрле. – Казан: «Тамга» нәшр., 2011. – Б.381.

шы елларындагы шикелле кимсетү-җәберләү булмаганлыгы күренеп тора» дигән ялгыш нәтиҗә ясаганнар[14]. Юкса алманлыларның Беренче бөтендөнья сугышы әсирләренә карата кылган җәбер-золымнары һәм вәхшилекләре турында шактый бәет текстлары сакланган.* Андый мәгълүматлар башка чыганакларда да бар.

Беренче бөтендөнья сугышында әсирлеккә эләккән рус армиясе солдатларын фотога төшерү турында Гатиятулла Әхмәдуллинның язмасы игътибарга лаек. Истәлекләрендә ул үзләренең әсирлеккә эләккәч немецларның кыр штабына китереләп, анда штаб башлыгының: «...барыгыздан да өчәр карточка алына, берсе үзегезгә бирелә, берсе бездә жандармнар отделениесенә бирелә, берсе үзегезнең Москвага җибәрелә», дип аңлатуын теркәгән[15]. Бу, күрәсең, немецларга әсирлеккә төшүчеләргә карата кулланылган гомуми чара булгандыр. Чөнки берничә кешенең бергәләп әсирлектә чакта төшкән фотоларын күргәнебез бар. Шундыйларның берсен — элекке Вятка губернасының Алабуга өязенә кергән (хәзерге Әгерҗе районындагы) Тәбәрле авылы кешесе Нәбиулла Азиевның биш иптәше белән 1916 елда немецларда тоткынлыкта төшерелгән һәм үзе белән алып кайткан фотосын бастырган да идек[13].

Галимнәр яисә кызыксынучы башка милләттәшләребез андый фоторәсемнәрне туплауга иҗтиһад итсә, бик файдалы һәм кирәкле гамәл булыр иде. Чөнки Германия архивларында тупланган һәм сирәк белгечләрнең генә теше үтәрдәй документлар нигезендә пропагандистик мөселман әсирләре лагерьлары турында төпле мәкаләләр һәм хезмәтләр язылып та, үз җирлегебездәге чыганакларның кулланылмавы һәм исәпкә алынмавы аянычлы күренеш. Хәтта, әйтергә кирәк, пропагандистик материалларга нигезләнеп язылган һәм даими чыгып килә торган мәкаләләр берьяклырак фикер урнашуга этәрә. Гүяки, Беренче бөтендөнья сугышы вакытындагы татар әсирләре концерт-спектакль куеп, җырлап, газета-журнал чыгарып, динне тиешенчә тотып, остаханәләрдә төрле тәтиләр ясап, хезмәтләре өчен азмы-күпме акча да алып, фырт киенеп, алкогольсез сыра эчеп рәхәт чигеп яткан. Югыйсә, бөтен әсирләр дә гадәттән тыш шартларда тотылмаган бит. Чөнки Вюнсдорфтагылары Германиядәге татар әсирләре тотылган 100 лагерьның икесе генә ләбаса. Калганнары турында хәбәребез бөтенләй юк диярлек. Бу турыда И.Гыйләҗев тә урынлы искәрткән. Ягъни, ул: «Бу махсус пропагандистик лагерьлар турында мәгълүматлар күбрәк сакланганга күрә, аларны өйрәнү чагыштырмача җиңелрәк, ләкин башка урыннарда әсирлек авырлыкларын кичерергә мәҗбүр булган милләттәшләребез язмышын да онытырга ярамый», — ди һәм Вюнсдорфтагы әсирләрне күздә тотып, аларны «барлык татар әсирләренең кечкенә бер өлеше генә» дип тәгаенли[14]. Ләкин бу авторның шул ук лагерьларга багышлап язган мәкаләсен «Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре» дип атавы һәм мәкалә бүлекләренең берсен «Алманиядә лагерь тормышы» дип исемләве — гомуми әсирләр тормышын тасвирлаган кебек аңлашыла.

Сугышта ничәләп татар сугышчысы әсирлектә булды икән, алар кайсы шәһәрләрдәге лагерьларда тотылган, бүтән рәвештә асралучылар күпме кеше булуы турында киләчәктә галимнәребез төгәлрәк итеп язарлар, дип ышана-

[14] Ислаев Ф., Нәккаш Н. Солтангәрәй Хәбибуллин... — Б.154.
[15] Яркәев Г. Әсир дәфтәре... — Б.97; Әхмәдуллин Г. Сугыш хатирәләре... Б.35.
[16] Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә... — №3. — Б.169.
*Бәетләр журналыбызның алдагы саннарында Раиф Мәрданов әзерләвендә дөнья күрәчәк.

сы кылә. Гомумән, сакланып калган көндәлекләрдән, хатлардан, бәетләрдән һәм башка төр язма мәгълүматлардан әсирләрнең тормыш-көнкүрешләрен берникадәр күзалларлык тасвир тудырырга мөмкин. Югыйсә, үзебезнең галимнәрнең кулы ирешердәй, якындагы кыйммәтле беренчел чыганакларны файдаланмау — аларны санга сукмауга тиң. Галимнәр сугыш бәетләренең кайберләрен «турыдан-туры бәет традицияләренә таянып язылган хроника, дияргә мөмкин»[15] дип билгеләгән икән, шул ук сыйфатламаны әсирлек бәетләренә карата да әйтергә була бит. Бу очракта татар чыганакларының төп әһәмияте шунда ки, алар — бөтен җәфаны үзләре чиккән татар сугышчылары һәм әсирләре тарафыннан язылган. Ә алман архивларындагы рәсми мәгълүматлар, нинди генә булсалар да, безнең татарларны дошман массасы итеп санаган һәм үзләренең мәкерле мәнфәгатьләрендә кулланырга ниятләгән немецларның карашын чагылдыра.

Мөселман әсирләренең Вюнсдорф лагере турында язылган мәкаләләрне укыганда, урыны-урыны белән аларның авторлары алман пропагандасына бирелеп һәм ияреп киткәндәй тоела. Мөхәммәт Мәһдиев мәкаләсендә, аерым алганда, мондый юллар бар иде: «Вюнсдорф лагере Германиядәге барлык татар әсирләренең мәдәният учагына әверелгән. Монда татарча спектакльләр, концертлар куелган, укыту эше юлга салынган... алар янына Германия галимнәре килеп йөргән... лагерь шулай итеп, кешеләрдә интернационализм хисләре тәрбияләүче учакка әйләнгән... Лагерьда биюгә өйрәтү түгәрәге дә эшләгән... Вюнсдорфтагы татар әсирләренең барысы да бальный танецка өйрәнеп кайта. Апрель аенда Вюнсдорфтагы татар әсирләре якынтирәдәге бөтен якташларын чакырып, Сабантуй бәйрәме ясыйлар»[16]. Менә бу өзектә әйтелгән «Германиядәге барлык татар әсирләренең мәдәният учагы» дигән фикерне, шулай ук лагерьның интернационализм учагы буларак бәяләнүе — үткәндәге чынбарлыкны чагылдыра дип булмый. Чөнки Вюнсдорфтагы лагерь дошман кулындагы әсирләр лагере булган һәм анда тотылган татарлар һич тә үз ирекләре белән алдынгы Европаның мәдәни казанышлары белән танышырга дип, шулай ук тиктомалдан интернациональлекне өйрәнергә дип бармаган лабаса. Вюнсдорфтагы бөтен татар әсирләренең «бальный танец»ка өйрәнеп кайтуларына килсәк, ул сугышта катнашкан татарларның барысы да диярлек авыр крестьян хезмәтенә бәйле авыл кешеләре булганлыгын искә алганда, сокланып таң калырлык нәрсә түгел. Һәрхәлдә, әллә ниткән биюләр өйрәнеп илгә кайткан ул бичараларның берәрсендә зиннәтле-купшы сарайлардагы «бал»ларда катнашырлык һәм «танец»ларга йөрерлек мөмкинлек-ихтыяҗ булмаганлыгы аермачык билгеле. Үзләре әйткәнчә, чит-ят җирләрдә читлектәге кош хәлендә, тулы билгесезлектә яткан, газиз туган җире, ачлыктан интеккән гаиләсе, туганнары, сөекле сабый балалары һәм хәсрәтле эти-әниләрен бер минутта да исләреннән чыгармаган ул мескеннәрнең башында бию кайгысы булмаган. Гомумән, мондый темалар турында язганда кешеләрне чынбарлык мохитеннән аерып карау ялгыш нәтиҗәләргә китерә. Татар язмышы турында каләм тибрәтергә алынучы татар ул-кызлары бихисап җәбер-җәфалар күргән милләтебезнең тарихи хәтерен һәм үзаңын тирәнтен аңларга тиеш. ■

---

[17] Татар халык иҗаты. Бәетләр / төз. Ф.Әхмәтова, И.Надиров, К.Җамалетдинова. — Казан: Татар. китап нәшр., 1983. — Б.9.

[18] Мәһдиев М. Герман җире яшел үлән... — Б.31-32.

КӨТЕБЕ СИТТӘ ВӘ МӨӘЛЛИФЛӘРЕ

Ризаэддин бине Фәхреддин

IV. ХӘДИС ҺӘМ МӘШҺҮР МӨҖТӘҺИДЛӘР*

Хәдис риваять итүдә мәшһүр мөҗтәһидләрнең хәлләре төрле булып, кайберләре бик күп хәдис риваять иткән хәлдә, кайберләре бик аз риваять иткән. «Мәшһүр мөҗтәһидләр» дигән сүз исә бер җәмгыятьтә махсус кагыйдәләргә нигезләнгән, иярүчеләре булган кемсәләр. Юкса, һиҗрәттән соң беренче, икенче, өченче йөзләрдә гыйлем белән исем чыгарган кемсәләрнең күбесе, иярүчеләре булса-булмаса да, мөҗтәһидлек мәртәбәсендә булалар иде. Моның белән кемсәләрнең үзләренең тормыш юлларын да ятлау, риваять иткән хәдисләрне белеп бетерү кеше куәтеннән түгел.

Мәзһәпләре ислам дөньясында билгеле булган, азмы-күпме иярүчеләре булган мәшһүр мөҗтәһидләр болар: Әбү Хәнифә, Мәлик, Суфьян Сәүри, Ибне Әбү Ләйлә, Әүзагый, Суфьян бине Гуяйнә, Ләйс бине Сәгъд, Шафигый, Әхмәд бине Хәнбәл, Исхак бине Раһуя[1], Дауд бине Гали Заһири, Бакый[2] бине Мәхләд Әндәлүси, Әбү Җәгъфәр Мөхәммәд бине Җәрир Табари, Ибне Хөзәймә, Әбү Сәвүр Ибраһим бине Халид Кәлби, Ибне Хәзим, Әбү Габдулла Җәгъфәр әс-Садыйк бине Мөхәммәд әл-Бакыйр.

Алар арасында башкаларга караганда аз риваять иткән мөҗтәһид — Әбү Хәнифә хәзрәтләре. Соңгы авторлардан берәү[3] аның хәдисләрен 500 белән 1000 арасында булганын якынча билгели. Мөҗтәһидләрнең хәдис риваять итүләре хакында булган бәхәсендә Ибне Хальдун: «Әбү Хәнифә радыяллаһү ганһү 17 хәдис яки шул тирә риваять итте», — дисә дә[4], бу гыйбарәдә кайбер сүзләр төшеп калган булса кирәк. Чөнки Әбү Хәнифә башка мөхәддисләр** шикелле Хорасан, Мисыр, Йәмән һәм Нисапур кебек урыннарда йөрмәсә дә, бөек галимнәрдән һәм мөҗтәһидләрнең берсе булуына шөһбә юк. Шундый бер мөҗтәһид өчен унҗиде хәдис бик аз булса кирәк. Әбү Хәнифә хакында Хафиз Зәһәби: «Әбү Хәнифә Гата, Нәфигъ, Габдрахман бине Һүрмүз әл-Әгърәҗ, Гади бине Сабит, Сәләмә бине Көһәйл, Әбү Җәгъфәр Мөхәммәд бине Гали, Катәдә, Гамру бине Динар һәм Әбү Исхак һәм башка бик күп кешеләрдән риваять итә», — ди[5]. Бу телгә алынган затларның һәрберсе олуг мөхәддисләрдән, шулардан хәдис ишетеп тә, бөтен хәдисе унҗиде генә булу мөмкин түгел. Һәрхәлдә, сүзләре төшеп калуын төгәл белергә куәтебез булмаса да, Ибне Хальдун гыйбарәсендә хата барлыгына шөбһәбез юк[6]. Бу хата

Дәвамы. Башы журналның 9 нчы санында.

[1] «Раһуя» фарсыча булган «раһ» белән «вия»дән ясалган. Сәфәрдә вакытта тууы сәбәпле, «Раһвия» дип исемләнгән. Тел һәм әдәбият галимнәре «Раһуя»ны «сибуя» һәм «нәфтуя» кебек «уау»ның һәм аның алдында булган хәрефнең фәтхәсе, «йа»ның сәкене белән, мөхәддисләр «уау»ның сәкене һәм «ha»ның даммәсе, «йа»ның фәтхәсе белән укыйлар.
[2] Бу кемсәнең исеме төзүченең хатасыннан булса кирәк, «Мөкаддәмә вәфият әл-исляф»тә «Тәкый» дип басылган.
[3] Зәрканиның «Әл-мөваттаэ» шәрехендә.
[4] Т.1 — Б.217.
[5] Тәзкирәт әл-хифаз. Т.1. — Б.151.

***Мөҗтәһид — мөһим сораулар буенча мөстәкыйль рәвештә карар чыгару хокукына ирешкән дин галиме.**
**** Мөхәддис — хәдисләрне тирәнтен белүче.**

Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе

Ибне Хальдунның үзендә түгел, бәлки, күчереп язучылар тарафыннан ясалган. Әбү Хәнифәнең риваяте аз булуы — башкаларга караганда гына. Бу да сөннәт һәм хәдис гыйлемнәренә әһәмият бирмәүдән яки аларның кыйммәте аз булуыннан түгел, бәлки, шуны таләп иткән башка бер сәбәпләргә күрә.

Ниятләренең һәм максатларының хаҗәтенә, табигать һәм вөҗданнарының мәҗбүр итүенә күрә, кайбер сәләф (борынгы изге) галимнәр төзегән китапларын һәм җыелган хәдисләрен хәтта яндырганнар[7]. Шул сәбәпле, кайберләре үзләренең мисаллары белән аз риваять иткән булса да, гаҗәп булмас. Заманыбызда галим һәм куәтле мөселман булган шәех Җәмаледдин әл-Әфганиның бөтен хезмәтләре гәҗитләрдә язылган булганга, кайбер мәкаләләре кыска китапчыклардан гыйбарәт. Бу нәрсә исә югарыда күрсәтелгән хәзрәтләренең язу өлкәсендә көчсезлегенә, каләменең зәгыйфьлегенә юрау булмый. Шуңа карамастан, Әбү Хәнифә хәзрәтләре тарафыннан риваять ителгән хәдисләр соңгы галимнәр тарафыннан «Мөснәд Әбү Хәнифә» исеме белән китап рәвешендә төзелгән һәм кайбер нөсхәләре бастырылган. Күргәнебезчә, бер нөсхәсендә булган хәдисләр унҗиде микдарында гына түгел, бәлки, йөзләрчә.

Кайбер кемсәләр: «Хәдис риваять итүдә Әбү Хәнифәнең шартлары бик авыр иде, шуның өчен башкаларга караганда хәдисе аз булды», — дисәләр дә, моңа каршы: «Әбү Хәнифәнең шартлары никадәр авыр булса да, булыр, имам Бохари шартларына караганда, җиңел иде», — дип бәхәсләшүчеләр бар. Нәрсә генә булмасын, бу мәсьәлә ул кадәр әһәмиятле түгел. Мөҗтәһид өчен, үзенә кирәк кадәр хәдис риваять итсә, җитәр, артыграк риваять итү-итмәү үзенең ихтыярында. «Әгәр белмәсәгез, белгән кешеләрдән сорагыз!» (Коръән, 21:7.)

[6] Ибне Хальдун гыйбарәләрендә башка урыннарда ялгышлары барлыгы мәгълүм булганлыктан, бу җирдә ялгыш булачагында икеләнүебез булмады. Хәтта телгә алынган гыйбарә белән бергә килгән: «Мәлик рәхимәһуллаһның да «Мөваттаэ» китабында булган 300 тирәсе хәдис дөрес дип саналды», — җөмләсе дә дөрес түгел. Чөнки имам Мәликнең «Мөваттаэ»сында булган хәдисләрнең мөснәдләре генә дә моннан бик күпкә артыграк.

[7] «Кыйраэ сәбга»дан булган Әбү Гамру бине әл-Галәи әл-Мазәни әл-Басри җирдән өй түбәсенә кадәр тезелеп торган китапларын яндырганы риваять ителә. Вәфият әл-әгъян. Т.1. — Б.386.

V. ХӘДИСЛӘРНЕ ЯЗУ ХАКЫНДА РӨХСӘТ ҺӘМ ТЫЮЛАР

Олуг дәрәҗәле Коръән пәйгамбәрләрнең солтаны хөрмәтле рәсүл әфәндебез хәзрәтләре заманында һәм аның әмере белән язылып торган хәлдә, хәдисләрне язу хакында рәсүл саллаллаһү галәйһи вә сәлләм тарафыннан тыюлар булды. Моның белән беррәттән, хәдисләрне язу хакында рөхсәт итүне белдергән хәдисләр дә бар. Рөхсәт хәдисе буларак Мәккәне алган көндә: «Фәләнгә язып бирегез» хәдисе[8] һәм тыю хәдисе буларак «Минем сүзләрне язмагыз һәм кем миннән Корьәннән башка нәрсәне язды, бетерсен» хәдисе[9] дәлил итеп китерелә. Фәкать рөхсәт хәдисләре белән тыю хәдисләре бер җиргә китерелгәндә, тыю хәдисләре куәтле булачагы мәгълүм. Чөнки рөхсәт хәдисләре кайбер шәхесләргә һәм кайбер вакытларга багышланган булган, ә тыю хәдисләре гомуми [мәгънәдә]. Гасры сәгадәттә Коръән-шәриф язылган, хәдисләр язылмаган. Язу түгел, хәтта риваять итүдән дә кайбер әмирләр тарафыннан тыелуы риваять ителә. Хәзрәти Әбү Һөрайра: «Мин сезгә хәдисләр сөйләдем. Әгәр Гомәр бине Хаттаб заманында сөйләгән булсам, ул мине таяк белән суктырган булыр иде», — дигән[10]. Шулай ук Курза бине Кәгъб: «Гомәр бине Хаттаб безне Куфа шәһәренә җибәргәч, шәхсән үзе безне Саррар дигән җиргә кадәр озатты һәм шунда сорады: «Нәрсә өчен мин монда сезнең белән килгәнемне беләсезме?» Без җавап бирдек: «Аллаһ илчесенең иярчене буларак һәм әнсарлар* хакы өчен». Ул әйтте: «Ләкин мин шушы сөйләшү исегездә калсын өчен сезнең белән килдем. Анда сез Коръәнгә карата нәфрәттән йөрәкләре кайнап торган казан шикелле шаулап торучы халык янына килерсез. Алар сезне күргәч, муеннарын сезнең тарафка сузып, әйтерләр: «Мөхәммәд иярченнәре!» Шуңа күрә анда рәсүлүллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләм хәдисләрен азрак сөйләгез. Моннан тыш, мин сезнең белән аз гына булса да сәфәрдә катнаштым», — дип риваять итә.[11]

Рөхсәт белән тыю хәдисләрен куллану хакында имам Нәвави: «Рөхсәт — онытырга курыккан кеше өчен, ә тыю — бу нәрсәдән курыкмаган һәм язуына таянган кеше өчен. Яки Коръән белән кушылудан курыккан вакытта тыелды һәм ул куркудан имин булганда рөхсәт ителде», — дип мөрәҗәгать итә[12].

Пәйгамбәрләр горурлыгы булган әфәндебез хәзрәтләре Коръән-шәриф кебек хәдисләрне дә гыйбарәләре, сүзләре белән ятлау һәм Коръән-шәриф кебек, ләкин Коръәннән аерым рәвештә, язу хакында әмер итә иде. Шөбһә юктыр ки, хөрмәтле сәхабәләр хәдисләрне дә үзенә [күрә] башка рәвештә, гаять дикъкать белән ничек ишеткән, шул сүзләр белән ятлаганнар, арттыру һәм кимету ихтималларын калдырмыйча кәгазьләргә язган булырлар иде, шул сәбәпле, өммәттә таралып, ике китап кушылган булыр иде. Гасры сәгадәттән башлап, бер-берсеннән аерым рәвештә язылулары сәбәпле, олуг дәрәҗәле Коръән белән хәдисләрне катыштырмау һәм халыкларны да шөбһәләндерү ихтималы юк иде. Моннан тыш, Коръән-шәрифнең теле гаҗәп булу сәбәбле, сүзендә гаҗәплелек булмаган хәдисләр белән катышуы шөбһәләнү ки-

[8] Сахих әл-Бохари. — Т.1. — Б.36.

[9] Сахих Мөслим. — Т.2 — Б.393. Бу хәдис-шәриф шәрехендә имам Нәвави: «Әйтелде ки: чынлыкта, бергә кушылып, укучы буталмасын өчен, хәдисне Коръән белән бергә бер биткә язу тыелды. Аллаһ белүчерәк», — дип бер сүз сөйли. Т.12. — Б.412.

[10] Мохтасар җәмигъ бәян әл-гыйлем. — Б.175. Шуңа мөнәсәбәт белән замандашы булган бер зат: «Әгәрдә Әбү Һөрайра вафаты көненә кадәр хәзрәти Гомәр яшәгән булса иде, хәдисләрнең бик күбесен риваять итмәячәк, имеш», — ди.

[10] Сөнән Ибне Маҗә. Т.1. — Б.9. Хәдистә булган «һәзиз» тавыш мәгънәсендә, «мәрҗәл», якынча, казан мәгънәсендә.

[12] Тәкъриб. — Б.150.

***Әнсар — Мәккә мөселманнарын үзләренә кабул иткән Мәдинә халкы.**

тереп чыгармый иде. Шуңа күрә рәсүл хәзрәтләреннән никадәр хәдис чыкса, һәммәсе мәгълүм һәм саналган була, мәүдуг (уйлап чыгарылган), ялган хәдисләр булу ихтималына, хәдис буенча каршылыкларга, яла ягуга, ялган сүзләргә юллар калмый иде. Шул сәбәпле, хәдис гыйлеме һәркем өчен көн кебек ачык була, җәрех вә тәгъдилләр* өчен кагыйдәләр төзүгә, иснадлар** тикшереп, тоташкан яки киселгән, кабул ителгән яки кабул ителмәгән һәм башка моның кебек бәхәсләргә керергә юл калмый, хаҗәт төшми иде. Фәкать мондый бер хәл булмаган, бәлки, хәдисләр таркау һәм тик күңелләрдә генә һәркемгә мәгълүм булган рәвештә калган. Бу турыда безгә мәгълүм булмаган олуг сәбәпләр [дә] булуында шөбһә юк, безгә мәгълүм булганнары болар:

1) Аерым-аерым буларак ике бөек китап язу мөмкин булса да, бу хәл гасры сәгадәттән күпкә соң булган мәдәният гасырларына караганда [шулай тоела]. Кәгазь булмаган һәм язучылар да сирәк булган гасры сәгадәткә нисбәт белән бу эш мөмкин булмас иде. Хәтта ки Коръән-шәрифнең дә Мәккәдә иңгән өлешләренең күбесе күңелләрдә сакланып, бары тик Мәдинәгә һиҗрәттән соң гына язылган. Моның сәбәбе Мәккәдә булган хәлләрнең моңа ирек бирмәве булган.

2) Коръән-шәрифнең теле гаҗәп булса, бу нәрсә бары тик төзеклек һәм ятышлылык кагыйдәләре белән таныш булган аерым адәмнәргә һәм биек дәрәҗәләргә караган, бу да өч аять микъдары булу белән шарт ителгән. Әгәр дә Коръән-шәриф рәвешендә хәдисләр дә язылып барылса, әйткәнебезчә, адәмнәрнең башкалары да өч аятьтән аз булган хәдисләрдә һәрвакыт буталану һәм катышу ихтималы мәңге булыр иде. Моннан саклану йөзеннән хәдисләрне язудан тыю булган.

3) Хөрмәтле рәсүл үзе ширек бишегендә барлыкка килеп, мөшрикләрнең рухи хәлләре белән камил таныш булганлыктан, бөтен гайрәтен шуның орлыгын өзәр (бетерү) өчен сарыф итә иде һәм мөселманнарның бу адашуына кире кайтуларына сәбәп булачак нәрсәләрдән һәрвакыт саклау чараларын күргән. Әгәр дә Коръән белән бергә таралган рәвештә икенче бер китап буларак хәдис калган булса, кешеләрнең аны Коръән-шәрифкә тигез дәрәҗәдә тотачакларыннан һәм күпләрнең хәтта ике китапның ияләре арасында, Аллаһ сакласын, кайбер нәрсәләрдә тигез, дип уйлаулары ихтималыннан куркып, зарарсызрак әмерләрдән булган тарафны өстен күреп, хәдисләрне яздырмаган булса кирәк. Ислам дине камил җиткереләчәге [Аллаһ тарафыннан] тәэмин ителгәнлектән шулай уйлап эш итүдән тыю күрелмәгән. Хәдисләр, кирәк булса, язылсын, кирәк булса, язылмасын, өммәткә тәмам ирешүенә шөбһә юк.

Хәдисләрне язуда, риваять итүдә булган тыю дәлилләренең ятлау мәсьәләсенә катнашы юк һәм ятлаудан тыю барлыгы риваять ителми. Ихтимал ки, хәдисләрне язудан тыю, кешеләр язуларга таянып, ятлауга әһәмият бирмәсләр, дигән сәбәпкә нигезләнгәндер.

Дәвамы бар

Текстны басмага ***Айдар Гайнетдинов*** *әзерләде.* ■

***Җәрех вә тәгъдилләр — хәдис сөйләүчеләрне гаепләү яки мактаулар.**
****Иснад — хәдисне тапшыручылар (равиләр) чылбыры.**

БЕРЕНЧЕ ГВАРДИЯЧЕЛӘР

Шаһинур Мостафин,
әзтабар язучы, Россия Хәрби-тарихи фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы

...Мамадыш районының Урта Кирмән авыл җирлегенә караган Алан эшчеләр бистәсендәге буш нигезләрнең берсе янында, тирән уйларга чумып, басып торам. Мондый буш нигезләрне һәр авылда күпләп очратырга мөмкин. Һәркайсының – үз тарихы, үз моңы...

Минә бу нигезнең дә үткәне гыйбрәтле. Заманында биредә өч сугышта катнашкан бабам Ибраһим белән әбием Хәбибҗамал тормыш кичерә иде. Куе урман эчендә, яшел чирәмле тау битендәге түгәрәк аланлыкка урнашкан әлеге «оҗмах оясы»на без – аларның нәкъ бер дистә оныклары – өч чакрым ераклыктагы Арташ авылыннан еш менеп йөри идек. Бабай белән әбигә кышлык утын-печән хәзерләүдә, бакча эшләрендә, су китерүдә, малтуар карауда кулыбыздан, көчебездән килгәнчә теләп-яратып булыша идек. Өлкәннәрнең май кояшыдай балкыган рәхмәтле якты карашларын, кыстый-кыстый тәмләп сөтле чәй эчертүләрен һич онытасыбыз юк…

Бабам белән әбием әлеге төбәкнең бик хөрмәтле кешеләре иде. Гомерләре буе (бабай – 90 яшькә, әби 80 яшькә кадәр яшәде), күпләрне сокландырып, татуматур тордылар. Тик бәхетләре тулытүгәрәк булсын өчен бернәрсә җитми иде аларга. Ул да булса – бердәнбер уллары Миннегаянның сугыштан әйләнеп кайтмавы. Һәр көнне бабам белән әбием, аның яу кырыннан җибәргән беренче һәм соңгы фоторәсеменә карап, уллары белән исән кешедәй сөйләшә, күңелләрендәге шатлыкларын да, борчуларын да уртаклаша иде.

Аларның үз тормышлары белән икесе ике җирдә яшәүче кызлары – әниебез Гөлзәйнәп, апабыз Бибимәгъшия дә – очрашканда, бертуганнары Миннегаян абыйны чиксез сагынып-юксынып еш телгә ала, аның турында сөйләгәндә яулык читләре белән яшьле күзләрен еш сөртә иде. Шуңа күрәдерме, Ватан сакчысы булган Миннегаян абыебызның якты истәлеге балачактан ук безнең күңелләргә тирәнтен уелып калды. Без аны әкиятләрдәге өч башлы аждаһаны җиңгән пәһлеван батыр итеп күзаллый идек, аның белән ихлас күңелдән горурлана идек.

Сөйләүләренә караганда, чыннан да, яшьтән үк батыр йөрәкле, тәвәккәл, үтә булдыклы кеше булган Миннегаян абый. Туган ягында – күмәк

хуҗалыкта, беренче бишьеллыкларның удар төзелешләрендә тырышып эшләгән – мактаулы исеме телдән төшмәгән.

1941 елның мартыннан ул Кызыл Армия сафларында хезмәт итә башлый. Фашист илбасарларының безнең илгә каршы сугыш башлауларын да шунда ишетә.

Миннегаян абый танкка каршы ата торган артиллерия полкы составында Мәскәүдән Көнчыгыш Пруссиягә кадәр сугышчан озын юл үтә, рядовойдан орудие командиры дәрәҗәсенә күтәрелә, дәүләт бүләкләренә лаек була. «Дошманны эзәрлекләп, көне-төне алга барабыз, хәзер дошманны үз җирләрендә тукмыйбыз инде, тиздән туган нигезгә кайтыр вакытлар да җитә – көтегез!» – дип яза Миннегаян абый 1945 елның гыйнварында язган хатында. Әмма аңа бәхетле Җиңү көннәрен күрергә насыйп булмаган икән – сугыш бетәргә берничә ай калганда гына хатлар... өзелә. Озак та үтми, ул хезмәт иткән частьтан бабайлар йортына: «Сезнең улыгыз – гвардия өлкән сержанты Гаян Ибраһимов социалистик Ватан өчен көрәштә, хәрби антына соңгы сулышынача тугры булып, батырларча һәлак булды», – дигән хәбәр килеп төшә...

Ышанмыйлар карт белән карчык улларының үлгәнлегенә. Җиңү таңы атып, кайтасы фронтовиклар кайтып беткәч тә, бабай белән әби Миннегаян абыйны көтүдән туктамый. Бәлкем, исәндер, кайда да булса тоткарланадыр дип, һаман могҗиза көтеп яшәделәр. Әнә бит, кияүләре – Кызыл Йолдыз ордены кавалеры Әхмәтсафа солдат Мостафинның да үлгәнлеге турында ике мәртәбә кара хәбәр килгән иде, өченчесендә исә тере килеш (!) үзе кайтып төште. Авыр яраланып, контузия алып, ике күзе дә сукыраю, ишетә дә, сөйләшә дә алмау сәбәпле, госпитальләрдә озак дәваланган икән... Шуңа хат-хәбәре булмый торган... Азмыни андый язмышлар?!

Гомер буе сугышны ләгънәтләп һәм улларын көтеп яшәде өлкәннәр. Әмма иң зур, изге теләкләренә барыбер ирешә

Гвардияче Миннегаян Ибраһимов. 1941 елның ноябре

алмадылар – уллары белән кавышу шатлыгын татый алмыйча, бер-бер артлы җир куенына керделәр. Бабамның үләр алдыннан әйткән сүзләре шул булды:

– ...Тәки кайталмады улыбыз. Вакыт табып, Миннегаян абыеңның язмышы белән дә кызыксын әле, олан!

Ил Агасының – яраткан бабам Ибраһим Ситдыйк улының гозерләп әйткән васыятен үтәдем. Каһарман якташлар эзеннән СССР Оборона министрлыгының Үзәк архивында каткат булуым чорында гвардияче Миннегаян Ибраһимовның да сугышчан юлы белән җентекләп таныштым.

***

...16 нчы армиянең танкка каршы ата торган 289 нчы артиллерия полкы составында дошманга каршы көрәшеп, Мәскәү янындагы сугышларда зур батырлык үрнәкләре күрсәтә Миннегаян абый. Архив документларыннан күренгәнчә, 1941 елның 25 октябрендә алар полкы оборона тоткан участокка – Спасс-Рюховское һәм Ивлево авыл-

ларына таба дошманның 80нән артык танкы, дүрт дистәгә якын бомбардировщигы һәм ике батальон күләмендәге пехотасы һөҗүм итә. Көчләр тигез булмаса да, безнең артиллеристлар каушапкалтырап калмыйлар. Ике сәгатьтән артык дәвам иткән кискен көрәш вакытында дошманның 59 танкын, 5 самолётын һәм бер батальон пехотасын юк итәләр. Нәтиҗәдә, фашистлар чигенергә мәҗбүр була. Шушы гаять авыр шартларда да Миннегаян абый хезмәт иткән орудие расчёты, төз атып, дошманның 6 танкын яндыра.

«...Пушканы корып торучы иптәш Ибраһимов шушы җитди-кискен көрәштә үзен искиткеч батыр, тәвәккәл, җитез һәм иң кыен вакытта да каушап калмый торган салкын канлы, аек акыллы сугышчы итеп танытты, – диелә 16 нчы армия командующие – генерал-лейтенант Рокоссовский, артиллерия генерал-майоры Казаков һәм Хәрби Совет әгъзасы Лобачёв кул куйган Бүләкләү кәгазендә. – Ватаныбызның курку белмәс улы Гаян Ибраһимов «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүгә тулысынча лаек». (33 фонд, 682524 тасвирлама, 239 эш, 505 бит.)

Шулай итеп, абыебыз – кызылармеец Г.Ибраһимов – «немец илбасарларына каршы көрәш фронтында совет командованиесенең сугышчан заданиеләрен үрнәк төстә үтәгәне өчен», Көнбатыш фронт Хәрби Советының 1941 елның 5 ноябрендә игълан ителгән 0280 номерлы приказы нигезендә, беренчеләрдән булып, сугышчан бүләккә лаек була. Гаян абый хезмәт иткән 289 нчы артполк исә Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә һәм ул тиздән «Танкка каршы ата торган 1 нче гвардияче полк» дип үзгәртеп йөртелә башлый. Мәскәүне саклаганда «гвардияче» дигән гаять мактаулы исемгә иң беренчеләрдән лаек булган әлеге данлы полк артиллеристлары алда торган хәлиткеч сугышлар барышында да үзләрен арыслан йөрәкле батырлар итеп таныта. Башкорт Дүшәнбаев, белорус Клецко, украин Попович, казак Турсункулов, каракалпак Гурсунов һәм башкалар, иңгә-иң торып, дошман юлына мәңге бирешмәс алмаз кыядай торып баса. Күрсәткән батырлыклары өчен аларның күкрәкләрендә хөкүмәтебезнең югары бүләкләре балкый. Татарстаннан килгән сугышчылар да республикабыз данын югары йөртә! Мәскәү янындагы сугышларда Арча районының Шушмабаш авылыннан килгән Гыйльметдин Шиһапов – Ленин ордены, Актаныштан Мәгариф Галиәхмәтов, Әлмәттән Мансур Галәветдинов исә Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә.

Гаян абый да «Мәскәү оборонасы өчен», икенче тапкыр «Батырлык өчен» медальләренә лаек була. Соңгысы аңа Пущай торак пунктын һәм Орша шәһәрен азат итү өчен барган сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен бирелә. Архив документларыннан күренгәнчә, Миннегаян абый үзенең расчёты белән әлеге торак пунктларга иң беренче булып бәреп керә һәм, төз атып, дошман пулемётчыларын, миномёт батареясын һәм байтак солдатын юк итә...

Мондый мисалларны аның сугышчан тормышыннан байтак китерергә мөмкин. Күкрәгендә Ватан-Анага карата тиңсез мәхәббәт, дошманга каршы чиксез нәфрәт хисләре кайнаган гвардия өлкән сержанты – орудие командиры Гаян Ибраһимов, фашист илбасарларының күпләгән җанлы көчләрен һәм техникасын юк итә-итә, Көнчыгыш Пруссиягә кадәр данлы сугышчан юл үтә. Һәм 1945 елның 26 гыйнварында ныгытылган шәһәркрепость Кенигсбергны алу өчен барган сугышларда батырларча һәлак була. Нибары 23 яшендә...

Миннегаян абыебызның мәңгелек сыену тапкан урыны, изге кабере исә хәзерге Калининград өлкәсенең Полесск (элекке Лабиау) шәһәре уртасында. Батырны онытмыйлар – елның һәр фасылында да чәчәкләргә күмелә ул!.. ■

БАБАЛАРЫМ, ӘБИЛӘРЕМ...

Алмаз Хәмзин

Үземнең кемлегемне барлап утырам әле.

Бабам Зиннур искә төшә. Ни әйтсәң дә, аның нигезендә, ул салган йортта туган сабый бит мин. Гел бабай, әби янында үтте балачак. Әти дә, әни дә — көнозын эштә. Әби — мич, казан алдында, бабай — өстәл янында дигәндәй. Мин шунда мәш киләм, уйныйм, рәсем ясыйм, гомумән, үз дөньям, үз шөгылем. Тыныч кына яшәп булмый, энем Азат кысыла: уйный белми, чүкеч белән башка суга. Бишектә — нәни энем Айрат. Көйсезләнә башласа, әби аңа марляга эремчек төреп имезлек ясый да авызына каптыра. Еламый ул шуннан соң.

Миңа бабай ул чакта гел моңсу йөргән кебек истә калган. Беркөнне аның янына әллә нинди кешеләр килеп, кулын кысып, күкрәгенә медаль тагып китте. Әллә нинди батырлыгы өчен. Өйдә әби дә юк иде. Нигәдер, бабай елады. Елады дип, күзеннән яшь чыкты инде. Әти кайткач, ул медальне «Пленда күрсәткән батырлыклары өчен», — дип укыды. Шунда белдем: бабай да әтием шикелле сугышта булган икән. Тик аны әсир иткәннәр, ә әти аягын югалтып кайткан. Бабай үзе сугыш турында миңа беркайчан да сөйләмәде. Сөйләргә ярамаганлыгын соңыннан гына белдем, заманы шундый булган. Зиннур бабайның язмышы бик катлаулы һәм гыйбрәтле – ул турыда бер нык-лап язармын әле. Инде Сафа бабайга күчим.

Кайбер елларда мине җәй буена әнинең авылы Иштирәккә кунакка җибәрәләр иде. Миңа анда тагын да рәхәтрәк. Сафа бабай да, Мәчтүрә әби дә, ни кылансам да, сүз әйтми. Умарталары бар, умырып бал ашыйм; сыерлары күп сөт бирә – каймак сыпырам, аннан соң бабайга булышам. Ул халыктан сөт җыя. Мин исә, бик тырышып, аның майлылыгын тикшерәм. Кысылып йөрим инде шунда, комачаулый торганмынмы?.. Әйтүче юк. Аннары бабай белән тире җыябыз. Мин сыйфатын карыйм: тишекләре, җыртыклары юкмы? Бабай сыйфатсызлыкка бик бәйләнми, күрше авыл җыючысын гел сүгәләр, шуңа күрә дә ул авыллар үзләре дә тирене бабайга китерә.

Бабай үзе сугыш турында миңа беркайчан да сөйләмәде. Сөйләргә ярамаганлыгын соңыннан гына белдем, заманы шундый булган.

Без бабай белән умарта карыйбыз. Ул миңа яуда күргәннәрен сөйли. Сугышның дөньяда иң акылсыз гамәл икәнен аңлата. Тик менә үзенең бик озак әсирлектә ятуын әйтмичә калган икән, соңыннан белдем. Зиннур бабай кебек, аңа да рәхәт булмаган. Әле Сафа бабайга үләргә дә туры килгән – анысын соңрак язармын.

Зиннур бабай

Сафа бабай

Кечкенә вакытта бер рәхәтлектән икенчесенә күчеп кенә йөргәнмен икән мин. Рәхмәт барысына да!

Үсә төштем, студент булгач, Казаннан авылга еш кайтам. Акча кирәк, бәрәңге, ит! Бар булганын бирәләр, укысын гына, диләр. Әле җәй көне кайтып йөрүләр истә. Мин кайтасын белеп, әбием Мәликә һәрвакыт капка төбенә чыгып утыра. Туксан биш яшь үзенә. Сөбханалла, таза-сау. Ходай Тәгалә алда да гомерен озайтсын! Янына якынлашу белән ул миңа:

– Нихәл, улым, кайттыңмы? Мин һаман исән бит әле, – ди.

– Әй, әбием, – мин әйтәм, – синең исән булуың шулкадәр шатлык, менә бит әле берәү дә каршыларга чыкмаган, ә син беренче булып кул бирәсең. Бәхет бит бу. Берәүнең дә мондый әбисе юк!

– Рәхмәт, улым, яхшы сүзеңә. Шулай да күп яшәдем инде, Ходайның рәхмәте, сез – оныкларым да йөзебезгә кызыллык китермәдегез. Телевизордан карап кына торабыз сине.

– Әби, әле син барында булдырабыз аны. Яшә генә! Тик озак яшәвеңә зарланма, яме! Кадер-хөрмәттә гомер итәсең, улларың, кызларың, оныкларың янәшәңдә. Икенче кайтуымда да шушында утырып каршыла, яме!

– Ярар, улым, исән-сау булсак, шулай итәрмен...

Сумкаларны тутырып, Казанга китеп барам. Вакыт дигәнең үтә тора, кесә такырая, эчләр суырыла, өйдәгеләрне сагынуның чамасы юк. Ябыккан сумканы алып, яңадан авылга сыпыртам. Әби капка төбендә:

– Әй, улым, әйтергә дә оят инде, мин һаман да исән бит әле, – дип каршы ала. Исән-саулыкка сөенешеп күрешүләр һәм үткән елгы шаяру катыш әңгәмәбез яңадан кабатлана.

Әбинең соңгы көннәренәчә – йөз дә бер яшенә кадәр — чөкердәшеп, сөйләшеп яшәдек. Урыны җәннәттә булсын! Аның урынында – капка төбендә — хәзер әнием утыра. Картлык шулай итә торгандыр инде, сагындырадыр... Һай, шуны белә торып та, сирәк кайтабыз шул туган нигезгә...

Мәчтүрә әбием турында язмадым бит әле. Матур әбиләрем күп. Ләкин әнинең әнисе – Мәчтүрә әбием кебек йомшак, киң күңелле, бер гөнаһсыз әбиләр сирәктер. Аның пешергән ашлары, аның кигән күлмәкләре, аның

Мәчтүрә әби

Мәликә әби

Әбинең соңгы көннәренәчә – йөз дә бер яшенә кадәр – чөкердәшеп, сөйләшеп яшәдек.

назлы сүзләре!.. Юк, аны кабатлап булмый. Аны бары тик күзеңне йомып, күз алдыңа китереп, күңелдән кичерергә генә була. Минем аңа пышылдап: «Әби, әби!..» – дип эндәшәсем килә. Ул, борылыр да, миңа: «Нәрсә, улым? Кулыңны канаттыңмы?» – дияр. «Пычак белән уйнамыйлар аны, ул – уенчык түгел», – дияр сыман һәм матур итеп чүпрәк белән бәйләп куяр. Ачуланмый гына назлап әйткән сүзләреннән бармак киселмәгән булып китә, авыртмый да.

Икенче вакыт мин тагын әбигә эндәшәм: «Әби, әби!» – «Нәрсә, улым? Һай, ул юньсез малайларны!.. Сугыштыгызмыни?.. Күзеңә төрттеләрме? Кылычлы уен куркыныч ул! Менә син үскәч, шафир булам, дисең, күзсез нишләрсең? Әй, балалар, ярамый, дисәң дә үзләренекен итә инде алар...»

Әби догасын укый. Күрәсең, Ходайдан мине бәла-казалардан саклауны сорый.

Мәчтүрә әбием дә туксанны узды. Хәтере бик начарланды, ләкин гадәтенә сеңеп калган ягымлылыгы кимемәде. Әни белән янына Иштирәккә баргач, яшь чакларны сөйләшеп утырабыз. Әби, тыңлый да, ара-тирә: «И, гүмерләр!» – дип куя. Язмышыннан канәгать рәвештә дисбесен тарта. Үзе өчен генә түгелдер,

балалары, оныклары, гомумән, алдагы хәерле, бәрәкәтле тыныч тормыш өчен иреннәрендә дога сүзләре тирбәләдер аның.

Сирәк кенә булса да әби-бабаларым, ягъни кода-кодагыйлар сабан туе алларыннан безгә – Зиннур бабайларга җыела иде. Әле алар янына күрше авылдан әтинең сеңлесе Динә апаның каенатасы Зиятдин бабай да чакырыла. Ул да пленда булган. Менә ичмасам бәйрәм башлана. Ләкин бу бәйрәмнең күп өлеше һаман шул каһәр суккан сугыш газаплары белән бутала иде. Зиннур бабай үзенең ничек итеп, үкенечле рәвештә Волхов фронтында камалышта калып, әсирлеккә эләгүен сөйли. Концлагерьда немецләрнең безнең илгә каршы татарлардан легионнар оештыра башлагач, анда бармавын, сугышның ахырынача эттән дә начар тормышта гомер кичерүен бәян кыла...Әй, Алла! Ни генә күрмәгән икән газиз бабам!

Аны аш бүлмәсендә тыңлап торган әбиләрем, әни, апаларым елый башлый.

Инде Зиятдин бабай сүз башлый:

– Концлагерьда исән калуымның сәбәбе бер генә булды. Үзегез беләсез – мин тегүче бит. Немецләр шуны белеп алдылар. Бер ватык тегү машинасы китерделәр, шуны төзәтеп, әсирләрнең күлмәк-ыштаннарын, бишмәтләрен ямап-җөйләп, немесләрнекен рәтләп ышәдем. Немесләр шуңа ипи сыныклары, һәм башка калдык-постыклар биргәли иде. Тоткыннар белән бүлешеп тордым. Безне әнә шул тегү машинасы үлемнән коткарды. Ә күпләребезгә хәзерге тормышны күрергә насыйп булмады. Көн саен лагерьдан, арба-арба төяп, «җәһәннәм»нән котылганнарны үлек базына ташыйлар иде...

Хатыннарның елавы көчәя төшә. Сүзгә Сафа бабай кушыла:

– Менә мин шул баздан чыккан кеше инде. Үлгәнемне хәтерләмим. Бик каты чирле идем. Ни өчен бу вакыйганы беләм, соңыннан концлагерьдагы дуслар сөйләделәр. «Сине, беткән инде бу, барыбер үләчәк, дип, арбага салып, алып чыгып киттеләр», – диләр.

Әйе, мин берзаман аңыма килеп уянып киттем. Ниндидер базда, үлекләр өстендә ятам. Үлгән кеше дә сикереп торып басарлык яман әшәке ис бугаздан кыса. Белмим, нинди көч тапканмындыр, бу чокырдан мин үрмәләп чыга алдым. Таң атып килә иде бугай. Төнлә үлгәннәрне җыючы мәет арбасы минем янда туктады. «Карале, – диде ахрысы арбаны озатучы нимес сакчысы, – тере бит бу». Мине, арбаны бушаткач, яңадан лагерьга алып керделәр...

Аш бүлмәсе ягындагылар тыела алмый үкси үк башлады.

– Менә шуннан соң, – дип дәвам итте Сафа бабай, – тернәкләнеп киттем. Хәзер сезнең каршыда утырырга насыйп булган.

Шулчак Зиннур бабай өстәлгә тозлы балык астына җәелгән район газетасыннан бер рәсем күреп алды.

– Карагыз әле, күрше авылдагы безнең гадук Гәсимгул түгелме соң бу?! Гаиләсе белән. Рәсем астына «Бәхетле гаилә» дип куелган. Айяй болар үрчегән. Зиятдин кода, син аны беләсең. Сволочьны! Без сугышта йөргәндә дизиртировать итеп калган ул. Хайван! Бармакларын имгәтеп. Менә шул хәзер «Алтын кеше» булган! Кара син аны!..

Гәҗитне чүп чиләгенә бәрделәр.

– Әйе, ул заманда төрлесе булды! Хәзергесен хәерлегә әйләсен! Әйдәгез, кодалар, бүгенге гадел тормыш өчен! – дип, Зиннур бабайның сабан туена махсус әзерләнгән балын чәкештереп куйдылар.

– Еламагыз, хатыннар! Без чиста яшәдек, сезгә безнең өчен кызарырлык булмады! ■

ДӘҺШӘТЛЕ ЕЛЛАР ХАТЛАРЫ

Әлфия Шамова

Бөек Ватан сугышы башлану белән үк язучыларыбызның күбесе хәрби сафка басты, кулларына корал тотып, фронтның алгы сызыкларында булды, окопларда ятты, атакаларга барды, илебезнең азатлыгы, бәйсезлеге өчен каннарын, җаннарын аямады.

Ул көннәрдә фронттагы язучыларыбызга бик зур бурычлар йөкләнгән иде. Бердән, алар дошманга каршы чын солдатларча батыр сугышырга, дошманны кырырга, бетерергә, юк итәргә тиеш булсалар, икенчедән, язарга, иҗат итәргә, ялкынлы сүзләре белән сугышчыларны батырлыкка рухландырырга тиеш иде. Язучыларыбыз бурычның икесен дә намус белән үтәде.

Ут эчендә йөрүче татар язучылары, сугыш тынган араларда вакыт табып, бер-берләре белән даими рәвештә хат

Хатип Госман

Аларның кайберләре сакланган. Аларны кулыма алгач, бу хатларны язган язучылар күз алдыма килеп басты...

Өчпочмаклы хатлар... Фронт хатлары... Алар, гадәттә, карандаш белән язылган, кайберләре, еллар үтү белән, саргая башлаган, танымаслык хәлгә килгән. Бик күп хатлар вак, хәтта чамадан тыш вак хәрефләр белән төрле-төрле төстәге, төрле күләмдәге кәгазьләргә язылган: папирос кәгазенә дә, әйбер төрә торган сары кәгазьгә дә язылган хатлар!

Бу хатлар мине Татарстан Республикасының Милли архивына алып килде. Анда казынып, башта мин Язучылар союзы фондының хатларын гына укыдым. Аннары, эзләнүләр барышында, кызыксынып, язучыларның шәхси архивларында сакланган хатларына юлыктым. Аларның хатлары мине үзләренең гадилеге, тыныч тонда язылулары белән сокландырды. Аларны бик кызыксынып, дулкынланып укып чыктым һәм журналда бастырып чыгарырга бик тә вакыт дип, үземнең бурычым итеп санадым.

Тылда эшләгән язучылар да Казаннан фронтка — каләмдәш иптәшләренә — хат җибәреп торган. Аларның хатлары исә яхшы кәгазьгә кара белән язылган, ләкин, кызганыч ки, алар архивларда да бик аз.

Хатларның күбесе окопларда, ут эчендә, снарядлар шартлаганда язылган булсалар да, аларда зар, моң, әрнү, сыкрану әсәре юк диярлек. Анда бары дошманны тар-мар итү, җиңеп кайту турындагы ялкынлы теләкләр белән бергә, киләчәк матур тормыш турындагы уйлар, хыяллар гына бар.

Өчпочмаклы хатлар... Фронт хатлары... Дәһшәтле еллар хатлары!

язышып торган. Бу хатларда аларның дошманны җиңүгә зур ышанычлары, шундый авыр көннәрдә дә татар әдәбиятының язмышы, каләмдәш иптәшләренең язмышлары турында кайгыртып торулары, үзара иҗади дуслыклары ачык күренә. Бу хатлар язучыларның фронттагы тормышын, аларның уй-хисләрен, омтылышларын, кайгыртучанлык тойгыларын, иҗади эшен дә, совет кешесенә хас гомуми рухны да ачык чагылдыра.

Әтинең архивында фронттан өйгә: әбиемә, әниемә, безгә — дүрт балага, туганнарына язылган хатлары сакланган. Йөз алтмыш бер хат! Барысы да әтинеке, аның уйлары, аның фикерләре, хыяллары...

Моннан тыш, әтием сугыш елларында вакытлыча тылда калып торган чакта да, фронтта чакта да, каләмдәш дуслары белән хат язышып торган.

ХАТИП ГОСМАН[1] ХАТЛАРЫ

1941 елның 13 июлендә Х.Госман фронтка китә. Ул башта артиллерия полкы штабында, аннары укчы дивизия газетасында, 1942 елның 23 августыннан Төньяк-Көнбатыш фронтының «Ватан өчен» газетасы редакциясендә хәрби корреспондент булып, ә 1944 елның сентябреннән Икенче Белоруссия фронты гаскәрләре составына кергән Беренче гвардияче инженер-сапёр штурм бригадасында клуб мөдире булып хезмәт итә, сугышны Германиянең Гюсторф шәһәрендә тәмамлый.

Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен ул Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

ХӘМИТ ЯРМИГӘ[2]

Ярми, Агиш*[3]*, Хәй*[4] *абый, Әмир, Җәләй*[5] *ага һәм Шабанов!

Сезгә фронттан яңа ел сәламе.

Мин, миллионнар арасына кереп, сезнең күздән югалдым ахры, сездән ни сәлам, ни хәбәр юк. Ә мин, чынлап әйткәндә, югалмадым гына түгел, киресенчә, зур өметләр һәм күңелем тулы якты хисләр белән яңа — 1942 нче елга атлыйм.

«Үлем немец оккупантларына!» — менә безнең лозунг. Нәкъ 700 ел элек — 1242 елда немецлар Чуд күлендә тар-мар ителгән булсалар, 1942 нче елда аларны тагын да рәхимсезрәк һәлакәт һәм тар-мар ителү көтә. Без җир йөзендәге барлык гүзәллекнең иҗат итүчесе — Кеше өчен сугыш алып барабыз, аның бөек иҗат җимешләрен — культураны һәлакәттән саклап калу өчен көрәшәбез. Бу көрәш авыр, ләкин безнең халыкның кодрәтле рухы бу авырлыкны җиңеп чыгар һәм бөтен халыкларга азатлык һәм тыныч тормыш алып бирер. Без моңа ышанабыз һәм 1942 ел безнең ышанычларны чынбарлыкка әверелдерәчәк.

Сәлам дуслар!

Безнең җиңү елыбыз башлану белән һәммәгезне дә чын күңелдән тәбрик итәм!

Сугышчы Хатип Госман.
Төньяк-Көнбатыш фронт.
31.12.41.

---

[1] **Хатип Госман** (1908-1992), язучы, әдәбият галиме.

[2] Хәмит Хөснетдин улы Ярми (Ярмөхәммәтов) (1904-1981), фольклорчы, 1942-1944 елларда — Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры. 1944-1971 елларда — Тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты секторы мөдире.

[3] Якуб Хәлил улы Агишев (1899-1972), әдәбият белгече, текстолог.

[4] Габделхәй (Хәй) Хисмәтулла улы Хисмәтуллин (1895-1977), әдәбият галиме, текстолог.

[5] Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдинов (1894-1966), тел һәм әдәбият галиме.

ГОМӘР БӘШИРОВКА[6]

Гомәр!

Менә мин мәгълүм машина янында утырам һәм бармакларым клавиатура өстендә йөгергәләп йөриләр, ә тирәягымда сиңа хәзер бик ерак, ләкин бик таныш кешеләр тезелеп утыралар: алар һәммәсе дә сиңа сәлам, сәлам дип торалар.

Бүген бездә, син китәр алдыннан булган шикелле, ыгы-зыгы, синеңчә әйткәндә, «кет-кет»[7] *Казанга китәргә җыена. Берничә сәгатьтән ул безнең һәммебез өчен бәхеткә тиң булган юлга чыгачак. «Кет-кет»не күрерсең, әлбәттә, ул сиңа бу хатны тапшырыр.*

Менә хәзер миңа туп-туры итеп, өтерләр патшасы[8] *карап утыра. Непременно сиңа аерып сәлам әйтергә куша, сәламенә беркадәр ачу салып җибәрергә исәп итә ахры: аның кулъязмалары уңае белән бернәрсә дә хәбәр итмәдегез ич. Менә тагын шагыйрь*[9] *синең хөрмәтеңә мөнәҗәт чыгарып утыра. (Мөнәҗәтен хат ахырында гына игълан итмәкче.)*

Инде минем үземә килгәндә, болай бик простой итеп кенә сәлам әйтергә дип утырам.

Әй, менә кызык кына хат язарга исәп иде, һәммесе дә таралып киттеләр. Үзем генә утырып калдым. Тонны үзгәртергә туры килә.

Кыскасы: эшләр бездә син бар чактагы төсле бара. Син безнең газеталарны күрә торгансыңдыр. Алардан карап эшебезнең ни төстәрәк торуын үзең дә чамаларга мөмкин. Тик минем андагы иптәшләргә бик ачу килеп йөри: нигә ул язучы мәсьәләсен болай сасыттылар инде? Бу, әдәпле генә итеп әйткәндә, безобразие. Казандагы кайбер кешеләр өчен фронтка язучы җибәрү тау кадәр бер эштер инде. Ә заман көтми. Язучының фронтка килүе иң гади гражданлык эше. Руслар да шулай карыйлар һәм шулай эшлиләр дә. Казанда гына нигәдер артык дәрәҗәдә акыллы башланалар. Подумаешь!

Мин синең белән җибәрә алмаган нәрсәне Әхмәди белән җибәрәм. Ул аны Фатих Хөснигә[10] *тапшырыр. Сез карап, аны журналга бассагыз иде. Журналга күләм ягыннан артык озын дисәгез, турыдан-туры китап итеп Татгосиздатта басыгыз.*

Әдәби иҗат планым турында мин сиңа сөйләгән идем. Шул план тулысы белән эшкә ашырылачак. Алда — пьесаны төгәлләү. Ләкин эштә бик еш өзеклекләр чыга тора. Анысы үзеңә мәгълүм. Монда минем соңгы вакытта очучылар белән дуслык була башлады. Татарлардан яхшы ук атаклы очучылар бар.

Инде тагын нәрсә язарга. Бернәрсә дә язмаска!

Хәзергә хуш!

Сәлам белән Хатип Госман.

27 январь 1943 ел.

ТР МА. Р-6529 фонд. 1 тасвирлама. 104 эш. 1, 1 әйл. бит. Төп нөсхә.

Гомәр дус!

Сиңа һәм синең подразделениеңдәге[11] *барлык егетләргә һәм кызларга сәлам.*

Мин исән. Аннан да бигрәк, син исән икәнсең — шунысы өчен сөендем. Сәламәтләнеп җитүең — бик сөенечле хәл. Югыйсә, синең хәлне миңа бик хәвефле итеп сурәтләгәннәр иде.

[6] Гомәр Бәширов (1901-1999), язучы, партиянең Өлкә Комитеты командировкасы белән Төньяк-Көнбатыш фронтында «Ватан өчен» исемле газетада 1942 елның 23 августыннан ике ай хезмәт итә.
[7] Габдулла Әхмәдиев — журналист, шул газетаның тәрҗемәчесе.
[8] Нәфик Яһудин (1910-1977), сержант, шул газетаның корректоры.
[9] Шәрәф Мөдәррис (1919-1963), шагыйрь, солдат, шул газетаның хәрби корреспонденты.
[10] Фатих Хөсни (1908-1996), язучы.
[11] Радиокомитет хезмәткәрләре.

Син миңа хат язгансың. Алдым. Бик сөендем. Бергәләшеп, көлә-көлә, рәхәтләнеп укыдык. Мондагы егетләрнең һәммәсе дә сиңа сәлам тапшырырга куштылар.

Мин җибәргән әйберләрне тапшыра торасыз икән, анысы өчен бик зур рәхмәт. «Генерал»ны тапшырдыгызмы? Тапшыргач, «К.Татарстан»га бирсәгез иде. Якуб[12] абзый турында халык белеп торсын. Ул — безнең сирәк картларыбыздан берсе.

Бу араларда сезгә очерклар җибәрә алмадым. Чөнки язмадым. Ни өчен дисәң, Казан өчен тагын бер китап әзерләп ятам. Исеме «Ут сызыгында» булыр. Бу турыда моннан берничә көн элек Кәшафка хәбәр иткән идем. Зур әйбер өлгертеп булмады, 3-4 табаклык бер китап басып ташларга кирәк.

Син андагы хәлләр белән безне шулай таныштырып тор инде. «Совет әдәбияты»ның 4 нче номеры килде. Әмирхан Еники хикәясеннән башка материаллар миңа бик сыек тоелдылар. (Тукай турындагы бер-ике мәкаләне искә алмыйм).

Минем хатынга сездән тиешле булган акчаны биреп җибәрә алмассызмы.

Хат яз.

Дусларга сәлам белән,
Хатип Госман.
22.7.43.

ТР МА. Р-6529 фонд. 1 тасвирлама. 104 эш. 2 бит. Төп нөсхә.

Кадерле радио-Гомәр хәзрәтләре!

Җәнабе Галиләрегезгә вә хәләл җефетегез һәм балаларыгызга күп сәлам. Сәлам бәгъдендә сүзем шулдыр: «Ярсу» исемле бер хикәят җибәрәм. Сез аны үзегезнең бөтен дөньяга ишетелеп тормыш көчле вә кәраматле авызыгыз белән татар халкына мәгълүм итәрсез. Мәгълүм иткәннең соңында, үзегезнең юктан назариягез лаек күргәнчә, берәр җирдә нәшер итәрсез («Совет әдәбияты» яки «К.Татарстан»).

Офицер Мирсәй әфәнде Әмиров үзенең сала әтрафларига булган сәяхәтеннән кайттымы? Кайтса, сәлам тапшырыгыз һәм аның белән алышуны яңартып җибәрергә хәзер булып калам.

Безнең егетләрдән сиңа һәм сезгә сәлам. Кичә Гыйльманов[13], я Кавине[14], я Газизне[15] җибәрүләрен сорап, сездәге тиешле оешмаларга телеграмма җибәрде. Карагыз, әшне сез анда корырак тотып, ике егетнең берсен җибәрүне тизрәк оештырыгыз.

Хатип Госман.
4.8.43.

ТР МА. Р-6529 фонд. 1 тасвирлама. 104 эш. 3, 3 әйл. бит. Төп нөсхә.

Мирсәй!

Союзда син председатель бугай. Сугыш тәмам. Мин Германиядә ходатайлык кылмыйча, мине тиз генә кайтармаслар. Тизрәк ГлавПУРККА[16] аркылы ходатайлык кылуыгызны үтенәм.

Минем полевая почта номеры 89580.

Үтенеп, Хатип Госман.
15.05.45.

ТР М. Р-7083 фонд. 1 тасирлама. 176 эш. 26 бит. Төп нөсхә.

Хатларны һәм искәрмәләрне басмага ***Әлфия Шамова*** *әзерләде.*

[12] Якуб Җиһангир улы Чанышев (1892-1987), хәрби эшлеклесе, генерал-лейтенант.
[13] Гани Гыйльманов, политрук, журналист, шул газетаның җаваплы мөхәррир урынбасары.
[14] Кави Нәҗми (1901-1957), язучы.
[15] Газиз Иделле (1905-1985), язучы.
[16] ГлавПУРККА — Главное политическое управление Рабоче-Крестьянской Красной Армии.

Радик Әминов фотосы

«Кукмара районының Зур Сәрдек урта мәктәбе директоры, Русиянең атказанган укытучысы Закирҗан ага Сабитов (рәсемдә) бик тә сәнгать җанлы инсан иде. Берзаманны ул укытучылар белән «Сүнгән йолдызлар»ны сәхнәләштереп, көтүче малай ролен уйнауны миңа, бишенче сыйныф баласына ышанып тапшырды. Директор абый мәктәптәге алты йөз кырык укучы арасыннан нигә нәкъ мине сайлап алгандыр — әлегәчә төшенеп җиткәнем юк».

1971 ел

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Газинур Морат

«Туган нигездә әти-әни белән төшкән беренче һәм соңгы сурәт бу. Әгәр олуг язучыбыз Марсель Галиев очраклы рәвештә генә фотоаппаратын онытып калдырган булса, дөньяда минем өчен иң кадерле ядкяргә әйләнгән әлеге мизгел беркайчан да кабатланачак түгел иде...»

Июнь, 2003 ел

Фазыл Вәлиәхмәтов фотосы

«1991 елның 27 маенда, ягъни сәяси ачлык тотуның соңгы көнендә, Ирек мәйданында зур митинг булды. Ихтимал, XX гасырда җитмеш меңләп татарның бергә җыелып, бер тән, бер җан булып яшәп алганын рәсми тарих инде хәтерләми дә торгандыр. Шул көнне мәйдан алдында шигырь уку вазифасы, чын трибун шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан тәкъдиме белән, миңа йөкләнгән иде».

«2008 елда язучылар, җыйнаулашып Изге Болгар җыенына барган иде. Җыен тәмамлангач, Идел ярынарак елышып, корбан чалдырып, казан асып, сәйран кылып та утырырга туры килде. Мәҗлесебезнең хуҗасы, әлбәттә, хәзрәти Туфан ага Миңнуллин үзе иде».

Ләбиб Лерон фотосы

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Тыңлап, Илбик әйтте: — Оттым сүзеңне.
Тагын бер сорауга җавап бир инде:

Аңлат миңа капу башы турында:
Бу эш булсын икән кемнәр кулында.

ҮГДЕЛМЕШ КАПУ БАШЫ БУЛЫРГА НИНДИ ИР КИРӘКЛЕГЕН ӘЙТӘ

Җаваплап, Үгделмеш әйтте: — И, илбик,
Исән-тыныч яшә, и, күңле изгем.

Капу башы булсын ару кешедән,
Җаны-тәне белән эшкә мөкиббән,

Караңгы төшкәнче торсын капуда,
Һәм шунда ук булсын ул таң атуга.

Белсен үз эшенең заңын-низамын,
Уңай-төз холыклы да булсын тагын.

Тоз-икмәк күп булсын ир-яугирләргә,
Алтын-көмеш җыйсын әйбәт түләргә.

Төнгә каршы үзе ятмастан борын
Күрсәтсен ул һәрбер сакчыга урын[1].

Ерактан мөсафир килсә — сорарга,
Белдеклесе булса, хәбәр тыңларга.

Кальга капкаларын бикләткәч, шуннан
Көндәлек эш инде тәмам да булган.

Капкаларны иртән тикшерә, торып,
Сакчыларны шунда ук алмаштырып.

Әгәр илбик «кабул итәм», дип әйтсә,
Йомышы барларны тезә бер рәткә.

Хәбәр итеп чыга илбик яныннан,
Тиз генә — кешегә вакыт калдыра.

Каравыл әһелен бер җыеп, барлый,
Карый һәм бу көнлек эшләрне саный.

Илбикнең кабуллык вакыты беткәч,
Каравыл хакында керә илбиккә.

Белсен үз эшенең заңын-низамын,
Уңай-төз холыклы да булсын тагын.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Урын – монда «пост».

Ягъни яугирләрнең теләген әйтә,
Берәй мохтаҗлыны белгәнен әйтә.

«Бүләклә», дип илбик, бирсә хак, көмеш,
Шәрәфле ат-исем, төшемле йомыш,

Әйтә — кайсы егет ярашып эшли,
Кайсы бик тырышмый, сәлкәү йөрешле,

Кайсы яраклы һәм кайсы мәгънәле,
Кайсы булдыклы һәм кайсы файдалы.

Шуларны илбиккә тәгърифләп бирә:
«Фәлән кешене, ди, күтәрү кирәк».

Чыккачтын илбиктән фәрман китерә,
Әйбәт егетләрнең күңлен күтәрә.

Капуда торасы урнын билгели,
Каравылның кизү корын[2] билгели.

Күреп ала килгән ят кешеләрне,
Бәяли кылынган яхшы эшләрне.

Китерелгән ләвәш, ашка күз ата,
Яраксыз булганда кире озата.

Бик игътибар белән карый сораны[3]:
Китергәндә беркем эчмәсен аны.

Аш-ләвәшне гадел өләшкән чакта
«Бу илбик нигъмәте ул», дип күз ата.

Карый — бер корын[4] да ашсыз калмасын,
Эчтә дә, тышта да ач ук калмасын.

Ике шәй күтәрә биләр абруен:
Кулында — байрагы, түрендә — сые.

Янә ике нәрсә капу күркедер,
Бийгә бәхет юлы, шөһрәт китерер:

Ике шәй күтәрә биләр абруен:
Кулында – байрагы, түрендә – сые.

Бере — олуг хаҗип азат булуы[5],
Икенчесе — капу башы холыгы.

Болар сәрай — капу эшен башкара,
Җәйрәтә бий һәм ил атын илара.

Тагын түшәкчегә, табакчыларга,
Ашчыга күз ташлый һәм тугчыга[6] да.

Янә кошчы, кишче[7] һәм ук-җәяче
Көн дә әзер-хәзер торсын һәммәсе.

Кайчакта хезмәттәш, иптәш-кулдашын
Өйгә алып килеп, ашата ашын.

Ашатып-эчертеп, сыйлап-туйдырып,
Тагын да күчтәнәч җибәрә биреп.

Үзенә бер тирке[8] корал, ат-тунын
Калдырып, дусларга бирә артыгын.

Читтән кеше килеп хезмәткә керсә,
Аны сыный, торак хәстәрен күрә.

Азыклану урнын, атын һәм тунын[9],
Һәм бүтән эшләрен хәл итә шуның.

Янә сораштырып торырга кирәк
Гаскәр ачмы-тукмы, бармы тун-упрак[10].

Калса бер гаскәри моңда — тарлыкта,
Хәленә кер, кордашлык хакын үтә.

Сәрайга килмәсә кем дә кем беркөн,
Сорашып белергә кирәк сәбәбен.

Калса бер гаскәри моңда – тарлыкта,
Хәленә кер, кордашлык хакын үтә.

[2] Кизү коры – «дежур команда».
[3] Сора — нииндидер эчемлек.
[4] Ягъни экономияләү җәһәтен дә уйлый. Корын — монда «команда».
[5] Бу мизгел бигүк аңлашылмый: олуг хаҗип һәрвакыт азат кешедән булмады микәнни?
[6] Тугчы — (байракчы) тыныч тормышта нишләгәне ачык түгел.
[7] Кишче — сүзе аңлашылып бетми: үзбәкчә нәшердә «сусар тотучы» дип бирелгән. Безнеңчә, бу шикле аңлатма. Фарсыча киш «үк савыты».
[8] Тирке – «комплект».
[9] Ат һәм тун – фразеологизм, «хәрби амуниция һәм атлары» мәгънәсендә.
[10] Тун-упрак – «мундир». Упрак — «обмундирование» (кешегә дә, атка да карый).

Тугры кол күзәтми үз мәнфәгатен,
Бәк өчен тырышу — аның гадәте.

Аурый икән — хәлен сорарга кирәк,
Азып йөри икән — тыярга кирәк.

Бу эшләр илбиккә тугрылык та ул,
Аны шат һәм тыныч хәлдә тота ул.

Колак сал — ни сөйли хезмәтле яугир,
Бийгә хезмәт итеп хөрмәт тапкан ир:

«Гамәлдәр[11] илбикне яратыр булсын,
Ярату дигәнем — тугры ир булсын.

Бәкләрнең үз эшен яраткан колы
Эзләр хуҗа хәлен яхшырту юлын».

Тугры кол күзәтми үз мәнфәгатен,
Бәк өчен тырышу — аның гадәте.

Файда итмәс кайбер бәгырьсез угыл,
Файдалырак булыр тугрылыклы кол.

Сихәтле әремне[12] багып үстерсәм,
Агулы чәчәкне мин төптән өзәм.

Ярдәм итми торган кардәш булса, куй!
Ярдәмчел дусны тот, аңар яса туй.

Телең сөчек, йомшак, бал кебек булсын,
Йөзең булсын алчак, гөлдәй ачылсын.

Чытык йөз, ачы сүз туңдыра җанны,
Гомердә дә шуннан эретми аны.

Бу хакта тагы бер шундый шигырь бар
(Мәгънә өчен кат-кат ярый укырга):

«Кеше сине сүксә агулы телдән,
Сөягеңә кирт ул, тамга-күңелгә.

Чытык йөз, ачы сүз туңдыра җанны,
Гомердә дә шуннан эретми аны.

Тиз төзәлер яра чыбыркы ярса,
Әмма тел ярасы сызлар елларча».

… Әгәр бий атланып, алып кор җәргә[13],
Уен-аугa чыкса, илен күрергә,

Күзәтергә кирәк шундый мәлендә:
Зыян-зарәт килә көтмәгәнендә.

Биләрдә булса бер ялгышу-хата,
Тик атлы сугышта һәм ауда чакта,

Ышанычсыз кеше бар икән — читләт,
Хәтәрле хәлләрдә күзәт бик ипләп.

Бөтен сөекле һәм сөйгән кешеләр
Генә бий янында якын йөрсеннәр.

Сүв башы төзергә тиеш кор-җәргә
Сөңгеле егетләр саклык итәргә.

Кече кор, олы кор буталышмасын,
Тыштагылар эчкә өлеш кушмасын.

Сәрайда ни рәвеш утырыш-торыш,
Сәфәрдә дә шулай булырга тиеш.

…Капу башы — тугры булу үрнәге,
Шулай булу кирәк, и, җан терәгем.

Капу башың менә шундыйрак булсын —
Бий икмәген ашап эшләүче ялчың.

Менә әйтеп бирдем, илбик ишетте,
Әйткәнемнән нидер алып ишетсен.

Илбик әйтте: — Оттым сүзең, билгеле,
Тагын бер сүз булсын миңа өлгелек.

Беләсең син, шиксез, дөнья биләре
Аралаша илдән илче җибәреп.

Белекле сүзеңне син әйтеп бирче:
Ни дигән сүз инде «ялавач, илче».

Нинди булсын икән илче, әгәр дә,
Бий җибәрсә аны күрше илләргә.

[11] Гамәлдәр — «чиновник».
[12] Оригиналда узгун дигән үлән күрсәтелә.
[13] Кор җәргә — түгәрәкләп, камап алган хәрбиләр теземе.

ҮГДЕЛМЕШ ЯЛАВАЧ ИТЕП ҖИБӘРЕРЛЕК КЕШЕ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕГЕН ӘЙТӘ

Әйтте – җавап бирде Үгделмеш: – Илбик,
Бу эштә бик кирәк гыйлем вә белек.

Ирләрдән шундыйны сайларга кирәк:
Белекле булсын ул, инсафлы, зирәк.

Һәр ялавач – илче, изге бер кеше,
Тәңре колларының иң сайланмышы.

Ялавачлар төрле-төрле эш кыла,
Һәм бик шәп эшләр эшли еш кына.

Ушлы булсын илче, сүзләрнең белсен
Тышкы шәкелен һәм эчке мәгънәсен.

Таки ул шундый бер оста сүз әйтсен –
Тәмам бозылган бер хәлне төзәйтсен!

Ни ди, әнә, ишет, сәясәтче ир,
Халыкка җитәкче булган баһадир:

Халыктан сайланмыш ир булсын ушлы,
Һәр җирдә абруйлы һәм укымышлы.

Бел ки, тик шундый эш уңа ул уңса,
Каю эшкә гыйлем һәм уй салынса.

Кем үз эшен белгеч шикелле белә,
Һәм эшкә тотынса, кулыннан килә.

Белемнәрне куллан һәм аек уйла:
Күп эшләрне шунда башкарып була.

Кеше тугрылыклы, күзе тук булсын,
Бөтен, чын холыклы, күңле нык булсын.

Хуҗа мәнфәгатен чын эшче күзләр,
Аны хуҗа, ә ул хуҗасын сөяр.

Бәгенә файдалы — аңар тугры зат,
Тугры затны күрсәң, күтәр, якынлат.

Тугры хезмәтчеләр – бәгыреңә сан,
Бәгырь генә түгел, йөрәгеңә кан.

Ачкүз кеше хәтта үзен тоталмас.
Мондый заттан ничек чыксын ялавач!

Ирләрдән шундыйны сайларга кирәк:
Белекле булсын ул, инсафлы, зирәк.

Күзе тук ярлыны байга сан, диләр,
Теләгенә, чөнки, ул шиксез җитәр,

Сок ир комсыз була, явыз, нәфесле,
Менә шундый инде чын бер хәерче!

Ни ди, ишет, әнә канәгать кеше
(Шундый кеше була байларның башы):

Кемнең күргәне бар малга туйганын,
Күңел күзе, җаны ярлы булганын?

Хирыслы зат, хәтта, бай булса да кол,
Күңел бушлыгында үлеккә тиң ул.

Ничек яхшы әйткән белем бирүче –
Үгет-нәсихәтләр телен белүче:

Төкәнмәс байлыкка ирешмәк булсаң,
Күңел байлыкларын булдыр, и, инсан!

Канәгать булган кол – хуҗа ул, ләкин
Канәгатьсез хуҗа үзе колга тиң.

Хуҗа комсыз булса, чын хәерчедер,
Канәгать – күңле бай хуҗа диелер.

Оятлы, ипле һәм эшчән, күрекле,
Шулай ук һәртөрле яктан белекле.

Оят белмәгән ир мәнсез утын ул,
Кеше оят белсә, рухан бөтен ул.

Эшчән булса, «дөрес кеше» диелер,
Холыклы да булса, үзен сөйдерер.

Кешедә берләшсә гайрәт һәм белем,
Һәрбер эш андыйның кулыннан килер.

Бу бәйтне[1] укы һәм күңлеңнән ишет,
Белем алып, шуның буенча эш ит:

Ушың белән уйла, белек илә бел –
Көнең котлы булыр, котаер һәр ел. ■

[14] Бәйт – «кушык, строфа».

СОЛДАТ

Гаяз Исхакый

(роман)

VII

Лодзьга килгәннән алты-җиде ай үткәннән соң, Садыйк танымаслык дәрәҗәсенә килгән иде. Ул хәзер шактый гына русча сөйли белүдән, солдат уенына тәмам өйрәнеп җитүдән, чиннар-фәләннәрнең исемнәрен, солдатларның 344 кыланышларын тәмам ядка алудан башка эченнән дә үзгәргән иде. Ул хәзер авылдагы кыш көне азбар көри торган, җәй буе кырда эшли торган, эшләү берлә ашаудан бүтәнне белми торган, үзенең авылы берлә күрше шәһәрне генә күрә торган, өстеннән һәрвакыт тирес берлә тир исе чыга торган мужик егете түгел иде. Ул хәзер әллә ничә шәһәр күргән, әллә ничә шәһәр күргән кешеләрне күргән солдат Садыйк Әхмәдич иде. Ул хәзер үзенең авылын исенә төшергәндә, үзенең иптәш егетләрене хәтеренә китергәндә дә һәрвакыт аларга түбән күз берлә карап: «Мужик инде, мужик!» — дип кенә куя иде, ул үзенең хәзер солдатка китүенә түгел кайгыру, хәтта шатлана иде. Аңарга хәзер авылның кечкенә өйләре бу зур казармага чагыштырганда бик кечкенә, бик ямьсез булган кебек, авылдагы күбесе бәрәңгедән гыйбарәт булган аш та бик тәмсез, андагы дуплы тунлы иптәшләр дә шоп-шома юнган солдатларга караганда бик тупас кебек күренә иде. Ул хәзер карт солдат дәрәҗәсенә кергәнгә, ул һәрвакыт кесәсендә акча тота алырлык байлыгы булганга, ул хәзер начальство каршында да «Садыйк Әхмәдич — маладис!» булганга бәйрәм көннәрне бәйрәмчә үткәреп, якташ солдатларына кунакка барып, гостиницаларга керә алганга, аның тормышы хәзер бик җиңел үтә, вакыты бик күңелле уза иде. Аның хәзер тормышының тулмаган җире булса, ул да монда Гайниҗамалның булмавы, әллә нидә генә бер булса да әтиләрен-әниләрен күрә алмавы иде. Ул өеннән бик еш-еш хат алса да, ул һәр хатта авылның бөтен кодагый-әбиләр, кодача абыстайлары, ил күршеләре, мәсҗед картлары, мәхәллә имамларыннан бик сагынып, бик саргаеп, бер күрергә зар вә интизар булып сәламнәр укыса да, ул үзенең Гайниҗамалыннан да төрле каралар берлә бизәкләп бетергән, кырына борып-борып бәетләр язган ислемай сөртелгән хатлар алса да, аның күңеле алар берлә генә канәгатьләнми, аның дәрте аның берлә генә кайтмый иде. Ул күп вакытта шәһәрдән-фәләннән йөреп кайтып йокларга яткач, бик озак уйлап ята. Үзенең Гайниҗамалының ни эшләгәнен белергә тырыша, үзенең аның берлә булган бар вакыйгаларын башыннан алып очына кадәр күңеленнән кичерә, Гайниҗамалның күрешкәндә елаганнарын күз алдына китерә иде. Аңарга хәзер дә Гайниҗамал кайгыра, аның өчен Гайниҗамал еглый кебек күренә иде. Шуның артыннан Гайниҗамалның вәгъдәсене бозуы, Гайниҗамалның бүтән егет берлә йөри башлавы, Гайниҗамалның кияүгә чыгуы, Гайниҗамал берлә аерылышулары, бу киткән көнне азбарда үбешүләре актык үбешү булуы хәтеренә килә иде. Аңарга тагы Гайниҗамал еглаган кебек, Гайниҗамал моның берлә бәхилләшкән кебек күренә иде. Шул эшнең иртәгесен үк ул бик озын иттереп, тирәләренә тагы матур бәетләр язып, Гайниҗамалга яза, үзенең күкеле шикләнгәнен бәян кыла, Гайниҗамалга вәгъдәсен бозмаска җалына, җалвара иде. Озак үтми, тагы Гайниҗамалдан хат ала иде. Тагы күңеле урынына утыра иде. Тагы Гайниҗамалга үзенең аны сагынуын,

аны сөюен язарга тотына. Тагы үзе мәдрәсәдә өйрәнгән шаблон буенча «җанымның җаны, бәгыремнең каны» берлә хатны тутырып, сачәкләр ябыштырып җибәрә иде. Көндезләрен уйнау, кайвакытларда каравылга бару, еш-еш кына хат алу, сөальләргә җавап язудан башка Садыйкның башка эше юк иде. Монда кайгырырга, шатланырга эш булмаганга, ул артык кайгырмый, артык шатланмый, ашап-эчеп, юынып, итек чистартып, сирәк-сирәк шәһәргә чыгып гомерен уздыра, вакытыны үткәрә иде. Казармада төрле солдат булса да, кайсы солдатлар бик күп книгалар укысалар да, Садыйк бер дә русча укый белмәгәнгә, икенчедән, укудан ләззәт алмаганга, ул бернәрсә дә укымый, бернәрсә хакында мәгълүматын арттырмый иде. Шулай булса да аның башына хәзер авылда вакытта булмаган яңа мәгълүматлар кергәләгән иде. Ул да шундый үзенең яхшы солдатлыгын күрсәтергә җай килүен, нутренни вракны «һәң» генә иттерергә тугры килүен эченнән көтә дә иде. Ул начальство алдында тагы «маладис» булыр өчен иптәшләр арасында сөйләнергә, новобранецлар алдында мактанырга эш булсын өчен шул эшнең тизрәк булуын көтә иде. Ләкин шәһәрдә тынычлык булганга, эшчеләр арасында андый-мондый тавыш-тын булмаганга, һаман Садыйкка үзенең уены мәйданга чыгарырга җай килмәгәнгә һаман аның уе уй гына булып калып, ул һаман шундый сүзләрне сөйләгәндә тыңлаучы гына булып торырга мәҗбүр булганга, аның күңелене дә әллә нинди бер нәразыйлык хисе ашый, шул хис аңарга тынычланып йокларга ирек бирми иде. Шул фикерне аның мәйданга чыгара алмавына бер сәбәп, аныңча, тагы шул ук еврейлар, поляклар сәбәп булганга, аның аларга дошманлыгы артканнан арта бара иде. Аның күңелендә шуларның барысы өчен дә үч алу уе береккәннән берегә бара иде.

VIII

Тагы бер ел үтте. Садыйк тәмам карт солдат булып, казарманың тәмам правалы гражданы булды. Ул да башка солдатлар кебек итеген үзе чистартмый башлады. Ул да башка солдатлар кебек яңа солдатларга мужикка караган күз берлә карый башлады. Ул хәзер тәмам казарма кешесе булды. Ул хәзер чын солдат булды. Аның тышкы каты гына түгел, бөтен эче башкарды. Ул хәзер үзенә бертөрле караш ясады. «Яхшы», «начар» дигән сүз, «ярый», «ярамый», «матур», «ямьсез» дигән сүз аның кашында элгәреге мәгънәсен югалтты. Аныңча, хәзер начальство яраткан эш нинди генә булса да яхшы эш иде. Нинди генә булса да аны эшләргә ярый иде. Ул һәрнәрсәгә шул «начальство» дигән күзлек аша караганда ул һәр мәсьәләне бик җиңел хәл кыла, һичбер мәсьәлә хакында баш ваттырып уйлап та тормый иде. Шуның өчен ул үзенең яңа солдат вакытында: «Ник солдатка алалар? Солдат ник кирәк?» — дигән сөаленә дә хәзер көлеп кенә: «Начальство шулай куша», — дип җавап бирә иде. Һәм дә үзеннән яшь солдатларга да шул фикерне күңелләренә урнаштырырга тырыша иде. Ул һәр мәсьәләне хәл кылырга юлын тапканга, һичбер мәсьәлә хәзер аның сөаль булып башын ватып тора алмаганга, ул безнең мәдрәсәләрдә «Исагуҗи» укый башлап, инсанның маһияте — хәйване натыйк, ишәк(неке) — хәйване саһил, фәләннеке фәлән дип, һәрнәрсәгә җавап тапкан шәкерт кебек, үзеннән-үзе бик риза, үзенең кыйммәтене бик белә иде. Аныңча, һәр начарлыкның нигезе начальствога каршы тору, һәр яхшылыкның башы начальствоның сүзен тоту иде. Шуның өчен солдаттан качкан иптәшләренә бик яман күз берлә караган кебек, начальствоның сүзене ноктасы берлә тутырмаган солдатларга да шул күз берлә карый иде. Нинди суык көнне, нинди ямьсез җил-буранлы төнне каравылга барырга тугры килмәсен, ул һәммәсен ноктасы берлә урынына китерә иде. Ул шулкадәр һәрнәрсәгә үзенең начальство күзе берлә карарга өйрәнгән иде, әгәр аңарга үзенең иң якын иптәшен атарга начальство кушса, ул аны ләм-мим димәенчә атачак иде. Ул казармадагы кайсы солдатларның авыл хәлләрен сөйләүләрен барысын да начальствога тирес

эш дип иман китергәнгә, андый сүзләрне сөйләүче... Садыйкның начальство әмере берлә йөремәгән бер эше булса — ул да Гайниҗамалны сөюе, аның берлә хатлар язышуы иде. Ул, ничектер, бу мәсьәләне үзенең мантыйкында аерып йөрткәнгә, аның хакында бервакытта да начальствоның ул мәсьәләгә ничек караганны сорап тормаенча, ул һаман элгәреге юлында дәвам итә иде.

Менә шулай Садыйкның һәр көне сабын берлә юынып, чистарткан итек киеп, вакытында ашап-эчеп, бернәрсә хакында да уйламаенча, һичнәрсә тугрысында тирән кайгылар, тирән шатлыклар хис кылмаенча үткәргән вакытын, бу көне кичәгә, кичәсе иртәгә охшаган гомерен әллә кайдан ишетелгән: «Сугыш!» — дигән тавыш, әллә нинди иттереп тәэсир итеп бүлдерде. Аның күңелендә әллә нинди яңа хисләр уянды. Бу тавыш Садыйкның гына түгел, казарманың астыны өсткә китерде. Бөтен солдатның күз алдына үлү-үлмәү мәсьәләсе җанлы кебек килеп басты. Солдатлар аннан-моннан газета эзләргә, газета укырга ябыштылар. Әфисәрләр солдатларга сугышның ничек баруын акрын-акрын бәян кыла башладылар. Әүвәл көннәрдә әфисәрләр бу сугышмыни, өч атнага да бармас, менә Япониянең бер очыннан икенче очына чыгарлар, дип сөйләсәләр дә, бара-тора сакланып сөйли башладылар. Әүвәлге җиңелү солдатларда курку хисен уятты. Андагы солдатларның җиңелүенә түгел, үзләренә чират җитәр дип курка башладылар. Төрлесе төрле хәйләләр эзли башлады, кайсылары кача башладылар. Садыйкка бу хәбәр бик ачы тоелды. Аның да «начальство»га бинаэ кылган мантыйкы урыныннан кузгалды. Ул да бу мәсьәләгә үзенең әтиләрен-әниләрен, Гайниҗамалын бергә кушып уйлый башлады. Ул да начальствога каршы килергә аз гына да нияте булмаса да, сугышка бармый калуны бик зур бәхеткә саный башлады. Ул шуның өчен әфисәргә-фәләннәргә денщик булып керүне дә уйлый башлады. Казарманың бөтен һавасыны өмет берлә өметсезлек тутырды. Начальстводан кечкенә генә бер кешенең вакытсыз килүе солдатларның күңелендә әллә нинди фикерләр уянуга сәбәп була башлады. Хәзер казарманың эч тормышы, иптәшләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте элгәрегә караганда тәмам үзгәрде. Газеталар укый башладылар. Садыйк та, табигый, шул сугыш мәсьәләсе берлә мәшгуль иде. Ул да хәзер җиңелүнең кем ягында булуын тикшерә иде. Вакыт үтә-үтә болар шул газеталарга, шул үзара моназарәләргә дә өйрәнделәр. Ул да боларга гади бер эш булып китте. Ул да боларны борчымый башлады. Аларның күз алларында үлү-үлмәү күренеп тормый башлады, һәрнәрсә гади хөкемен алды. Безнең Садыйк та әтиләренә, Гайниҗамалга бәхилләшеп хат язганның соңында, тынычланган кебек булды. Ул да артык борчылмаенча гомер үткәрә башлады.

IX

Сугыш башланудан бер-ике ай үткәч, казарманың халкы сугышка өйрәнебрәк җиткәч, бер якшәмбе көнне Садыйк иптәшләре берлә йөрергә чыкты. Яз көне матур булганга, көн дә бәйрәм булганга, урамда йөрүченең исәбе-хисабы юк иде. Фабрикалар, заводлар, магазиннар ябык булганга, боларның приказчик, эшчеләре шул матур һавадан, шул матур көннән файдаланыр өчен, ләззәтләнер өчен, сасы, тыгыз өйләрен ташлап, иркен-киң урамнарга чыкканнар иде. Һәммәсе дә озаграк шул саф һаваны сулар өчен, озаграк шул матур кояшлы көнне күрер өчен, шул кәефле яз исен иснәр өчен акыртын гына хәрәкәтләнәләр, акыртын гына атлыйлар иде. Зур урамга чыга торган урамнардан чиләктән актарган бәрәңге кебек, төрле төстәге, төрле киемдәге кешеләр агып торганга, зур урамның йөрүчеләре күбәйгәннән күбәя бара, тротуарлар тыгызайганнан тыгызая бара, хәрәкәт акыртынланганнан акыртынлана бара иде. Монда поляклар, еврейләр, немесләр, руслар, татар солдатлары – барысы да үз теле берлә сөйләгәнгә, барысының да тавышы бергә кушылып һавага күтәрелгәнгә, шәһәр өстендә әллә нинди кытай музыкасы төсле бер тавыш гөрләп тора иде.

X

Бу тавыш үзенә бертөрле мәһабәтлелектә, үзенә бертөрле матурлыкта, үзенә бер төрле көчлелектә хис кылынганга, урамга яңа кергән кеше үзен әллә нинди зур мәсҗетдә, әллә нинди үзе аңламый торган бер зур бәйрәмдә, әллә нинди, алга таба бара торган бер корабында кебек, үзен-үзе бик кечкенә кебек күрә, үзен-үзе шул хәрәкәткә каршы килә алмаслык көчсез бернәрсә генә икәнлегенә ышана иде.

Бу мәһабәтле, бу матур адәм диңгезе, бу әллә нинди хуш исләр сача торган матур хатыннар, матур кызлар бергә зиннәтләнгән җанлы адәм бакчасы бәлки тагы шул үзенең мәһабәтен, үзенең матурлыгын югалтмаенча, үзенең шул вәкарьле хәрәкәтен бозмаенча, бик озак дәвам иткән булыр иде. Бәлки ул тагы, яңа кешеләр белән тулып, яңа матурлар белән зиннәтләнеп, бата торган кояшның сары нурларына чумар иде. Аның актык яктысы берлә саубуллашмаенча, шул урамын ташламас иде. Ләкин... кварталыннан күренгән кызыл флаг, аның артыннан килә торган кешеләр диңгезе, кешеләр диңгезенең дулкыны бу урамның да хәрәкәтен үзгәртте. Мондагы тавышка әллә нинди яңга сүзләр кушты, әллә нинди яңга тавышлар ишеттерә башлады. Бөтен урамның күзе — кызыл флагка таба, аның артыннан килә торган кешеләр диңгезенә таба юнәлде. Һәммә кеше шуның хакында сөйли башлады. Безнең Садыйкның бу флагка, бу кеше диңгезенә исе китте. Ул да шуны карарга, шуның хакында уйларга тотынды.

Менә халык туктады. Кызыл флаг, кешеләр урамны тутырдылар. Бер авыздан кебек: «Долой войну!» — сугыш бетсен, дип кычкыра башладылар. Садыйкның күршесендәге кешеләр дә кушылды. Менә тагы урамның теге ягында бер бик зур флаг күренде. Тагын: «Сугыш бетсен!» — дигән сүзләр ишетелде. Бөтен урам шул тавыш берлә тулды. Садыйкка бу тавыш, бу күренеш үзенә бертөрле тәэсир итте. Моның нәрсә галәмәте, бу тавыш ни идекен белмәгәнгә, ул аптырап калды. Бу кадәр халыкның җыелуы, «Сугыш бетсен!» дип кычкыруы аның башына сыймый, аның миендә оеша алмый башлады.

Менә флаг туктады. Әллә нинди бер яшь кенә кеше полякча сөйли башлады. Поляклар бик ихлас белән тыңлый башладылар, урамның теге тарафында бер кеше еврейчә сөйли башлады. Урамда бер тарафтан икенче тарафка хәрәкәт башланды.

Бераздан соң һәммә йир тынды, һәммә кеше тыңларга тотынды. Садыйк: «Ә-ә поляклар белән еврейлар бунт ясый икән», — дигән фикергә килде. Ләкин ул үзенең бу фикерен урнаштырып бетерә дә алмады, поляк урынына бер рус менеп русча сөйләргә тотынды. Русча: «Без сугышка каршы киләбез! Сугыш кирәкми! Сугыш кем өчен файдалы?..» — дип бик озак сөйләде. Садыйкка моның сүзе вакыйган дөрес кебек тоелды. Аның баягы «бунт» дигән фикере тагы шөбһәләнә башлады. Аның артыннан тагын поляк, тагын рус сөйләде. Шул арада атлы казаклар күренде. Урамның кырыенда кычкыру, елау башланды. Камчы тавышы, ат аягы тавышы якынлаша башлады. Флаг янындагы кешеләр хәрәкәткә килделәр. Садыйк та моның демонстрация икәнлеген, моның начальство яратмый торган эш икәнлеген аңлады. Ул тагы: «Бунт икән», — дип хөкем итте.

Менә, озак үтмәде, казаклар флаг янына килеп җиттеләр. Флагны алыр өчен, эшчеләр берлән сугыша башладылар. Эшчеләр тагы кузгалды. Флаг югалды. Һава камчы бутаулары, кизәнүләре берлән тулды. Кычкырыш, бакырыш, казакларның сүгенүләре бөтен дөньяны алды. Ул ара да булмады, әллә нинди офицерларның: «Таралыңыз!» — дигән сүзе ишетелде. Садыйк, иптәшен эзләп, артына-алдына каранса да, таба алмагач, үзе генә кайтып китте. Бик озакка кадәр аның колагына елаган тавышлар, бик озакка кадәр ат тоягы тавышлары, әллә ни кадәргә кадәр казаклар сүгенгән тавыш ишетелде.

Ул бу вакыйганы рәтләп аңламаганга, ни өчен куганнарын белеп бетерә алмаганга, мондый зур җыелышларны моңганчыга кадәр күргәне булмаганга, анда

сөйләнгән сүзләрне ишеткәне булмаганга, аның башы әллә нинди бер «иҗтимагыйнәкыйзин»га (каршылык укмашмасына) әверелгән иде. Ул, кайдан уйларга, ничек бу мәсьәләне хәл кылырга белми кайтып килгәндә, аның колагына шул тарафтан залп тавышы ишетелде. Ул үзе дә дерелдәп китте. Залптан соң тагы еглау, кычкыру, сүгенү тавышы күтәрелде. Ул: «Аталар күрәсең», — дип әйтергә өлгермәде, тагы, икенче залп, өченче, дүртенче залп ишетелде.

Ул бу залпларны, бу кыйнауларны төрлечә уйларга тотынды. Аның фикеренчә, теге русның сөйләгән сүзе, «Безгә сугыш кирәкми!» — дигәне тагы да дөрес кебек, ул рус «нутренний враг» түгел кебек тоелды.

Тагын аның күзенә кызыл флаг янындагы кешеләр, аларның сөйләүләре, шундагы хатын-кызның кычкырышлары, аларның бер кешегә дә тимәүләре, казакларның, кылыч түтәсе берлә кыйнарга тотынулары Садыйкның башында әллә нинди уйлар уяндыра башлады. Аның башында «Начальство кушмый» дигән хәзер җавап булмаса иде, ул шуның хакында уйлый-уйлый, кызыл флаг янында кешеләрнең идеяләренә бәлки җиткән булыр иде. Ләкин хәзер «формула» аның бөтен бәхәсләренә җавап бирде. Ул тагы: «Начальство кушмагач, сөйләмәсен», — диде дә, казармасына кереп китте. Ишек япканда, бер залп ишетелде.

Бу вакыйга казармада бик күп сүзләргә, бик күп бәхәсләргә, солдатлар арасында бик күп кычкырышуларга сәбәп булды. Кайбер солдатлар: «Бунт», — дип кызыл флаг күтәргән кешеләрнең барсын да «нутерный врак»ка кертәләр. Алар белән уйнамаенча, аларның арт сабакларын укытырга кирәк, диләр. Кайсылары казакларның кыйнауларын, атуларын гаепләп, кыйналган балаларның, ат таптаган хатыннарның, канга буялып яткан эшчеләрнең гөнаһсызлыкларын сөйлиләр, аларны кызганалар иде. Алар солдатларның дошманы булмаенча, дусты булуын да, аларның сугышны бетерергә теләүләрен солдатлар өчен файдалы булуын да сөйлиләр иде. Ике тарафның да, үзләренә күрә дәлилләре бар, ике тарафның да, үзләрен күрә, карашлары бар иде.

Поляк, яврәй солдатлары, русларның шәһәрдән алынганнары вә башка, укыганыраклары — барысы да кызыл флагны яклыйлар иде. Авыллардан килгән рус солдатларының күбесе, татар солдатларының барысы да аларга дошман күзе берлә карыйлар, аларны аз гына да кызганмыйлар иде.

Казармага кайткач, Садыйкның да аңлап җитмәгән нәрсәсе тәмам аңланды. Ул да хәзер үзенең иптәшләре — татар солдатлары кебек: «Аларны кыйнарга кирәк», «Аларга ирек бирмәскә кирәк» уена керде. Бу кычкырыш бик озакка кадәр барды.

Бара-тора казарма бераз тынды. Казарманың төрле тарафында җыелган солдатлар бер-берсе берлә үзләренең күргәннәрен-ишеткәннәрен акрын гына сөйләшә, үзләренең дус-ишләре белән хиссиятләрен бүлешә башладылар. Казарманың һәр тарафында, чыш-пыш итеп кенә, акрын гына тавышлар килә башлады. Ара-тирә генә, бер тарафтан: «Казак уң кулын чабып өзде...», икенче тарафтан: «Бер баланың эчәкләре чыкты...», өченче тарафтан: «Башы ярылды...» кебек сүзләр генә ишетелгәли иде. Болай сөйләшүчеләр, болай соңга калып утырышучылар — казакларны гаепләүчеләр иде.

Казакларны яклаучыларның барысы да үзләренең урыннарында, борыннары берлә төрле тавышлар чыгарып йоклыйлар, яисә йокларга хәзерләнеп яталар иде. Садыйк та озак тормады, йокыга китте.

Иртәгесен солдатлар торып тагы шул сүзләрне сөйләргә өлгерә алмадылар, казармада: «Начальство» дигән тавыш чыкты. Һәм казармага поп, офицерлар белән полковник килеп керде. Солдатлар начальствоны гадәтләренчә каршы алдылар. Начальство үзара сөйләшкәннән соң, поп солдатларга карап: «Туганнар, солдатлар», — дип сөйләргә тотынды. Ул кичәге вакыйганы сөйләде. Ул кызыл флаг күтәргән кешеләр патшага, ватанга, халыкка дошманнар, алар Япония акчасына

ялланганнар, алар — динсезләр, алар — кяферләр, алар тәмуг кисәүләре дип бик озак аларны начар күрсәтергә тырышты. Ахырдан: «Сез, солдатлар, падишаһны һәм дә мәмләкәтне сакларга тиеш, андый кешеләр берлә катнашмаска тиеш», — дип сүзен бетерде.

Аннан соң полковник: «Араңызга андый кешеләрне кертмәңез, андый кешеләр берлә дус булмаңыз. Алар белән дус булу солдатның исемен пычрата, чисен югалта», — диде. Соңыннан гына: «Андый кешеләрне күрсәңез, иптәшләреңез арасында алар берлә таныш бер солдатны белсәңез, яисә аларның язуларын укучыларны күрсәңез, начальствога әйтеңез», — диде.

Бу сүзләр кызыл флагчыларга дошман бөтен солдатның нигезен тазарткан кебек, Садыйкның да фикерен тазартты. Ул хәзер үзенең кем икәнен тәмам белде. Ул хәзер, начальство хәтере өчен, солдат исемен былчыратмас өчен, солдат чисен югалтмас өчен, кызыл флагчыларны гына түгел, алар яклы солдатларны да «нутерни врак»ка кертеп, алар белән дә начальство кушканча мөгамәләгә хәзерләнеп куйды. Начальствоның бу сүзе солдатлар арасында дошманлык төшерде, аларны тәмам икегә бүлде.

Садыйклар, аларның иптәшләре үзләрен казарманың хуҗасы хисап кылып тегеләрдән көлә, аларны мыскыл итә башладылар. Тегеләр кысылдылар: аларның иптәшләре аз иде. Алар, элгәреге кебек, күп солдат арасында сугыш тугрысында, демонстрация хакында сөйләшми башладылар. Ләкин аларның үзара дуслыклары артты. Алар үзара аерылып җыелышлар ясап, гәзитәләр, китаплар укый башладылар.

Казарманың бу тормышы тагы озакка бармады, аның тынычлыгы тагы бозылды. Урамда тагы кызыл флаг күренде. Солдатлар арасында тагы шуның хакында сүзләр башланды. Ләкин бу юлы демонстрация, бәйрәм көн булмаганга һәм дә начальстводан солдатларны чыгарырга рөхсәт булмаганга, беркемне дә чыгармадылар.

Ай йитәр алдыннан казармада тревога булды. Солдатлар бик тиз киенеп, офицерлары берлә урамга чыктылар. Офицерларның әмере белән кызу-кызу атлап эшчеләр урамына таба бара башладылар. Алар чыкканда, урамдагы халык, су кебек, эшчеләр урамына таба агыла иде. Эшчеләр урамы тарафыннан кеше тавышы, ат тавышы, еглау тавышы, тагы әллә нинди тавышлар ишетелә иде. Эшчеләр урамына якынлашкан саен халык күбәя бара, тавыш-кычкырыш ачыграк ишетелә, ат аягы тавышы, еглау тавышы куәтләнә бара.

Менә солдатлар, бер урамнан борылып, эшчеләр урамы очына чыктылар. Урамның теге очында зур кызыл флаг күренде. Ул язгы җил белән җилбер-җилбер итеп бер җыелып, бер сузылып торганга, бер кечкенә кебек, бер зур кебек күренә иде. Урамның икенче кырыенда тагын шуның кебек флаг күренә, теге яктарак аңардан кечкенәрәк тагын бер флаг. Эстинә буйларында әллә никадәр әллә нәрсәләр язылган кечкенә кызыл флаглар күренә. Шуның өстенә, халыкның бу ягында — казаклар. Аларның чабып йөрүләре, аларның кычкырышулары, аларның камчы тавышлары ишетелә. Бу халык диңгезе, бер туктамаенча, әллә нәрсә кычкыра, бер туктамаенча хәрәкәтләнеп тора иде.

Якынрак килгәч, Садыйк тагы элгәреге: «Сугыш бетсен!» — тавышларын ишетә башлады. Тагы аның күзенә, әллә нинди биек нәрсәләр өстенә басып сөйли торган кешеләр күренде. Аерым сүзләр аның колагына килеп-килеп бәрелә башлады.

Офицер кушуы белән солдатлар туктады. Офицер янына, бик кызуланып, атка атланган военный киемдәге кеше килде. Офицер белән әллә ни сөйләшкәннән соң, офицер, солдатларны икегә аерып, яртысын икенче бер офицерга биреп, яртысын үз янында калдырды. Садыйк та иптәшләре берлән әллә нинди, начар, былчырак, сасы урамга таба кереп китте.

Бу урам, мондагы йортлар шәһәрнең башка урамнарына охшамаган кебек, курка-курка гына капка артыннан баш тыгып карый торган кешеләре дә башкаларга охшамаган иде. Боларның урамнары былчырак, өйләре ямьсез булганы кебек, кешеләре дә — үзләре арык, үзләре ябык, киемнәре начар. Солдатлар якынлаша башлагач, боларның һәммәсе дә, ярканатлар кебек, капка артларына качалар, солдатлар үткәч, тагы урамга чыгалар иде.

Боларның күбесе теге урамга барырга курыккан карилар (картлар), карчыклар, ата-аналары йибәрмәгән балалар иде. Сирәк-сирәк кенә бу капкалар янында, әллә нинди кызыл чүпрәкләрен флаг ясап күтәргән балалар да күренә. Алар да, солдатларны күрү белән: «Солдат!», «Солдат», — дип кычкырып капка артларына яшеренәләр. Солдатлар киткәч, тагы чыгалар... Садыйк янындагы бер рус солдаты боларны күреп көлде. Садыйкка да бу балалар үзенең балачакларын, үзенең, зурларга охшар өчен, зурлар төсле кыланыр өчен дип агачлар ясап иген сугып уйнаулары, чабатадан арба ясап, печән ташып уйнаулары исенә төште. Ул да көлде. Уң яктан иптәше, боларга ачуланып: «Алар бар да бер этләр! Нинди флаг күтәргән була?! Мин кирәкләрен бирер идем! Алар уйнап йөрсеннәр, без монда ач, каравыллыйк!» — диде.

Бу сүз Садыйкта да ашыйсы килү фикерен уятты. Ул: «Хәзер казармада аш өлгергәндер. Казарманың бөтен почмагында, борынга орып керә торган щи исе чыккандыр», — дип уйлый башлалды. Аның авызына сулар килде. Ул үзенең ашыйсы килүен тагы чынлабрак белде. Шуның өстенә тагы теге солдат: «Менә хәзер ашап йибәрсәң икән, ә! Менә бу сволочьлар аркасында, кичкә кадәр ач тор!» — диде.

Ул ара да булмады, алар тагы элгәрегедән дә былчырак урамга борылдылар. Тагы җыелган халык күренә башлады. Офицер командовать итте: солдатлар, мылтыкларын кулларына алып, алга таба бара башладылар. Шулай итеп эшчеләргә барып терәлделәр.

Садыйк тугрысында эшләпә кигән ике марҗа белән бер егет тугры килде. Марҗаның берсе әйләнеп карады да, иптәшенә нидер әйтте. Икесе дә солдатларга карап көлешергә тотындылар. Бу көлү Садыйкның бөтен тамырларына тәэсир итте. Ул аларның үзләрен солдатлардан югары күреп көлүләреннән, боларның — кызыл флагчыларның — үз хезмәтләрен эшкә санамауларыннан хурланды. Эченнән: «Тукта әле, өйрәтермен...» — дип уйлап куйды. Аның күңелендә әллә нинди бер ачу кабарды. Аның шул тау кебек өелгән, кычкыра торган, сөйли торган кешеләрне, шул «начальствоның дошманнарын» изәсе, бетерәсе килде. Менә шул арада урамның теге ягыннан солдатлар халыкны куа башладылар. Халык бу якка таба кысыла башлады. Теге марҗалар да монда таба атламакчы булдылар. Садыйк, күзендә ачу берлә: «Нельзя!» — дип кычкырды.

Тагы кысу куәтләнде. Кешеләр арасында тагы кычкырыш купты. Теге яктан, халыкка бик кычкыра торган бер офицер атының башы күренде. Шуның артыннан: «Таралыгыз!» — дигән тавышы ишетелде. Боларның артыннан тагы казаклар күренде, тагы камчылар худка китте. Тагы еглаган, кычкырган-бакырган тавыш күккә күтәрелде.

Урам арчылды. Солдатлар, штыкларын алга каратып, халыкны куа киттеләр. Озак үтмәде, төрле яктан кысыла-кысыла, казаклар тарафыннан кыйнала-кыйнала халык төрлесе төрле якка таралып бетте. Садыйклар бик озак урамда торганнан соң, ашыйсылары килеп эт булып беткәннән соң, казармага кайттылар.

Аш ашап бетерергә дә өлгермәделәр, аларны тагы урамда патруль йөрергә алып чыгып киттеләр. Алар тагын иртә белән барган урамнарга бардылар. Тагы анда-монда аз-аз гына җыелган кешеләрне куа башладылар. Каршы килгәннәрне тотып тенти башладылар. Озак иттереп урамның бер очыннан икенче очына кадәр йөрделәр.

Әллә никадәр кешене тентеделәр. Әллә никадәр кешене кудылар. Тентетмәскә теләгәннәрен политсага җибәрделәр.

Менә бер йорт тугрысыннан узып барганда, йорт эченнән тавышлар ишетелә башлады. Солдатлар туктадылар. Башлыклары капкадан барып карагач, боларга капкадан керергә кушты. Болар бик кызуланып керә башладылар.

Болар кергәндә, былчырак йортның уртасында 40-50 кеше җыелып, араларыннан берсенең сөйләвен күрделәр. Башлыклары тегеләргә: «Кузгалмагыз!» — дип кычкырды. Эшчеләр төрле якка чабыша башладылар. Солдатлар таратмаска тырыша башладылар. Бер минутта, бөтен йорт әле анда, әле монда чабучылар берлән тулды. Алар артыннан солдатлар куарга тотындылар. Башлыклары: «Йибәрмәңез!» — дип әмер бирде.

Садыйк та бик тырышып куарга тотынды. Кечкенә генә бер эшчене мылтык түтәсе белән сугып екты. Ул арада, булмады, койма янындагы ташларга басып, койма аша сикерергә тели торган зур сакаллы бер эшчегә күзе төште. Садыйк бөтен тавышы белән кычкыра башлады. Эшче, гүя моның тавышын ишетмәгән кебек, һаман, мәче кебек, тырмашып менүендә дәвам итте. Садыйк коймадан сикерергә хәзерләнгән минутында гына барып җитте. Мылтыкның түтәсе берлә сугып кына, эшчене качудан алып кала алмаганын белеп, штыкны ходка җибәрде: бар куәте белән эшченең эченә штыкны тыкты. Эшче «һәк» диярргә дә өлгермәде, канга буялып егылып төште.

Аның йөзе әллә нинди бик куркыныч төс алды. Аның һәр әгъзасы дер-дер калтырый башлады. Яткан урыны канга буялды. Авызы чалышайды. Аның һәр әгъзасы, битенең һәр хәрәкәте, әллә нинди әйтеп бетерә алмаслык газап чиккәнен күрсәтә башлады. Ул бик ямьсез иттереп күзен тутырып Садыйкка карады. Гүя бу күз каравы берлә үзенең Садыйкны әллә никадәр сүккәнлеге, аны чиксез кабахәт дип уйлаганын белдермәкче булды. Ул бик авыр иттереп ыңгырашуга тотынды.

Садыйкның күзенә тагы койма аша сикерүче бер яшь егет күренде. Ул бик кызуланып аңарга таба юнәлде, аны да бу карт кебек итмәкче булды. Штыгын сузарга өлгерә алмады, егет теге якка сикереп төште. Садыйк тагы анда йөгерде, монда йөгерде, кайсысын тотты, кайсысын сугып екты.

Озак үтмәде, барысын да җыеп бетереп, солдатлар берлә чолгап алып, политсага илтәргә саный башладылар. Йорт тынычланды. Койма буендагы теге картның ыңгырашуы гына ишетелә башлады.

Санап бетергәннән соңында, Садыйк унтер офицерга теге картны күрсәтте. Унтер офицер: «Әй, карт шайтан!», — дип кычкырды. Карттан ыңгырашудан башка тавыш чыкмагач, унтер солдатларга барып алырга кушты. Солдатлар, барып, әллә ниләр сөйләнделәр, кулларын бутадылар да, килеп: «Ул сөйли алмый. Ул үлә», — диделәр. Унтер: «Үлмәгәе! Бетсен!» — диде дә чыгарга командовать итте.

Теге карт эшченең ыңгырашуы Садыйкта тагы солдатлык хисен уяндырды. Ул — үзен-үзе бик зур егетлек кылган солдат итеп хис кыла башлады. Үзен-үзе шул янындагы иптәш солдатларыннан — кеше буе, кул сузымы биек, алардан әллә ни кадәр, әллә ни дәрәҗә мәмләкәт өчен файдалы, дип уйлый башлады. Шуның өчен янындагы поляк солдатының Садыйкка бик ямьсез иттереп караган күзеннән дә бер дә курыкмаенча, теге эшченең ыңгырашуын ишетә-ишетә, күкрәген киереп капкадан чыкты. Ул үзенең «каһарманлык хисен» йөрәгенә тутырып алга таба атлый башлады.

Дәвамы бар

Текстны басмага
***Мәсгуд Гайнетдин** әзерләде.* ■

ЯЗМЫШ ЙӨРТӘ КЕШЕНЕ

Тәлгат Галиуллин

Диләрә Нәүрузова коллажы

«Мөһаҗир» сүзе һәм төшенчәсе шәхес культы фаш ителеп, шактый сулар акканнан соң, үткән гасырның алтмышынчы еллары ахырында, күренекле язучыбыз **Мәхмүт Галәү** наменнән кара тамга алынып, аның «Мөһаҗирләр» дип аталган тарихи романы дөнья күргәч кенә әйләнешкә керә башлады. Әдип үзе исән чакта туган телендә бастырып чыгара алмаган «Болганчык еллар» һәм югарыда аталган әсәрендә 1897 елда халык исәбен алу, төгәл мәгълүматы булмаган авыл кешеләренең бу кампанияне чираттагы чукындыру, руслаштыру галәмәте дип бунт күтәрүләре, табигый ки, әзерлексез башланган фетнәнең канлы рәвештә бастырылуы һәм шунда катнашкан күп гаиләләрнең авыллары белән тугандаш вә диндәш Төркиягә күчеп китәргә карар кылып, юлда һәм аларны беркем көтмәгән яңа урында ачлыктан, төрле чирләрдән күпләп кырылуы ачыктан-ачык һәм сәнгатьчә югарылыкта тасвирлана. Әдипнең «җиңел кулы» белән кертеп җибәрелгән атама туксанынчы елларда туган илен, газиз кавемен төрле сәбәпләр белән, төрле чорларда ташлап китәргә мәҗбүр ителеп, читят җирләрдә гомер сөргән кешеләр язмышының уртак билгеләмәсенә әверелә.

Ирек җилләре исеп, тарих битләре ачыла башлагач, мөһаҗирлек хәрәкәтенең күченеп йөрүгә, «һава алыштыруга» маһир татар халкы арасында бик күптәннән яшәгәнлеге, хаҗга, ислам диненең үзәкләре Мәдинә белән Мәккәгә белем эстәүгә барулар, сәүдә, хәрби матавыклар белән чит илләргә чыгып йөрүләр турында сәяхәтнамәләр, юлъязмаларның күптәннән туа килүләре мәгълүм була. Бу истәлекләрне әдәби әсәрләрдә, фәнни язмаларда өйрәнә башлыйлар. **Галимҗан Ибраһимов** «Диңгездә» хикәясенә шул риваятьләрнең берсен нигез итеп ала. Ватаннарына кайтып баручы хаҗиләр утырган корабны корбан сораучы балык туктата. Әҗәле җиткән кешене бирмәсәләр, барысы да һәлак булачак икән. Хаҗиләр шобага салалар. Язмыш шул хакта сөйләүче Нурый Фәррашның әтисе Гаптулла хаҗине сайлап ала. Һушын югалткан бәхетсезне кәфенлиләр дә, суга ташлыйлар, башкалар исән кала. «Корбан сораучы балык» (1976) исемле ярым популяр, ярым фәнни мәкаләсендә **Мөһәммәт Мәһдиев** болай дип яза: «Диңгез һәм андагы куркыныч балык турындагы мифлар ни өчен татар әдәбиятына, халык иҗатына тирән үтеп кергәннәр? Бу хәл Галимҗан Ибраһимовның хикәясендә генә булса, әллә ни иркенләп сөйләшеп торуның кирәге дә булмас иде. Ләкин шул ук күренеш белән без **Габдулла Тукайда** да, **Дәрдмәндтә** дә очрашабыз», — дип, язучы Тукайның «Милләтчеләр», Дәрдмәнднең «Кораб» шигырьләренә тирән анализ ясый.

Татар җәмгыятендә, шул исәптән поэзиядә, мөһаҗирләргә игътибар үсү бөек язучыбыз, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның исеме һәм мирасы акланып, туган иленә кайтуы белән бәйле. Мөһаҗир образы, мөһаҗир язмышы диюгә, күз алдына, беренче чиратта, чит илләрдә яшәүче татарларны туплау юнәлешендәге милләтпәрвәрлеге белән бу хәрәкәттә яңа бер чор ачкан Г.Исхакый күз алдына килеп баса.

Бөек мөһаҗиребез образының шигърияттә яктыртылуына алдарак әйләнеп кайтырбыз әле, бу очракта милләттәшләребезнең, булсын ат өстендә, булсын җәяү, көймәдә, куркыныч көчләрнең саклап торуына карамастан, элек-электән ил чикләрен үтеп йөрүләре кызыксындыра. Читкә чыгып китәргә мөмкинлеге булган татарны юл йөрү газаплары, билгесезлек туктатып кала алмаган. Ә инде илдә 1917 ел матавыклары, 1918-1920 елларда илдәшләр арасында кабынып киткән сугыш, Икенче Бөтендөнья

орышы чит-ят мәмләкәтләрдә калучылар санын бермә-бер арттырган. Мөһаҗирлек хәрәкәте дә сәяси юнәлеш алган.

Журналист **Тәлгат Насыйров** мондый нәтиҗәгә килә: «1917 елгы октябрь түнтәрелешеннән кузгалган күчеш чорында меңнәрчә татар Русиядән Төркиягә юнәлә… 1970 елларда бу илдә 25 меңләп татар яши». Бу санга Финляндия, Австралия, Америка, Кытай, Япония һ.б. илләргә күчеп киткән татарларны өстәсәк, шактый ук саллы күрсәткеч килеп чыгар иде.

Гаяз Исхакыйның чит илләрдә яшәгәндә иҗат иткән әсәрләрен өйрәнү барышында профессор **Хатыйп Миңнегулов** татар мөһаҗирләренең саны турында да фикере белән урталаша: «Аклар», «Әсирләр» (икенче Бөтендөнья сугышы тоткыннары — Т.Г.) составында чит мәмләкәтләргә эләккән милләттәшләребезнең саны берничә дистә меңгә якын», — ди галим. Әлбәттә, бу саннар да мотлак дөреслеккә, төгәллеккә дәгъва кыла алмыйлар. Чөнки татар мөһаҗирләренең санын алу, исем-фамилияләрен, һөнәрләрен язып калдыру белән бер оешма да, аерым галим яисә сәясәтче дә шөгыльләнмәгән, дөнья совет шымчылары белән шыплап тутырылган чорда бу тыелган темага алынырга берәү дә җөрьәт итмәгән.

Чит илләрдә элек-электән туплана килгән маялары, «череп беткән» байлары булмагач, татар мөһаҗирләрен бер җирдә дә, хәтта тугандаш Төркиядә дә, «кадерлем, хуш киләсең, рәхим итеп түрдән уз, сый-нигъмәтебездән авыз ит», дип, колач җәеп, каршы алулар булмаган.

Мөһаҗирлек — татар кавеме уйлап тапкан хәрәкәт түгел.

Матбугатта күренеп алган хәбәрләргә караганда, 1917 елгы октябрь инкыйлабыннан соң 5 млн рус телле кеше чит илгә чыгып китә. Украин, яһүди, әрмән качакларының чит илдәге язмышлары турында сүз алып барганда, бер мөһим үзенчәлекаерманы искә алу кирәктер. Хикмәт шунда: татар мөһаҗирләре томанлы билгесезлеккә, бары тик үзләренә ышанып чыгып китсәләр, телгә алынган халыкларның, бигрәк тә рус телле мәдәният әһелләренең Аурупаның Париж, Берлин, Лондон кебек шәһәрләрендә барып сыеныр, таяныр диаспорасы, меценатлары, хәтта банклары, үз зиратлары була. Хөкүмәткә үпкәләдеме, Думаның берәр карары белән килешмәдеме, эче поштымы, рус зыялысының илдән чыгып китү мөмкинлеге элек-электән булган. Әйтик, XIX гасырның күренекле каләм иясе **Иван Тургенев** тәүге мәхәббәт ләззәтен вә михнәтен тасвирлаган «Первая любовь», «Ася» һ.б. бәяннарын, **Александр Герцен** Русиядә тормышны ничек, ни рәвешле җайлап җибәрүгә киңәшләрдән торган «Былое и думы» дигән фәлсәфи-публицистик романын илдәшләренә Парижның Елисей кырларыннан иңдереп яткан. Бөек пролетар язучысы исеменә лаек булачак **Максим Горький** 1929 елга тикле, үзен Сталин, тиешле шартлар тудырып, ялынып диярлек чакырып алганчы, Италиянең «оҗмах» утравы Каприда «интегеп» ята. Рус телле башка (әйтик, **Иван Бунин, Евгений Мережковский, Зинаида Гиппиус** һ.б.) язучылар да, илдә калып, совет хөкүмәтенә мәдхия җырлап тамак туйдырган язучылардан кайтышрак яшәмәделәр, дип уйлыйм.

Чит илләрдә элек-электән туплана килгән маялары, «череп беткән» байлары булмагач, татар мөһаҗирләрен бер җирдә дә, хәтта тугандаш Төркиядә дә, «кадерлем, хуш киләсең, рәхим итеп түрдән уз, сый-нигъмәтебездән авыз ит», дип, колач җәеп, каршы алулар булмаган.

Төркия, Франция, Алмания һ.б.

мәмләкәт хөкүмәтләренә эшкә ялланып, өлешчә исем-фамилияләрен үзгәрткән, мәгәр мәсләкләренә тугрылыклы калган укымышлы татар мөһаҗирләре гаҗәеп зур уңышларга ирешәләр. Җөмләдән, **Йосыф Акчура** (1876-1935) — «Төрк йорды» журналының баш мөхәррире. Төркиянең Бөек милли мәҗлес депутаты, Кәмал Ататөрекнең киңәшчесе, Истамбул университеты профессоры, 1931 елдан вафатына тикле Төрек тарих җәмгыяте рәисе вазифаларын башкара. Русия думасы депутаты чорында ук Тукай теленә эләккән **Садри Максуди** (1878-1957) — әүвәл Парижда Ислам институты профессоры, Төркиягә күчкәч, шул ук вазифаны Истамбул дарелфөнүнендә башкара, ә инде 1930-1938 елларда Бөек милли мәҗлес депутаты була.

Татар кешесенең күндәм, тырыш, кара эштән дә куркып тормыйча (урман кисүгә җибәрелеп тә, соңрак төрле өлкәләрдә сәләтләре ачылган фин татарларын искә төшерик), төрле милләтләр белән уртак тел таба алуы холык-гадәтләребез, әхлакый тәрбиябез белән аңлатыла. **Әхмәт Рәшит** «Мөһаҗирләр» шигырендә «татар табышмагының» чишелешен, җавабын эзли. *«Сибелә чәчәк» җырын көйли-көйли, Сибелгәнбез ерак-еракка»*, *«Мөһаҗирлек мәллә канга сеңгән»* кебек юллар халкыбызның күченеп йөрүгә һәвәслегенә, күңелендә моңын, җырын онытмавына ишарә ясаса, *«Ризык мәллә шулай йөретә»* гыйбарәсе аңардан гына тормаган, югарыдан иңгән мәҗбүрияткә киная булса, бу уйланулар укучыны шигырьнең мәгънәви вә кичереш йөген кабул итүгә әзерлиләр: алгы нәүбәткә туган өммәтнең балалары белән горурлану хисе чыга. Татар токымы баласы язмыш аны кайсы төбәккә ташламасын, солтан булмаса да, олтан дәрәҗәсенә төшми. Әлбәттә, бер йодрык кебек үз туган җирләрендә яшисе урынга халык улларының төрле кыйтгаларга, Русиянең төрле төбәкләренә сибелүе милли фаҗига иде. «Афәтле билгесезлек» шигырендә **Зөлфәт** сорауны бик төгәл куя:

Бөекләре читтә калган
Халык бөек яшәрме?

Харрас Әюп «Хәтер» шигырендә язмыштан узмыш юк, илдә калганнар киткәннәрне кире какмыйча, авыр сүзләр әйтмичә, күңел түрләрендә сакларга, берсен дә онытмаска тиешләр, дигән фикер уздыра.

Яшерелмәс вакыт пәрдәләре,
Киткәннәр дә кире кайтырлар —
Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Югалмасын бары хәтерләр!
(Харрас Әюп. «Хәтер»)

«Хәтер» адәм балаларын табигый инстинкт белән яшәүче башка җан ияләреннән аерып торучы бөек байлык, буыннар арасына күпер сызып торучы Ходай бүләге, ди шагыйрь.

Халык тормышының көзгесе — әдәбиятта килү-китү, кайту-кайтмау мәүзугы әледән-әле күтәрелә килгән үзәк, тормышчан һәм фәлсәфи мотивларның берсе буларак яши, бәгырьләрне өздереп, үстерелә. Мөһаҗирләрне генә күздә тотмаса да, шагыйрь **Мөхәммәт Мирза** мондый язмышка тарыган кешеләрнең рухи бәргәләнүен шактый төгәл ачып бирә:

Килү-китү арасында
Бертуктаусыз юл икән.
Гомер итү чарасызлык —
Урап үтү юк икән.
(Мөхәммәт Мирза.
«Бер күк астында яшәп тә...»)

Рәдиф Гаташның «Мөһаҗир», **Зиннур Мансуровның** «Мөһаҗирләр» шигырьләре — туып-үскән газиз җир белән аерылу сагышының фәлсәфи-этик, милли-мәдәни нигезләрен ачуга, мөһаҗирлек күренешен киңрәк колачларга омтылышлары белән үзенчәлекле әсәрләр.

Әхмәт Гадел «Ил урылды. Идел-Урал ауды...» шигырен Садри Максуди Арсалга» (1978-1957) багышлый; **Лена Шагыйрьҗан** *«Очып китте тагын Җирдән бу Татарның бер*

баласы», дип, бөек биючебез белән хушлаша («Рудольф Нуриев белән хушлашу»). Аерым шәхесләрнең тормышына, яшәешенә, дөньяга карашына багышланган тезмәләрендә дә шагыйрьләрне тулаем халкыбызның бүгенгесе, аның киләчәге борчый.

Еш кына «китү» янәшәсендә «кайту» сүзе килә, бу төшенчәләр елганың ике яры кебек, бер-берсенә антитеза буларак яши. Чынлыкта бу мәүзугъны 1913 елда иҗат ителгән «Мөхәрриргә» шигырендә Гаяз Исхакыйга «Кайт әле монда Ватанга, кайт әле, саргайтмәле!» дип, Тукай әйләнешкә кертеп җибәрде. Шагыйрь ул елларда Архангел губернасының Мезен шәһәрендә сөргендәге каләмдәшенә, фикер иясенә тизрәк туган иленә кайтуын сорап мөрәҗәгать итә. Алдагы юлларда шагыйрь мөхәррирне иленә чакыруының сәбәбен дә ачып сала: синнән башка татар җәмгыяте *«алты ел торды чупансыз»* (җитәкчесез, көтүчесез)... *Синең «пакь вә чын сүзеңнән», «Күз карашыңнан керер җир тапмас» иде гамьсез, надан әрсезләр, монафикъләр,* ди шагыйрь, үрсәләнеп.

Мөһаҗирләрнең зур дәрәҗәгә ирешкәннәре өстәмә итеп төрек фамилияләрен алсалар, Исхакый кушаматны, тәхәллүсне нигездә саф татар сүзләреннән ясый: Казанлы, Ураллы, Тимер, Хәбибрахман әл-Болгари, Котлы Мөхәммәт, аеруча Иделле дигән ачыкламышны еш куллана. Үзенең чит ил кешесе икәнен ачкан бердәнбер төрек сүзен — Япанчыны (иностранец) куйгалый. Туган җирендә яшәгәндә дә, мөһаҗирлек чорында да яшәеш кредосы шул ук кала.

Туган халкына каршы алып барылган геноцидны фаш итү, милләтне уяулыкка чакыру, генофондын саклап калу, «Идел-Урал» штаты рәвешендә булса да, татарның дәүләтчелеген торгызу (ул — реалист, теләкне мөмкинлектән чыгып кына калкытып куя) — аның мәңгелек хыялы.

Татар язучылары, бигрәк тә шагыйрьләре Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеген, көрәшен, милләтпәрвәрлеген тулырак һәм тирәнрәк яктырту хыялы белән иҗат итәләр. Шигъри багышлауларның күләме буенча (камиллек дәрәҗәсенә әлегә кагылмыйм. Сан сыйфатка күчә диләр) ул Тукайдан гына калыша, дип, уйлыйм. Күчеш, эзләнү чоры өчен **Рашат Низаминың** «Ике мөһаҗир», **Әмир Мәхмүдовның** «Пәйгамбәр» сәяси поэмалары үзенчәлекле үр булды.

Исхакый бөеклеген аңлау һәм шәрехләү юнәлешендә беренче сәяси-фәлсәфи уйланулар **Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Зөлфәт, Әхсән Баян, Равил Рахмани, Айдар Хәлим, Эльмира Шәрифуллина, Факил Сафин** каләмнәреннән төшсә, аларга соңрак **Лена Шагыйрьҗан, Флёра Тарханова, Фәйрүзә Мөслимова, Җәүдәт Сөләйман, Газинур Морат, Мөхәммәт Мирза,** яшьрәк буын шагыйрьләр тавышы да килеп кушылды. Казан дәүләт университетының яшь шагыйрьләре Исхакыйның 130 еллыгына багышлап студентлар гәзите чыгарды. Барча багышламаларны уртак мотив берләштерә. Ул — Исхакый кабызган милли ялкынны, кешегә, туган телгә хөрмәтне киләчәк буынга илтеп җиткерү, даһи язучының иҗаты, эшчәнлеге белән горурлану, аның мөстәкыйльлек, инкыйраздан котылу турындагы өйрәтү-хыялларын бүгенге көн проблемалары белән бердәмлектә карау — хәтер терәге, яшьләр иҗатында буыннарны бәйләп торучы җанлы җеп буларак калка. Милләт бәхете өчен көрәшүчеләрнең катлаулы язмышы, чарасызлык хисе сагыш чыганагы булып тора, лирик уйлануларның нигезен тәшкил итә. Поэзиябез бөек көрәшчебез тормышын гади бәян итүдән читләшеп, халкыбызны инкыйраздан саклап калу өчен Исхакый идеалларын замана мәнфәгатьләреннән килеп бәяләү юлына чыга бара. ■

АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Габдулла Тукай

● Бармак берлән каткан җирне казып булмый, әлифбасыз (алфавитсыз) язып булмый; шуның төслек, мәктәпләрне төзәтмичә, «Тәрәккый!» — дип кычкырырга базып булмый.

● Без культура дөньясының әлифбачысы гына әле. Айлар, еллар үтәр, әлифбадан үтеп, югары күтәрелербез.

● Балаларымызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә ияләшсен.

● Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф[8] булып, анчак гүзәл вә мөкатдәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр. Моның киресенчә: кечкенәдән тупас вә ямьсез нәрсәләр күреп үскән балаларның язгы ачык күк кеби саф күңелләре томанланып, рухлары яхшыны вә начарны аермый, һәрнәрсәгә бертигез караучы буладыр.

● Ишетмәгән сүз вә күрелмәгән нәрсә һәрберсе гыйлем.

● Белми хикмәтсез кеше хикмәт дигән сүз кадрене.

● Гыйлем җәүһәрен чүплек башыннан эзләргә мәҗбүр итәләр... Чүп булгач чүп инде. Ул таралып ятса да, тәртипкә салынса да — барыбер чүптер.

● Һәрнәрсәнең гүзәлен яратабыз бит... Әфьюн башлар уйлап чыгарган ямьсез исемнәр дә татар балаларына кушылмасын.

● Без ... халкыны караңгыда калдырып адаштырырга кулымызда аз гына бер икътидар[9], тәнемездә җан бар вакытта аслан[10] разый булмаячакбыз.

● Кап-кара кол белми хөррият дигән сүз кадрене.

● Ислах дәрьясында йөзсен безнең кораб.

● Мәгариф мәйданында без, татарлар, ат уйнатыйк!

***

● Сез — чын яшь егетләр; өмет бар сездә, сез — интеллигентлар... Черек милләт өчен сынмас терәк сез; тугыз корбан суеп алган теләк сез.

● Терелер өчен корбан кирәк.

● Йөрмәсен бәгыре өзек милләт киеп кашсыз йөзек — без аның бик зур фәхерле[11], чын бриллиант кашлары!

● Беләсезме, бу дөнья нинди дөнья? Бу дөнья — һәр ике дөньяда бәхетнең башы.

● Нәрсәдә ләззәт икән?.. Кайда тәм?.. Тик фәкать милләткә хезмәткә

Дәвамы. Башы журналның 9 нчы санында.

мәхәббәт... Бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!

● Әйдә, халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә; бу юлда һәртөрле хурлыкка, зорлыкларга[12] түзмәккә!

● Милләтнең тәрәккыйсенә вә башка милләтләрнең аяклары астында тапталмавына кирәкле нәрсәнең һәммәсе дә саваплы вә хәерле бер эштер.

● Хуҗа Насретдин шикелле, атның артына карап атланмыйк.

● Зыялыларымызга һәрничек, җәсарәтле[13] пожарныйлар кеби, җәһаләт[14] ялкыны эчендә дөрләп янган милләтне, тизрәк утка атылып, коткарырга тырышу фарыздыр. Пожарны читтән тамаша кыйлып кына көлеп тормак — ирлек түгелдер.

● Бу заманда гафилләргә[15] дөнья тардыр.

● Бу тормыш кем белән туктар талаштан? Сугыш син һич тә армас-талмастан. Синең төсле берәү ул: бергәбер сез, көрәшкәнне җиңә алмый ул каберсез.

● Ничаклы изсә дөнья, ирке бар — куркытмыйдыр безне; елар җирдә көләм мин, һич чытып тормыйм аңар йөзне.

● Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен, ... кирәк түгел мәгънәсе юк көлке уен.

● Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел, һич кайгысыз кеше булса — адәм түгел!

● Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан, вә юлны тапмый калмый һәр адашкан.

● Берәүнең уйларын икенче берәү бикләп куя алмас; теләгендә нык торучыны беркем өметсез итә алмас.

● Тәңребезнең безгә кушуы: «Өметсезләнмәгез!»

● Сәгадәт талына менсәң — үзең мен; ни ярдәм килсә дә килсен үзеңдин.

● Ир кеше теләкләрен күңелендә яшереп тотмас; үзен бер генә урынга агач кебек беркетеп куймас.

● Теләрсәң кемне сүк син яки макта, берәү берлән дә булма иттифакъта.

● Саклан, күңелеңдә урын бирмә таләптән башкага; хаклык теләүче үз максатыннан бүтәнгә күз салмас.

● Кызыкма һичвакыт шөһрәткә син; бик төренмә иртәгә үк артык булыр чүпрәккә син. Тапмасам шөһрәт, сизә алмаслар, димә, күңелемдәген, зур тәрәзә бар дип аңла дөньяга күкрәктә син.

● Кача күр, кош кеби, мактауларыннан, хәбәрдар бул ки шунда ау барыннан.

● Угърашып[16] торма җиһанда иң түбән мәхлук белән!.. Сипмә конфетти... сәфилләр[17] өстенә: ул хәзерләнгән атарга йөзгә каршы чүп белән.

● Бул кеше: байбәтчәләрнең калдыгы хәмерен көтеп, алты еллык образованиеңне йөрмә селкетеп!

● Бар җегетләр: бик тәкәбберләрчә тоткан позасын, чөнки дөнья бакчасының күргән ул тик розасын.

● Татар шәкертен кеше ясар өчен, иң элек, аның «вәкар»ен бозарга кирәк. Бу — өй салганда иң элек нигездән башлау, сүткәндә түбәдән тотыну кебек кагыйдә инде. Андый «вәкарь» яшьлектә җимерелмәсә, ...неграмотный үләчәк «зате галиләрдә»[18] дә кала. Мисал эзләсәңез, күктән йолдыз эзләгән кеби генә булып, аны табуда зәхмәт чикмәссез.

● Измәсен яшьләрне дә күптән яше үткән кеше.

● Безнең ашын ашаган, яшен яшәгән картларымызны, корыган агачтан дуга ясарга мөмкин булмаган кеби, тугъры юлга күндерү мөшкилдер.

● Безне артка тарткан картлар мазарстан[19] таба атлар.

● Тәфсилләмәсәң, татар аңламый.

***

● Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе: «Ah!» — дисең, без ник болай соң? Без дә Хакның бәндәсе.

● Түбәннәр югары ашкан, бөекләр түбән төшкән.

● Өй түрендә бар иде гаять тә зур баскыч... Югаргы басма мәгърур: «Мин югары, сез түбәнсез, — ди, ни-

чек гали минем урыным, түбәнгеләр, күрәмсез?» — ди. Бер адәм килде дә шул чакта әйләндерде баскычны: түбәнге басмалар менде, югаргысы түбән төште.

● Күрмәгез бер яклы дип сез бу вафасыз дөньяны; ул ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн игы.

● Әйтсәгез, сездән сорыйм мин: бездә нәрсә юк иде?!

● Вакытында җирне селкеттек, инде беттек, инде беттек!

● Без — ишек төбендәге агачлар.

● Бу дөнья бер төркем вәхшиләргә рәхәт урын булды: болар, белмим, ни сәбәптән безнең өскә ябырылдылар. Болар яхшы кешеләрнең канын эчә, чөнки кан эчү аларга шикәрдән һәм дә хәлвәдән татлырак.

● Читен хәл. Гайрәтең җитсә — ерып чык, әгәр җитмәс исә — бет, шунда тончык!

● Шаярыр идек — әле генә язмыш ханым кыйнаган; җылар идек — әле күздән яшемез дә кипкән.

● Нигә тарихтан гыйбрәт алмыйсыз?

● Әгәр сез тоткан юлыгызда нык торса идегез, бу хәлгә төшүегез, минемчә, мөмкин булмас иде.

● Халык... хөрриятнең җаннар корбан итәрлек дәрәҗәдә мөкатдәс нәрсә икәнен аңлап җитмәгән. Аңласа да, бик азы аңлаган.

● Искеләр белми һәнүз милләт дигән сүз кадрене.

● Дөньяда һәрнәрсә дә үз асылына бер әйләнә.

● Сез үзеңезнең хәлеңезне төзәтергә теләсәңез, хәзер сезгә тырыша торган вакыт тәмам җитте.

● Дустны, дошманны дөрест фәрекъ итмичә[20], күп саташтырдык... шайтанны чын инсан белән. Аңгы-миңге баш белән дә эшләдек — булсын кабул... Үтте инде, дустларым, ул үткән эш, ни булса ул; инде эшлик саф, ачык күзләр белән.

● Белмисеңме син: читен мәхбүслек ул. Булса да алтын, һаман да читлек ул.

● Мәңгегә оча алмас, йортта күп асралса кош.

● Читлек ачтым, андагы кошчыкны коткардым, ...аңар бирдем азатлык мин, үземдә шулвакыт күрдем: тынычланып калды... һәм тәмам иркенләде күңелем.

● Изге эштер тартышмаклык хокук өчен... Тартыш, зинһар, тартыш, тартыш!

● Ачыл, азатлык бакчасы! Сандугачларың сайрасын — милләтнең киләчәге айлы кичтән дә яктырак булсын.

***

● Синең бар дөньяда күргән газабың, гөман юктыр, бозык булганга җаның.

● Иң начары: җан картайган, һәр нәрсәгә «барыбер» дип карый башлаган.

● Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без, кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.

● Әхлак, вөҗдан, инсафларны сөреп чыгардык истән дә; бозылдык шулкадәр начар, уздырдык без иблистән дә.

● Мәлганәт[21], пычрак вә ялган берлә тулган безнең эч; бар начарлыктан, бозыклыктан гыйбрәт безнең эш.

● Көнчелек, үчлек белән тулган татарлык, төяп илтеп Мәкәрҗәдә сатарлык.

Сүзлекчә

[8] Назик вә ләтыйф — нечкә һәм гүзәл;
[9] Икътидар — сәләт, көч-куәт;
[10] Аслан — һич тә;
[11] Фәхерле — мактанычлы;
[12] Зорлык — авырлык;
[13] Җәсарәт — батырлык, кыюлык;
[14] Җәһаләт — наданлык;
[15] Гафил — ваемсыз;
[16] Угърашу — бәйләнешү;
[17] Сәфил — түбән, вөҗдансыз бәндә;
[18] Зате гали — бөек зат;
[19] Мазарстан — каберлек, зират;
[20] Фәрекъ итмичә — аермыйча;
[21] Мәлганәт — түбәнлек, явызлык.

Текстны басмага
Зиннур Мансуров *әзерләде.*

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

«УКЛАР», Уральскида 1906 елның 15 июненнән ноябренә кадәр (барлыгы — 6 сан) К.Мотыйгый наширлегендә һәм мөхәррирлегендә басылган демократик юнәлештәге (татар телендә беренче) «айлык, рәсемле, сатирик журнал». Аны чыгару тулаем Тукай җилкәсенә төшә (чөнки К.Мотыйгый «Әлгасрелҗәдид» журналы, «Фикер» газетасы, русча «Уралец» газеталарын да нәшер итә, аның вакыты чикле). «Фикер»нең 3 июнь санындагы игъланда журналда язмаларның «Шүрәле», «Сөемсез», «Ишан мөнкире»,» Каилелхак» кебек яшерен имзалар белән басылачагы хәбәр ителә. Болардан «Шүрәле», «Сөемсез», «Ишан мөнкире» Тукай имзалары булуы күптәннән расланган. «Каилелхак»ның («Дөресен сөйләүче») кемнеке икәнлеге ачык түгел (кайберәүләр К.Мотыйгыйга нисбәтли). Журналның башлангыч чорында хәбәрчеләр һәм басарга яраклы материаллар аз булу сәбәпле, Тукай барлык бүлекләрне үзе язып тутыра, бер генә кеше язган икән, дигән фикер калмасын өчен, төрле псевдоним куллана (яисә имзасыз гына урнаштыра). «Уклар»да аның «Шүрәле» имзасы белән 8 шигыре, 15 сатирик мәкаләсе, «Тәртә башы» белән 6, «Җен» белән 3, «Кырмыска» псевдонимы белән 2 мәкаләсе басылган, «Дугры», «Хәйләсез», «Кәфәштатыюш», «Чапансыз», «Чурт», «Хәсрәт», «Һөд-һөд», «Мәхүб прахуды кантурщигы», «Сөңге», «Адвокат», «Догачы», «Мылтык», «Уклар»ның лөгать мөтәфтише» кебек имзалар астында — берәр текст. Тәнкыйть үтемлерәк булсын дип, Тукай карикатур рәсем өчен темаларны да үзе тәкъдим итә, рәсем астындагы текстларны рус һәм татар телләрендә дә яза. Рәсемнәрнең күпчелеген Уральскида яшәгән рус үзешчән рәссамы һәм скульпторы Н.Г.Калентьев ясаган. Тукайның демократик юнәлештәге «Уклар»да басылган сатирик парчалары татар тормышындагы кимчелекләрдән, надан муллаларның әхлаксызлыгыннан, байларның комсызлыгы, бозыклыгыннан көлүгә багышланган. Аның иң еш тәнкыйтьләгән

кешесе, гәрчә бу чорда ул аны күреп белмәсә дә, ул — Казанның «Бәянелхак» газетасы нашире, мөхәррир, зур сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшев. Т.га бу газетаның тоткан юлы, Ә.Сәйдәшевнең традицион кыйммәтләрне генә яклавы, яңалыклы күренешләргә каршы чыгуы, шәхси мәнфәгатьләрне алга чыгаруы ошамаган. Журнал бик тиз арада популярлык казана («Чүкеч» журналын чыгаручылар көнләшкәннәр дә кебек). Т.ның журналда басылып торган текстләрында татар милләтенең артта калуы сәбәпләрен уйлап җаны әрнүе чагылыш таба, һаман ваемсыз рәвештә иске гореф-гадәтләргә ябышып ятуы тәнкыйть ителә. Надан, бозык, тәрбия җитмәгән динчеләрдән, түбән дәрәҗәдә генә фикер йөрткән байлардан, илгә җәелгән фахишәлек күренешләреннән, иске мәгариф системасыннан ачы көлә. Яңача яшәргә өндәгән идеяләр белән сугарылган журналның гомере генә кыска булып чыга. «Уклар» журналы үзенең 1 нче санында бирелгән «Сүз башы»нда ук үз юнәлешен белдергән була. Татарларга «Хөр Русиянең свободный гражданы булмак кирәк», — дигән җөмләдә журналның юнәлеше дә, андагы чәнечкеле — көлкеле язмаларның гади бер шаяру гына булмавы да ачык күренеп тора. Демократик строй турында уйланган, ул вакытларда социалистик идеяләрне якын күргән Т. журналның 1906 елгы ноябрь (6 нчы) санында «Шүрәле» имзасы белән «Шартлар» исемле мәкаләсен бастыра. Тексттагы «Бу тормышка кальбән разый булган кеше мөселман да түгел, мөэмин дә түгел, инсан да түгел, диясем килә...» дигән сүзләр хакимияткә ошамый. Нәкъ менә шушы мәкаләдән соң «Уклар»ның нашире Камил Мотыйгыйга зур штраф салына һәм губернатор әмере белән журнал басылудан туктатыла. «Уклар»да эшләгәндә тупланган тәҗрибәсе аңа 1907 елның октяберендә Казанга килгәч, «Яшен», «Ялт-йолт» журналларында эшләгәндә, үткен, әче телле сатирик булып җитешергә ярдәм итә.

«Уклар» журналының тышлыгы

Заһир Шәйхелисламов,
филология фәннәре кандидаты

Әдәбият

Яхин Ф.З. Татарская литература в периодической печати Уральска (1905-1907). — Казань: Татар. кн.изд-во, 1992. — 126 с.; Гыймадиев Ү.Сатира коралы белән. — Казан:Татар. кит. нәшр, 1977. — Б.35-71; Гимадиев У.И. Сила сатирического слова. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. — 270 с.

Карл Фукс үзенең истәлекләрендә хатын-кызларыбыз турында «Татар хатын-кызларының башта килгәнен ишетәсең, аннары гына үзләрен күрәсең», – дип язган. Әйе, безнең әби-бабайларыбыз зәркәнчелек эшенә бик оста булган, шуңа күрә бизәнү әйберләре гасырлар буенча кешеләрне сокландыра, горурлык хисләре уята.

МИЛЛИ МУЗЕЙ ХӘЗИНӘЛӘРЕ

Милли музей фондында да ***чулпылар, хәситәләр, алкалар,*** осталык белән эшләнгән ***йөзекләр, Коръән савытлары*** саклана.

Татарларда зәркәнчелек эше Казан ханлыгында, XIX гасыр-XX йөз башында чәчәк ата. Элеккеге дәвердә хатын-кыз бизәнү әйберләре гадирәк, катлаулы техника кулланылмыйча эшләнгән булса, Казан ханлыгы чорында исә осталар төрледән-төрле формалар кулланып ясаганнар, кыйммәтле ташлар белән бизәгәннәр. Татар осталары зәркән техникасының бөтен нечкәлекләрен дә белгән. Идел буенда Казан шәһәре үреп бизәкләү сәнгате үсеш алган бердәнбер шәһәр саналган. Әлеге алымның өч төрен еш очратырга мөмкин: ***турткеле, яссы һәм югары рельефлы.*** Бизәкләү алымының әлеге төрләрен кулланып, осталар төрле ***беләзекләр, каптырмалар*** һәм ***җиз тәңкәләр*** ясаган.

Шулай ук, ***коеп эшләү*** һәм ***гравировка*** кебек төрләр дә таралыш тапкан. Кою алымын бизәнү әйберләре өчен асылмалар әзерләү, борынгы тәңкәләрне имитацияләүдә киң кулланганнар. Чоку алымын кулланып беләзекләр һәм җиз тәңкәләр эшләнгән. Әлеге алымның гадәти мотивы булып үсемлек һәм геометрик бизәкләр, гарәп графикасында башкарылган язулар тәшкил иткән. Эшләнмәләрне ***гравировкалау*** белән беррәттән ***киртләү, бизәк кыстыру*** һәм ***каралту*** белән бизәгәннәр.

Аеруча сәләтле осталар ***челтәрләү*** алымына ия булган. Татар зәркәнчеләре аның өч төрен кулланган: ***яссы, ябыштырылган һәм калкытып челтәрләү.*** Соңгы алым — Казан зәркәнчеләренең иң зур казанышы. Челтәрләүдән ул орнаментының бөтеркә бизәге яссылык өстендә урнашу һәм тәбәнәк конус рәвешендәге тимерчыбыкның тараеп тәмамлануы белән аерылып тора. Челтәрләүнең бу төре өчен югары сыйфатлы көмеш һәм алтын нечкә тимерчыбыклар кулланылган. Калкытып челтәрләү алымы ярдәмендә күкрәк һәм баш бизәнү әйберләре өчен кыйммәтле җиз тәңкәләр, камзол каптырмалары эшләгәннәр.

Бизәнү әйберләрен эшләү өчен ***көмеш*** һәм ***алтын*** файдаланганнар. Бизәү өчен ***топаз, аметист, фирәзә, сердолик, аквамарин*** кебек кыйммәтле һәм ярымкыйммәтле ташлар кулланганнар.

Сезнең игътибарыгызга муен-күкрәк әйберләре арасында иң матуры — ***яка чылбырлары*** тәкъдим ителә. Музей фондларында ике төрле яка чылбыры саклана: берсе

**Яка чылбырлары.
XIX гасыр-XX йөз башы**

— каптырмадан гына тора, икенчесе — бердән алып тугызга кадәр чылбыр һәм каптырмалардан гыйбарәт. Чылбырларны санына карап хәтта аларның яшьләрен дә чамаларга булган. Яшь кызларда чылбырлар саны азрак, бердән алып өчкә кадәр, ә инде ханымнар биш, хәттә тугыз чылбырлы яка чылбырлары да таккан.

Татар халкының зәркәнчелек эшләнмәләрен күрәсегез килсә, Милли музейга рәхим итегез!

***Руфия Мөхетдинова** әзерләде.* ■

Әдәбият

Гасырлар мирасы. ТР Дәүләт музее җыелмаларыннан. — Казан: «Заман» нәшрияты, 2000.

КЫШТЫМ АФӘТЕ

Александр Филиппов

Без ул вакытта әле, ябык утарга куып кертелгән сарык көтүе кебек, бер мәгълүматсыз һәм үз хокукларыбызны да белми торган, кушканны үтәүче мәхлуклар идек…

Безне, көзге хәрби чакыруда Татарстан районнарыннан җыеп алынган егетләрне, Казанда команда җыелып беткәнчегә кадәр республика хәрби комиссариаты казармасы нарларында бер атна буе аунатканнан соң, хохол сержантлары кулына тапшырып, идәненә салам түшәлгән салкын мал вагоннарына кертеп тутырдылар. Ул елларда совет солдатларына шундый «кадер һәм хөрмәт» күрсәтеп йөртәләр иде. Безгә, авыл егетләренә, мондый романтика кызык кына әле. Вагон уртасында зур тимер мичтә — буржуйкада — ташкүмер яна. Аның янында чиратлашып кизү торасың. Тимер мичкә якынрак булган урыннарда яхшы ук кайнар булса да, җылылык вагонның баш-башларына кадәр үк барып җитми иде. Шуңа күрә булачак солдатлар, туплауга җыелган сарыклар кебек, тимер мичкә якынрак елыша. Ничек әле аска җәйгән саламга ут капмагандыр, Ходай рәхмәте!

Вагондагыларның күбесе армия хезмәтеннән бер-ике елга кичектерелеп торган егетләр иде. Мин дә шундыйлар исәбеннән. Башта болай да ике ел кичектерелгән укуымны тәмамларга мөмкинлек бирделәр, рәхмәт инде, ә икенче елны комиссия тикшерүе үткәндә корсакта бүсер табып, операция өстәленә яткырдылар. Бу кышкы чатнама суыкларда урман кисеп, ат урынына җигелеп, көчәнә-көчәнә чана белән утын ташудан килеп чыккан галәмәт иде. Шулай итеп, тагын бер елга армия хезмәтеннән азат ителдем. Икенче елны күзләремнең ерактагы әйберне начар күрүе турында әйткән идем дә, сез хезмәт итәсе часть өчен ярый, диделәр. Инде менә юлда, терлек вагоннарында барабыз. Вагонның юка такталарына тыштан салкын, эчтән җылы бәрелеп, «түшәмнән» эре-эре су тамчылары шыбырдап коела. Юлда үткән көннәр дә хезмәт срогына керә, диләр безне алып китеп баручы сержантлар. Ә кая алып барулары турында ләм-мим бер сүз дә әйтмиләр үзләре. Уралга иңәнлеген яшермиләр анысы.

Безең интернационал (бәйнәлмиләл) отделениене, хәрби төзелештә ирешкән уңышларыбыз өчен «Коммунистик хезмәт бригадасы» исеме бирелгәч, полкның Мактау тактасына кую өчен фотога төшереп алганнар иде. Рәсемдә (сулдан-уңга): рядовойлар Гайнуллин (отделение командиры вазифасын башкаручы, татар), Мадатов (үзбәк), Жилин (рус), Түләгәнов (үзбәк), Александр Филиппов (керәшен татары), Екаев, Туйчиев (үзбәкләр), Закиров, Мөхлисуллин, Зарипов (татарлар). 1960 ел

Без соңыннан гына сизендек. Бер ел алданрак армиягә алынган булсак, без Уралның кайнап чыккан вакытына туры киләсе булганбыз икән. Без хәтта шуңа да чиксез куандык...

Бер тәүлеклек юлны ун көн узганнан соң, безне 1958 ел азагында — декабрь ае үзенең соңгы көннәрен санаган чатнама суыкта — Свердловск тимер юл станциясе тирәсендәге бер тупикта тагын бер тәүлектән артык тоттылар. Өйдән алып чыккан биштәрләр инде күптән бушатылып, сохариларны кайнар суда җебетеп, калай савытларга тутырылган консерв итен күши башлаган идек. Шуннан соң гына Чиләбе өлкәсендәге Касли районының әкияти гүзәл кышкы чыршы-нарат урманына кичке эңгер-меңгер җиткәндәрәк китереп бушаттылар. Ул көнне күк йөзе аяз иде. Йолдызлар да нәкъ бездәге кебек җемелди. Җидегән, безнең якта әйтелгәнчә, Чүмеч йолдызлыгын эзләп таптым. Нишләптер, аның сабы икенче якка борылган кебек тоелды. Без бу вакытта кыйблабызны югалткан адәмнәр идек шул.

Ул арада хохол сержантлары безне рәтләргә тезеп, «рас-тва»га бастырып, багана башларында утлар җемелдәгән якка алып китте. Бу без урнашачак полк утлары икән. Полк дигәнем — ике рәткә тезеп салынган берәр катлы озын бараклардан гыйбарәт бер урам. Безне, Татарстан егетләрен, тынлы оркестр капка төбендә Сәйдәш маршын уйнап каршылады. Мондый хәлне әле беренче күрү булгангамы, безгә бу бик сәер тоелды, гүя полк олы кунаклар кабул итә. Як-ягына автоматлы часовойлар баскан олы капкадан узуга, безне казармалар артында урнашкан, озын кара торбасыннан әчкелтем кара төтен таратып утыручы казармага охшаган бинага борып алып киттеләр. Без әле сарык көтүе кебек, кая һәм нигә алып барганнарын һаман да белмибез. Иллешәр кешене бер залга үткәреп, чишенергә боердылар. Һәркемгә бер капчык биреп, өйдән киеп килгән киемнәребезне шуңа тутырырга куштылар. Теләгән кеше шул аламаларны өенә посылка итеп җибәрә ала икән. Андыйлар табылмады, берәү дә капчыкка адресын

язмады. Безгә шул залдагы бер стендка зур хәрефләр белән язып куелган яңа адресыбызны кычкырып укыдылар: «Чиләбе-40, Касли шәһәре-2...» Бу вакытта инде «Маяк»ның «тәмуг» чүлмәгеннән «җен» чыгып ычкынганга да бер елдан артык вакыт узган була... Мондый адрес шуннан соң барлыкка килгән. Ләкин бу саннар безгә әле ул вакытта берни дә сөйләми иде. Бездән алдагылар да, без дә шул кире беткән «җен»не чүлмәккә яңадан куып кертергә һәм кешеләрне ул тирәдән ераккарак күчерергә тиеш булганбыз...

Озакка сузылган талчыктыргыч юлдан соң мунчада юыну яшьләргә яңа көч өстәгәндәй булды. Ак халатына кызыл хач төшерелгән бер санитар егет өскә шлангтан көчле басым астында әллә нинди ят исле су

Бу вакытта инде «Маяк»ның «тәмуг» чүлмәгеннән «җен» чыгып ычкынганга да бер елдан артык вакыт узган була...

сиптергәч, киенү бүлмәсенә узасың. Монда үз үлчәмең буенча солдат киемнәре бирәләр. Гимнастёрка, чалбар, эчке күлмәк-ыштан, кызыл йолдызлы соры бүрек, бушлат, сары тимер прәшкәле бил каешы. Әлбәттә инде, иң мөһиме, — аяк чолгавы һәм кирза итек. Соңгысының үз үлчәмең булуы бик мөһим. Бер ягы кара, икенче ягы гимнастёрка төсендәге яшел погон. Аларга беркетергә — якорь һәм понтон күпер уртасына бульдозер төшерелгән сапер эмблемасы. Гимнастёрка якасына тегәргә ак манжет, энә һәм җеп... Мин боларны нигә санадым соң әле? Башка хәрби частьлардан аермалы буларак, өч ел хезмәт итү чорында без боларның барысы өчен дә акча түләргә тиеш булачакбыз икән. Ягъни безгә аларны әҗәткә генә биреп торалар. Без стройбат солдатлары булачак һәм безгә эшләгән өчен хезмәт хакы түләячәкләр икән. Бу киемнәрне безгә эшләп аласы акча хисабына аванс тәртибендә генә биреп торалар икән. Хуш...

Өр-яңа, энәдән-җептән генә чыккан солдат киемнәрен тиз-тиз киенгәннән соң, безне тышка чыгарып тезделәр дә, урамның аргы башындагы баракка алып киттеләр. Ашханә икән. Агач борыслардан «Х» хәрефе кебек аркылы сугылган аяклар өстенә идән такталары кадакланган өстәл тирәли егермеләп солдат утырасың да, тиз-тиз генә алюмин тәлинкәләргә салынган ашны сугып куясың, икенчегә — ботка, нәрсәдән әзерләнгәнен белүчеләр бар икән, кирза, диделәр. Шулай итеп, аякта «кирза» итек, корсакта «кирза» ботка. Алюмин чәйнектән алюмин кружкаларга чәй агызып эчәсең дә өстәл яныннан торырга команда көтәсең. «Встать! Выходи строиться! Живо!» дип кычкыра шул ук хохол сержант ачы тавыш белән. Соңрак тагын шуны белдек: солдат кухнясында пешерелгән бөтен ризыклар өчен дә акча без эшләп аласы хезмәт хакыннан тотып калынырга тиеш икән...

Татарстаннан килгән егетләрне полк буйлап төрле баракларга таратып чыктылар. Шулай итеп, без бер вагондагылар төрлебез төрле казарма-роталарга сибелдек. Башка вагондагылар дивизиянең бүтән полкларына таратылды. Бер барак — бер рота. Ротада — дүрт взвод, взводта — дүрт отделение, отделениедә унике солдат. Башка төрле бүленеш юк. Хуҗалык ротасыннан тыш, башка казармаларда без килгәнче беркем дә юк иде. Полкта безне иң беренче җылы мунча, ипи-тоз белән каршылаучылар шулар булды. Авылдан киткәндә безгә карт солдатларның — «дед»ларның яшьләрне — «салага»ларны төрлечә кыерсытулары, шуңа күрә якташларның берләшебрәк йөрергә кирәклеге турында әйтеп җибәргәннәр иде. Ә монда казармаларда җилләр уйный. Барыбыз да беришләр. Урамда да, казарма эчендә дә тәртип. Урамдагы,



барак тирәләрендәге карлар пөхтәләп көрәлгән, казарма җылы, идәне ялт итеп юылган. Казарма хуҗалары менә-менә кайтып керерләр төсле. Икешәр катлы караватларга мамык матрацлар куеп чыгылган. Калган урын-җир кирәк-яракларын баракның бер бүлмәсендә урнашкан каптёркадан кул куеп аласы. Тәмәке тартучыларга махорканы, тартмаучыларга шикәрне дә каптинармус өләшә...

Соңрак белдек: монда яшәгән солдатларны безне алып килгән вагоннарга төяп, Себер ягына алып киткәннәр икән. Тагын шуны да белдек: бу урын-җирләрдән файдаланган өчен дә акчаны без шулай ук үз кесәбездән чыгарып бирәчәкбез икән.

Бер атна дигәндә дивизия дә, полк та, безнең рота да формалашып бетте. Казармада ник бер русча авыз ачып сөйләшкән кеше булсын. Бер башта татарча җыр яңгырый, алар күршесендә үзбәкләр, казахлар, кыргыз һәм таҗиклар һәркайсы үз төркеменә берләшеп, үз телендә сиптерә, грузин, әрмән һәм әзәриләр дә шактый күренә, Балтыйк буе республикалары вәкилләре дә үзләренчә көязләнеп,

Без, кулга корал тотып, полк байрагын үбеп, беркайчан да, бернинди очракта да хәрби серне ачмаска ант бирдек.

вәкарь генә йөренәләр. Урыслар да бар. Гүя яшьләр бу икешәр йөз солдат сыйдырышлы баракларга халыкара симпозиумга җыелган, диярсең. Отделение саен бер-ике рус егетен куеп чыктылар. Бездә дә берәү бар. Үзебезнеке. Бөгелмәдән. Тыйнак. Безнең отделениегә ул үзе сорап язылды. Ротада күбебез авылдан, шәһәрнекеләр бармак белән генә санарлык. Алары да кайсы рәссам, кайсы музыкант, кайсы медик булып, «Ж» литеры белән билгеләнгән хуҗалык ротасына күчеп бетте. Урта Азия ягыннан килүчеләрнең дә кайберләре кухня ягына таба каерды, аларны пылау пешерергә оста, диделәр. Имеш, солдат көн саен «кирза» боткасы түгел, ә гел итле, дөгедән әзерләнгән пылау гына ашап торырга тиеш. Аннары тракторчы, бульдозерчы, кранчы, гомумән техника белән эш йөртүчеләрне аерым ротага сайлап алдылар. Бездә

күбрәк гуманитарийлар һәм авылдан килгән һөнәрсезләр җыелып калды. Офицерлар барысы да руслар. Взвод командирларының ярдәмчеләре урынын хохол сержантлары алып бетергән. Ике айга якын карантинда алар безгә хәрби устав ятлатты, белми торсаң, чираттан тыш наряд биреп идән юдыра, кухняда бәрәңге әрчетә, кар көрәтә... Бер солдат «гаебе» өчен бөтен взводың белән күтәреп, өч-дүрт чакрым йөгертеп кайтара. Шуны хәрби әзерлек үтү дип атыйлар. Менә шундыйрак тәртип. Сугыштан күкрәк тутырып орден-медаль тагып кайткан фронтовикларны тыңлап үскән малайларга мондый армия хезмәтен үз күзләрең белән күрү аңга бик үк ятышып бетми иде, әлбәттә. «Ә мин кайткач нәрсә сөйләрмен?» дигән уй күңелне гел кытыклап тора иде. Ике айга якын вакыт шулай узды. Без әле монда нәрсә эшләячәгебезне һаман да белми идек. Сапёр формасы кигәч, кулга чын мина тотып, аны җыеп, сүтеп карарбыз, понтон күперләр төзербез, сугыш техникасын өйрәнербез, дип уйлаган идек. Алай булмады. Солдат исемен йөрткәч, кулга автомат, винтовка тоттырырлар, дип уйлаган идек. Алай да булмады. Тантаналы шартларда хәрби ант биргән көнне генә утлы коралны ике-өч минут чамасы символик рәвештә тотып карадык. Без, кулга корал тотып, полк байрагын үбеп, беркайчан да, бернинди очракта да хәрби серне ачмаска ант бирдек. Бу истә калырлык вакыйга булды. Бу көнне безне үзбәк егетләре әзерләгән пылау белән сыйладылар. Бөтен полкны тезеп, безне дивизиядәнме, Урал хәрби округыннанмы килгән бер полковник котлады. Советлар Союзы Герое иде. Фамилиясен Сабиров, татар, сезнең якташыгыз, диделәр. Без, әлбәттә, бик тә горурландык, бер башка үсеп киткәндәй булдык. Мин аны яңадан күрмәдем. Бу кеше, соңыннан ачыклавымча, Киров өлкәсенең Нократ Аланы районындагы Түбән Шөн авылында туып үскән Фәйзерахман Әхмәтҗан улы Сабиров иде.

Шуның белән безнең солдат хезмәте тәмамланды. Без яшел погонлы эшчеләргә әйләндек тә куйдык. Взвод командиры уртача буйлы өлкән лейтенант иде. Дүрт отделениедән торган взводны казарма ишеге төбеннән яңа шәһәрдә без төзергә тиешле объектка кадәр «Взвод, шагом марш! Сул аяктан!.. Рас-тва-три... Артка калма!.. Аягыңны төзәт!.. Сул аяктан, сул аяктан!» дип кычкырынгалап алып барды. Бу яңа төзелеп килүче, бер-берсенә ике су тамчысыдай охшаган күп катлы йортларның берсе иде.

Безне төзелеш мәйданында башнялы кран янында гражданский киемле кешеләр каршылады. Яңа көч килде, дип шатланыштылар. Аларның берсе — эш кушып йөрүче прораб, икенчесе — штукатур-буяучылар бригадиры икән. Безнең отделениене шулар карамагына тапшырдылар. Взводта тагы бетончы-балта осталары, сантехниклар отделениеләре бар иде. Взвод командиры, солдатларын төзүчеләр кулына тапшырып бетергәч, каядыр полк ягына китеп югалды. Сержант та, бераз кычкырынгалап йөргәннән соң, бытовка вагонына кереп качты. Безне кадровый эшчеләрнең ярдәмчеләре итеп беркеттеләр. Алар нәрсә кушса, без шуны үтәргә тиеш. Измә килде, аны бушаттык. Аны өске катларга носилкалар белән ташыдык. Штукатурчылар измәне ялмап кына алалар, без килгәнче алар аны үзләре ташыган икән. Без эш башыннан түләүлерекордлы-премияле ысул белән эшли торган коллективка туры килгәнбез икән. Измә килгәч, бер минут туктап ял итәргә дә вакыт юк. Куалар. Измә ташучы машина калын такталардан кадаклап җыелган зур әрҗә бушаганны карап кына тора диярсең, ажгырып килеп тә җитә, тиз генә бушатып та китә. Утырып махорка чорнарга да вакыт калмый. Килгән измәне озак яткырып булмый, катып китә. Ташыйсың инде...

Ялга туктарга уйласаң, штукатурчылар командирга әләкләү белән куркыталар. Әйтәләр дә. Андый очракларда сержант төшке ашка кайтканда полкка кадәр арттан өрә-өрә куа, йөгертә, туктатып бер урында атлата, маршка бастыра, полк капкасына җиткәндәрәк җырларга боера. Аңа, күрәсең, шуңа карап бәя бирәләрдер. Сержантларга ел саен өйләренә кайтып килергә ял каралган. Ул арада аның урынын куштан ефрейтор биләп тора. Ул инде тегесеннән дә арттырып җибәрергә мөмкин. Ни гаҗәп, минем белән хезмәт итүче рядовой солдатларның берсе дә өч ел хезмәт итү дәверендә бер тапкыр да ялга җибәрелмәде. Тагын да нык гаҗәпләндергәне, безнең өйгә язган хатларыбызны укып, тикшереп торганнар икән. Дәүләт сере ачылудан курыкканнардыр, бахырлар. Безне ташчы, штукатур-буяучы һөнәренә шулай өйрәттеләр. Бу чын мәгънәсендә төрмә тибындагы «хәрби коммунизм» иде. Безнең буын анысын да татып карады.

Безгә кадәргеләр монда шактый йорт төзеп киткән. Урман уртасында бөтен коммуникацияләре белән яңа шәһәр төзелә башлаган. Әзер йортларда инде кешеләр тора. Ләкин без аларны күрмибез. Без төзелешкә килеп җиткәндә автобуслар аларны эшкә алып киткән була, ә сменадан кайтучылар ял итә. Күренсәләр дә, алар синең белән аралашмый, сөйләшсә дә, ачылып китми. Бу кешеләр шикелле, без төзи торган шәһәрнең дә исеме юк иде. Кечкенә Касли шәһәренең иярчене буларак, аны Касли-2 дип йөртәләр. Шәһәр элек-электән бизәкле чуен рәшәткәләр җитештерү белән дан тоткан. Табигатьнең иң гүзәл җиренә урнашкан ул. Олы Касли күле буена утырганлыктан, шулай дип атаганнар аны. Аннан көньяккарак киткәч, җәйрәп ятучы Иртәш күле үзе генә дә ни тора! Анысы миңа тагын да якынрак булып тоелды. Аңардан минем тәмле сулы Зичә инешемә аваздаш Тичә елгасы агып чыга. Аның да исеменең килеп чыгышы (з→д→т күчеше) безнең елганыкы кебек «төлке» дигән сүзгә туры килми микән әле? Тичә бассейнында да бездәге кебек татар авыллары йолдызлыгы урын алган. Берберсеннән шактый ерак урнашкан бу ике төбәкнең тагын бер охшашлыгы бар. Касли, Кыштым тирәләреннән башланган елгалар, кояш нурлары кебек, җир өстеннән төрле якка тарала. Беришләре көнчыгышка таба юл алса, икенчеләре көнбатышка таба юл салган, көньякка һәм төньякка таба агучылары да бар. Татарстан картасын карасаң, андагы елгалар да шулай бер биек сырттан башланып, төрле тарафларның җирен сугара. Димәк, елга-чишмәләр үз юлларын биек сырттан башлыйлар да бөтен дөньяга яшәү көче таратып, иңкүлекләргә җыелалар. Шулай булырга тиеш…

...Менә шунда, бераз гына тамак чылатып утырганда, җирле егетләрнең телләре ачылып киткәли. Бу юлы да шулай булды...

Хәрби коммунизм шартларында яшәгәндә дә, юк дигәндә, бер чишелеп киткән көннәр була. Измә заводында нәрсәдер җимерелгән, бүген төзелеш мәйданын, эш урыннарын җыештыру белән генә чикләнербез, диделәр. Без инде бригадага тупланган җирле халык белән бер дәрәҗәдә эшли башлап, әшнәләшеп тә өлгергән идек. Бригадада шул яктагы татар авылларыннан йөреп эшләүчеләр дә шактый. Солдатлар, «колхозга» берләшеп, шул егетләрнең берәрсен гастрономга җибәреп кайтара. Ул, үзеннән дә кушып, кабымлыклар да алып килә. Моны, әлбәттә, командирлар белергә тиеш түгел. Менә шунда, бераз гына тамак чылатып утырганда, җирле егетләрнең телләре ачылып киткәли. Бу юлы да шулай булды…

Ахыры киләсе санда ■

АКТАШ УПКЫНЫ

Күлне уратып алган тимер киртә

ТАБИГЫЙ МИРАС

Акташ упкыны — Әлмәт районы Кәләй авылы янында карст процессы нәтиҗәсендә хасил булган күл. 1939 елның 7 августында механизатор тракторы белән күл булачак урынга убыла. Бу елда упкынның тирәнлеге 52 м, ә диаметры 4-5 м чамасы була. Соңгы мәгълүматлар буенча упкынның диаметры 35 метр, тирәнлеге 28 метр. Акташ упкыны — 1978 елдан ТРның табигать истәлеге.

Ленар Гобәйдуллин фотолары.

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АТТИЛА (вафаты 454 елда) — 434 елдан һуннар патшасы. 443, 447-448 елларда Көнчыгыш Рим империясенә, 451 елда Галлиягә, 452 елда Төньяк Италиягә һөҗүм итә. Аттила заманында һун кабиләләре берләшмәсе иң зур куәтенә ирешкән. Аның яраткан хатыны Керкә исемле, бер улы Эллак, икенчесе Динцик исемле булган. М.З.Зәкиев Эллак исемен Ил+лек (иле бар) мәгънәсендәге төрки сүз дип карый. Аның фаразынча, Динцикны «диңгез чык» рәвешендә таркатырга мөмкин, ә Керкә исемен ул «кәрәкә» дигән балык исеме белән бәйләргә тырыша. Әлбәттә, болар фараз итү, этимологик тәҗрибәләр генә. Тарихчы Әзһәр Мөхәммәдиев Аттиланың (ул «Атилла» дип яза, Р.Әхмәтьянов сүзлегендә дә, М.Глуховның рус телендәге «Казанский ретро-лексикон»ында да шулай, ә «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә төп исем — Аттила һәм җәя эчендә Атилла варианты да бирелгән) исемен «Әтилле — «җиде климатның хакиме» мәгънәсен бирә булса кирәк», дигән фикер әйтә. Кайбер русча чыганакларда да Атилла язылышы кабул ителгән булуын әйтергә кирәк (мәс., «Казаки» китабы, Санкт-Петербург, 1999). Тел белгече Г.Ф.Саттаров татарларда очрый торган Атилла исемен Иделле исеменең борынгы варианты (Атилле) дип аңлата. Бу мәсьәләдә тел белгече М.Зәкиевнең фикерен кабатлап әйтү урынлы булыр: «Борынгы грек язмаларында сакланган бу исем һәрчак ике «т» белән язылган, шуңа күрә аның Идел (Атил) белән бәйләнеше булуы шикле». Р.Әхмәтьянов та бу фараз турында: «Аны исбат итү мөмкин түгел», – дип яза. *//Иртәгесен Рәшид Лаеш, Яшәр Байтак, Атила Кунтуз килеп, мине Истанбулның Азия ягына алып киттеләр. Илдус Садыйков (2005).* Бу мисалдан күренгәнчә, хәзерге Төркиядә әлеге исем Атила формасын алган икән. *Шәүкәт дәверләренең мәркәзләрендә торган Угыз (Модэ), Әтил (Атилла) кеби һун кааннарына, Төмин, Муган, Шийгуй һәм Шийби кеби шәркый вә гарби төрек кааннарына вә аларның дәверләренә озаграк туктарга кирәк иде. Г.Шәрәф. («Төрки-татар тарихы» исемле рецензиясеннән.)*

Аттила христиан дине тоткан, дигән фикер бар.

454 елның язында, үзенең яңа никах туеннан соң, борыныннан кан китеп, вафат булган.

Көнбатышта Аттиланы «Алла камчысы» дип атаганнар.

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә. Автор искәрткәнчә, «...бу сүзлекнең чирек өлеше 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан 1000 данәлек тираж белән бастырып чыгарылган иде».

Аттиланың вафатыннан соң һуннар мәмләкәте бик тиз таркала. Аттиланың уллары Эрнак/Эллак? (яки Ирник?, Р.Әхмәтьянов бу исемнең мәгънәсе «баш бармактай егет булса кирәк» дип исәпли) белән Диңгез (Динцик) арасында бердәмлек булмый, нәтиҗәдә баш күтәргән кабиләләр белән көрәштә Эрнак үтерелә, кече туганнары исә Кара диңгез буена качып китәләр. Диңгез Римга каршы сугышырга җыена, ләкин уңышка ирешми, Рим җиһангиры Анагист, аның башын кисеп, Константинопольгә китерә.

АХАК — Асылташның бер төре, яшерен кристаллы, төрле төстәге катламнары еш кына туры сызык һәм концентрик урнашкан кварцтан гыйбарәт каты гына минерал. Бу ярым затлы таш татар бизәнгечләрендә күп кулланылган. Ахактан муенсалар, түш бизәнгечләре, йөзек һәм алка кашлары, мөһерләр ясыйлар. Русчасы — *агат.* Аны *кара гәрәбә* дип тә атаганнар булса кирәк. Бируни заманнарында аны ташка әйләнгән нефть дип уйлаганнар.

//Ак япмаларга төргәнсең, Ахак идемме, әнкәем? Ахак кебек лә сатып бирдең, Артык идемме, әткәем? Халык җыры.

Төш юрау китапларында әгәр төшеңә ахак керсә, эшеңдә кечерәк кенә уңышка ирешерсең, дигән аңлатма очрый, ягъни бу ташның кыйммәте чамалы булуы тәгъбирдә дә чагыла.

АХЫРЗАМАН — заман ахыры, ахири заман. Фани дөньядагы вакытлы тормышның Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән бетерелүе.

Сөнни инанулар мәҗмугасы «Гакаид ән-Нәсафи» (XII гасыр) буенча ахырзаман сәгате җитү билгеләре: Дәҗҗал чыгу, җир астыннан тел белә торган ниндидер бер җанвар чыгу, җир өстендә төтен баганалары пәйда булу, көнчыгыштан Йәэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ килү, Гайсә пәйгамбәрнең кайтуы, Кояшның көнбатыштан чыгуы, бер-бер артлы Кояш һәм Айның өч тапкыр — башта көнбатышта, аннары көнчыгышта һәм ахырда Гарәбстан ярымутравында тотылуы (Айның ярылуы), Йәмәндә коточкыч ут чыгу. Пәйгамбәрнең күренекле сәхабәләреннән Хозәйфа ибне әл-Йәмәни Рәсүлуллаһның шушы ун вакыйга булмый торып, соңгы сәгать сукмаячак, дигән сүзләрен хәтерлик.

Гайсә пәйгамбәр белән Мәһди Дәҗҗални җиңәчәкләр дә җирдә гаделлек урнашачак. Кайбер риваятьләргә караганда, Гайсә пәйгамбәр җир йөзендә тагын 45 (яки 40) ел яшәячәк, өйләнәчәк, аның балалары да булачак, имеш. Бу заманда җир йөзендә мәхәббәт һәм сәгадәт хакимлек итәчәк; «бәрәннәрне бүреләр белән бергә күрәчәкләр, бала-чага еланнар белән уйнаячак». Вафатыннан соң Гайсәне Мөхәммәд Пәйгамбәр кабере белән янәшә җирләячәкләр һәм, вакыты җиткәч, алар икесе дә тереләчәк икән.

Сәгате җиткәч, кыямәт көне — хисап көне, йаум әд-дин (хөкем көне), тиргәү көне булачак. Исрафил фәрештә сурын өрәчәк тә, йолдызлар күктән коелып төшәчәк, диңгезләр ташый башлаячак, таулар урыннарыннан кузгалачак һәм барча адәмнәр үлеп бетәчәк. Кайбер суфи авторлар язганча, Газраил фәрештә беренче нәүбәттә Иблиснең җанын алачак икән. Ахырда ул Аллаһ әмере белән Исрафил, Микяил, Җәбраил һәм гарше-көрсине тотып торучы фәрештәләрне дә һәлак итә һәм иң соңыннан, әлбәттә, Аллаһ әмере белән, үзенең җанын үзе алачак, имеш.

Вакытлар узып, дәвернең ахыры ирешкәч, Аллаһы Тәгалә Исрафил, Микяил, Җәбраил һәм Газраил фәрештәләрне кабат тергезәчәк. Исрафил фәрештә сурны икенче кат өргәч, кайчан да булса җир йөзендә яшәгән барча халык терелеп, бер җиргә (әлмәхшәр) җыелачак. Алар бик озак Аллаһ хозурында басып торачаклар. Аллаһы Тәгалә алардан сөаль алачак, фәрештәләр адәмнәрнең яхшы вә яман

Питер Брейгель. «Ахырзаман». 1338 ел

эшләре язылган китапларны алып киләчәкләр. Шуннан соң аларның барлык эшләре әл-мәвазин дигән үлчәүдә үлчәнәчәк.

Мөхәммәд Пәйгамбәр кешеләрне зур сулык — әл-Һауд янында каршы алачак һәм гөнаһлары аз булган кайбер мөэминнәрне яклап, Аллаһтан шәфәгать сораячак. Шуңа күрә кайбер гөнаһкярлар өчен җәһәннәм мәңгелек булмаска да мөмкин, ә кайберәүләргә, оҗмахка кергәнче, озак кына аның капусы янында көтеп торырга туры киләчәк.

«Ахири заманның кайвакыт булачагы Аллаһы Тәгаләдән башка һичкемгә мәгълүм түгелдер».

«Әнәс әйтте: «Ант итәмен, сезгә миннән башка берәү дә сөйли алмаячак хәдисне җиткерәм. Мин Рәсүлуллаһның (с.г.в.): «Кабердән кубарылып тору сәгате җитүнең билгеләреннән берсе гыйлем ияләренең кимүе, ә наданлык белән азгынлыкның җәелүе булыр, хатын-кызлар саны артыр, ә ир-атлар саны кимер, чөнки илле хатынга аларны яклардык бер ир кеше туры килә башлар», — дигән сүзләрен ишеттем». (Бохари буенча.)

Тәфсирчеләр «Мөхәммәд» сүрәсенең 18 нче аяте Кыямәт көне турында, дип уйлыйлар. Мәс., «Тәфсир Ногмани»да Кыямәтнең якын булуы турында сөйләүче галәмәтләр инде килде, диелә. «Коръән»нең Аллаһтан иңгән китапларның соңгысы һәм Мөхәммәд галәйһиссәламнең ахыргы пәйгамбәр булуы бу галәмәтләрнең иң көчлеләре дип күрсәтелә. Сәлман хәзрәт тәрҗемәсендә Кыямәт көненең шартларыннан «иң беуге — Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлеге, айның ярылуы, Йәмән җиреннән төтен бәреп чыгу», дигән искәрмә бирелә. Мәүлана Мөхәммәд Али исә бу аятьтә ахырзаман турында кисәтү бар, дип исәпләми.

«АХЫРЗАМАН КИТАБЫ» — ахырзаман һәм кыямәт көне сурәтләнгән, көйләп укыла торган татарча китап. Мөәллифе (төзүчесе) Сөләйман Бакыргани, дип фараз ителә. Бу китап XIX гасырда һәм XX гасыр башларында халык арасында киң таралыш алган була. Халык арасында аны «Тәкый гаҗәб китабы» дип тә йөрткәннәр (монда «тәкый» сүзе

«тагы» мәгънәсендә). «Ахырзаман китабы»нда дөнья бетүнең төгәл вакыты күрсәтелгән. Бу хакта башкорт галиме Әхнәф Харисов түбәндәгеләрне яза: «Нәкъ 900 ел дигәндә Гайсә җиргә төшәр, Дәҗҗал үтерелер, ә Исрафил дөньяның бетүен белдереп, быргысын кычкыртыр, диелгән; моннан соң 15 ел үткәч, кара туфракны кызыл балчыкка тикле ашап бетереп баручы Йәәҗүҗ чыгар, Гайсә белән Мәһди Тур тавына ашар, Коръән күккә күтәрелер (Коръәндәге бөтен хәрефләр һәм сүзләр очып, аннан ак кәгазь генә торып калыр), диелгән». «Димәк, — дип дәвам итә автор, — «Ахырзаман китабы»ндагы исәпкә караганда, ягъни Мөхәммәт үлгән 632 елга 900 ел өстәп алганда, җир йөзендә тормыш 1532 елда ук (яки дөнья «яратылуына» 7040 ел дигәндә) бетәргә тиеш булган».

Христианлыкта Яңа Гаһеднамәнең (Инҗилнең) Иоанн Богословка нисбәт ителә торган бер китабы да (68 ел урталары-69 елның башы) ахырзаман турындагы мистик хәбәрләрдән тора. Аны Апокалипсис дип атыйлар.

XIX гасыр азагында Казан миссионеры Е.А.Малов «Ахырзаман китабы»ндагы Дәҗҗал, Мәһди, Йәәҗүҗ-Мәәҗүҗ, Исрафил, Газраил кебек персонажларның Ислам тәгълиматы белән турыдан-туры бәйләнеше булмавы, йәһүд һәм нәсари диннәреннән алынган булуы турында язып чыга (1897). Ләкин төптә хакыйкать шунда: «Ахырзаман китабы»нда библияви мотивлар чагылыш тапкан икән, бу әле китапның күчереп язылган (плагиат, сарика) булуы турында сөйләми, чөнки урта гасырларда күп кенә мотивлар һәм риваятьләр гарәпләр, яһүдләр һәм беренче христианнар өчен уртак булган.

Ахырзаман турында чыгарылган түбәндәге мөнәҗәт һәр заманда актуаль яңгыраган ахры:

Суфиларның наданы галим
булган заманы,
Гавәмнән битәр азганы,
заман ахры булгандыр.

Көчлеләре көч кыйлмак,
«изгеләре» үч булмак,
Биләр хәрәм мал җыймак,
заман ахры булгандыр.

Күр, заманның түрәсен,
нигә алар күбәү соң?
Сырган калҗа тирәсен,
заман ахры булгандыр.

Хур тотарлар галимне,
зур тотарлар залимне,
Саклагыл, Хак, хәлемне,
заман ахры булгандыр.

Нидер булды яраннар,
явызланды адәмнәр,
Фәкыйрьгә күп зыяннар,
заман ахры булгандыр.

Яки менә дастаннан:
Заман ахыр булганда
Ата телен ул алмас,
Ана телен кыз алмас;
Байның телен ярлы алмас,
Ханның телен кара алмас;
Әйтә белеп кайтаем,
Үле телен тере алмас;
Кардәштән чыккан яхшыны
Үз агаең күрәлмәс.
Заман ахыры билгесе —
Бергә туган туганың
Тату да булып торалмас.

Хәзерге вакытта дини футурология кешелек цилизациясенең вакыт ягыннан чикләнгән булуын киләчәктәге экологик һәм демографик һәлакәтләр белән бәйләргә тырыша.

«Ахырзаман» («ахири заман») сүзен рус теленә «конец света» дип тәрҗемә итәләр, ләкин аның төп-төгәл тәрҗемәсе — «последние времена». ■

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның октябрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Тәшәккер[1]

Мамадыш өязе Кәчимир карьясенең[2] могтәбәр сәүдәгәрләреннән Мөхәммәдҗан хаҗи Җаббаров кызы Рабигә ханым илә Малмыж сәүдәгәрләреннән Мөхәммәдҗан әфәнде Рәфиков араларында булган гакыйд мәҗлесендә[3] җәмгъ ителгән [җыелган] 50 сум 55 тиен акча «Кояш» идарәсе васитасы [арадашлыгы] илә Казан җәмгыяте хәйрияи исламия идарәсенә иреште. Мондаен нәмунә [үрнәк] булырлык изге эшләре өчен һәр ике яшькә җәмгыяте хәйрия идарәсе тарафыннан самими тәшәккерләр гарыз ителәдер. Хәзинәдар [казначы] — Нургазиз Хөсәенов.

Гаскәри балаларына

Балалар үлеменә каршы көрәш җәмгыяте гаскәргә алынганнарның балалары өчен ашханә ачарга карар биргән. Некрасов читальнясында балалар исемнәрен кабул итү өчен язу башланган инде.

Вагоннан куркып

Усия[4] дамбасы буйлап Гаффар Садыйков дигән кеше бер йөк утын алып бара икән. Кинәттән килеп чыккан 108 нче номерлы трамвай вагонын күргән ат, сискәнеп сикереп китеп, вагон юлына аркылы килгән. Вагон арбага килеп бәрелгәч, ат тагын да бигрәк куркып сирпелеп киткән дә, дамба кырына тартып алып, йөкне Казанка кырыена актарып җибәргән. Утын таралган, арба ватылган, тәртәләр сынгалап беткән, ат берничә мәртәбә әйләнеп имгәнгән. Бәхетенә каршы, иясе сәламәт калган.

Кояш. — 1914. — №530. — 9 октябрь.

Электр бозган

Балык базарында[5], вагон юллары кушылган турыда, вагон юлы астыннан үтә торган водопровод трубасы адашкан электр куәсе сәбәпле ватылган. Балык базарын бөтенләй су баскан. Воскресенская[6], 2 нче Гора[7] һәм Круговая юллар трамвайлары бу тугрыдан үтә алмыйлар. Моннан үткән труба Иске вә Яңа бистәләргә су бирә торган баш юл булганлыктан, бу трубаны төзәтү өчен суы туктатылганлыктан, мөселман бистәләре бөтенләй сусыз калды.

Кояш. — 1914. — №531. — 11 октябрь.

* Даталар иске стиль белән бирелә.
[1] Тәшәккер — яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.
[2] Кәчимир карьясе — хәзерге Кукмара районының Оштырма суы буендагы авыл.
[3] Гакыйд мәҗлесе — килешү, бу очракта никах мәҗлесе.
[4] Усия — Казансу елгасы тамагындагы Дальнее Устье пристане.
[5] Балык базары хәзерге Тукай мәйданында булган.
[6] Воскресенская — хәзерге Кремль урамы.
[7] 2 нче Гора — хәзерге Волков урамы.

***

Фуксовская урамында акчадан карта уйнап тотылган дүрт татарның һәрберсенә 50шәр сум штраф салынган.

Кояш. — 1914. — №532. — 12 октябрь.

Мөселман табиблар

Табиб Әбүбәкер әфәнде Терегулов[8] Казан клиникасының эчке авырулар шөгъбәсенә (иске клиникада) ординатор итеп кабул ителгән иде. Әбүбәкер әфәнде инде үзенең әүвәлге квартирасыннан клиникадагы казённый квартирага күчте. Хосусый баручы авыруларны үзенең иске клиникасындагы квартирасында сәгать биштән соң кабул итәдер.

Моңа кадәр җәмгыяте хәйрия амбулаториясендә авырулар кабул итеп килгән Маһипәрвәз ханым Дәүләткилдиева[9], хосусый шөгыльләре күбәю сәбәпле, ул эшеннән истигъфа иткән [чыккан]. Моннан соң аның урынына Суфия ханым Агиева[10] авыруларны кабул итәчәктер.

Кояш. — 1914. — №535. — 15 октябрь.

Казан мөселманнарының сәдакать [тугрылык] телеграмы

Кичә 20 октябрьдә падишаһ хәзрәтләренең тәхеткә утыруына егерме ел тулу мөнәсәбәте илә шәһәрнең һәр мәсҗедендә падишаһ әгъзәм хәзрәтләренә вә гаиләи мөхтәрәмәләренә сыйххәт вә гафиять [сәламәтлек] һәм гаскәрләренә галәбә [җиңү] теләп, догалар кылынды.

Янә бөтен мәхәлләләрнең әһалисенең арзулары мөҗибенчә[11], голәмә вә мәхәллә вәкилләренең имзасы илә падишаһ әгъзам хәзрәтләренә гарыз сәдакать телеграмы бирелде.

Бәйрәм

Үткән рамазан бәйрәме алдыннан башланган сугыш рамазан бәйрәменең шатлыгын байтак киметкән булса да, төрле урындагы гаскәрләребезнең галәбәсе хәбәре килеп торуы күңелләргә төс биргән вә, бигрәк тә бәйрәм алдында гына, Варшава якынындагы галәбәбез[12] гомумнең рухын күтәргән вә шатландырган иде. Шунлыктан, Казан әһалисе бу бәйрәмне кыш алды вә гомумән кайгылы көннәргә тугры килгәнгә карамастан, яхшы ук күңелле үтәр дип көткән иде. Бәйрәм житте. Гает укылды. Үткәннәр, ата-баба вә карендәшләр рухларына Коръән укылды, корбаннар кылынды. Бәйрәм башланды... Телеграм Төркия флотының Кара диңгез буендагы бәгъзе шәһәрләребезгә аткан хәбәрен китерде. Бу хәбәр мөселман җәмәгасен кызу-кызу мөзакәрәләрдә [фикер алышуларда] булынырга, дөрес хәбәр булуы белән булмавы арасында тәрәддедтә [икеләнүдә] калырга, моның хәле хакында баш авырттырырга мәҗбүр итте. Бәйрәмнең беренче көне фәкать шул хәбәрнең әсаслеме [нигезлеме], түгелме икәнен белергә тырышу белән үтте. Бәйрәмнең икенче вә өченче көннәрендә табигать тарафыннан җибәрелгән

---

[8] Терегулов Әбүбәкер Батыргәрәй улы (1885-1966) — терапевт, мед.фәннәре докторы.
[9] Маһипәрвәз Дәүләткилдиева — врач, К.Тинчуринның хатыны Заһидә Тинчуринаның апасы.
[10] Суфия Агиева — табибә, күренекле язучы Гафур Коләхмәтовның сеңлесе, мәгърифәтче, «Ак юл» журналының баш мөхәррире Фәхрелислам Агиевның хатыны.
[11] Арзулары мөҗибенчә — теләкләренә җавап буларак.
[12] Варшава якынындагы галәбәбез — 14 (27) октябрьдә Варшава-Ивангород операциясе вакытында немец армиясе чигенә башлый.

кар вә туфрак катыш буран өргән каты суык җил исте. Шулай итеп, бу бәйрәм мөселан җәмәгасе өчен байтак кызыксыз вә күңелсез булды.

Икенче яктан, бәйрәмнең исерткечсез, аек хәлдә үтүе шатлыклы галәмәтләрдән булды. Ходай боерсын да, киләсе бәйрәмнәребез дә шундый аек булсын вә хәтәрсез заманнарга тугры килсен.

q Асаре гатика [археологик истәлекләр]

19ында университетның асаре гатика шөгъбәсендә асаре гатика җәмгыятенең эшләгән эшләре хакында хисап бирү мәҗлесе булды. Бу хисапта баштанаяк диярлек Болгар хәрәбәләре вә Болгар урынынннан асаре гатика эзләү өчен казынулар вә табылган асар хакында тәфсыйлат [җентекле аңлатма] бирелде. Казынулар фотограф белән төшерелгән булып, кинематографтагыча экранда күрсәтелде. Табылган әсәрләр җәмгыять залына куелганнар һәм экранда рәсемнәре күргәзелделәр. Табылган әйберләр арасында дикъкать итәрлек күп нәрсәләр бардыр. Выставкасы бу көндә 12дән 3кә кадәр ачыктыр.

Кояш. — 1914. — №537. — 22 октябрь.

r Кардәшлек көне

Беренче ноябрьдә падишаһ әгъзәм хәзрәтләренең тәхте химаясендәге «Сугышта зарарланганнарга вә аларның гаиләләренә һәрбер урында ярдәм бирү» җәмгыяте тарафыннан «Кардәшлек» көне ясалачактыр. Бу көн ак чәчәк вә флаг көннәре кебек, флаг вә Русиянең дәүләт гербының рәсемен сату илә иганә җыюдан гыйбарәт булып, җыелган иганәнең яртысы Казан губернасыннан киткән солдатларга вә аларның гаиләләренә булачак, яртысы исә сугыш корбаны булган белгиялеләр файдасына булачактыр.

Бу көндә флаг сатып йөрергә теләгән туташ вә әфәнделәр 15 нче районның мөдирәсе Гайшә ханым Терегуловага[13] (Ново-Горшечная[14] урамында Сокольский йортта), 16-17 нче районнарның мөдирәсе Лидия Гермогенова ханымга (Братья Крестовниковларның заводында, училищеда), 18нче район мөдире Кәшшаф хәзрәт Тәрҗемановка[15] (Малая Симбирская[16] урамында, үз йортында, Яңа Бистәдә) мөрәҗәгать итеп языла алачаклардыр.

q Садри әфәнде Максуди – адвокат

Садри әфәнде Максуди гаделия нәзарәте [юстиция министрлыгы] тарафыннан антлы дәгъвә вәкиле могавинлегенә [ярдәмчесенә] тасдыйк ителде [расланды]. Садрый әфәнденең әүвәлдә бер мәртәбә гаделия нәзарәте тарафыннан тасдыйк ителмәгәнлеге газитәләрдә вакытында язылган иде, икенче мәртәбә мөрәҗәгате матлуб [көтелгән] нәтиҗәне биргән.

r Вәлиев хөкеме

17 нче октябрьдә Судебная палатада Тәтеш өязе Малый Яльчик авылы волостной старшинасы Вәлиевкә хөкем булды. Хөкем вакытында, үткән ел Яльчик волостное правлениедә Вәлиев шунда кунган хәлдә янгын булганы, правлениедә халык акчасы саклана торган сандыкта акча булырга

[13] Гайшә Терегулова (1868-1940) — тәрҗемәче, концерт-кичәләр оештыручы.
[14] Ново-Горшечная — хәзерге Бутлеров урамы.
[15] Кәшшаф Тәрҗемани (1877-1943) — дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин галиме, мөдәррис.
[16] Малая Симбирская — хәзерге Мәҗит Гафури урамы.

тиеш булганы хәлдә, халык тарафыннан уттан азат ителгәч, акчасыз хәлдә булганы, көйгән кәгазьләр арасында кәгазь акча кисәге вә нә дә алтын вә көмеш акча әсәре булмау, Вәлиевнең янгын алдыннан «Сандыктагы акча янып бетәме?» диеп сорашканы исбат ителә. Судебная палата Вәлиевне бөтен хокукыннан мәхрүм итеп, 8 елга каторга җибәрергә хөкем кылды.

***

22 октябрьгә каршы төндә Осланга йөри торган перевоз Идел уртасында туңып калган. Шушы перевозны читкә чыгару өчен икенче көн инде боз ватып маташалар.

***

Малая Красная урамында Степанов йорты яныннан ташландык 3 көнлек ир бала, Чехов урамында Чималин йорты яныннан кыз бала, Ново-Горшичнаядан Бодрин йоры яныннан ике атналык бер ир бала табылган.

Кояш. — 1914. — №538. — 23 октябрь.

Бүреләр һөҗүм итә

Кыш җитеп, халык шәһәргә җыелу белән шәһәрнең якын-тирәләре иркен калган. Шушы иркенлектән файдаланып булырга кирәк, шәһәребезгә бүреләр һөҗүм итә башлаган: Казанкада салларда хезмәт итүчеләр Игумный урманыннан[17] бүреләр килгәнен күреп, тавыш күтәргәннәр. Полиция килеп җиткән. Халык күбәйгән. Бүреләр моны күреп кайтып киткәннәр. Шул ук көндә төнлә белән Усиядә Громов йортында йорт хуҗасының этен бүреп буып киткән.

Урамга су түккән өчен

Вознесенская урамындагы[18] Хәмидуллинның йомырка подвалыннан урамга су (качать итеп) түккән өчен Җәләлетдин Низаметдинов һәм Шәриф Хафизов дигән эшчеләр тотылып, полициягә алынганнар. Урамны шакшылаганлыклары өчен җавапка тартылалар.

Кояш. — 1914. — №543. — 29 октябрь.

Мөселман хатын-кызлары вә сугыш

Бу көннәрдә Фатиха ханым Аитова[19] мәҗрух гаскәриләр файдасына түбәндәге иганәләрне тапшырган. Казанның окружной попечителенә: 10 данә халат, 50 данә күлмәк, 12 данә простыня. Петроградта директор департамента народного просвещения А.В.Виловка: 40 данә күлмәк; 10 данә халат, 8 ящик сохари (һәр ящикта яхшы оннан хәзерләнгән 15 кадак[20] сохари). Фатиха ханым Аитованың мәктәбендә укый торган кыз балалардан Казан губернасы баш мәэмүре [губернаторы] Боярский җәнабләренә 120 данә вак капчыклар тапшырылган. Һәр капчыкка бер кадак шикәр, әчмүхә[21] чәй, ярты кадак сабын, бер тартма папирус, бер кәгазь энә, бер кәтүк җеп куелган.

Кояш. — 1914. — №545. — 31 октябрь. ■

[17] Игумный урманы — Казансуның уңъяк ярындагы Зур һәм Кече Игумный бистәләре артындагы урман.
[18] Вознесенская урам — хәзерге Островский урамы.
[19] Аитова Фатиха Габделвәли кызы (1866-1942) — иганәче, җәмәгать эшлеклесе. 1897 елда Казанда кыз балалар өчен мәктәп оештыра.
[20] Кадак — 409,5 гр.га тигез булган авырлык үлчәве.
[21] Әчмуха — кадакның сигездән бер өлеше, 50 грамм.

КӨЛКЕ КУА КИЛӘ...

Габделҗаббар КАНДАЛЫЙ (1797-1860)

КӘҖӘ

Һәр кәҗәнең ике исме булыр, имеш:
Бере кәҗә, бере каза булыр, имеш;
Ул кәҗәне ярлы кеше асрар, имеш,
Сыер урынына сөтен савып эчәр имди.

Игътибар юк ул кәҗәнең гакылына,
Инабәт юк ул кәҗәнең сакалына,
Кая барсаң, шунда аны гайбәт кыйлгыл —
Язык булмас, бәлки, сәвап булыр имди.

Салып йөрер сыртына ул койрыгыны,
Һич тыңламас ул хуҗаның бойрыгыны,
Ашлыкның эзләп йөрер куерагыны,
Һәр ашлыкның башын кыркып йөрер имди.

Ул кәҗәнең караклыгы иртә белән,
Җиңеп булмый ансын асла киртә белән;
Үгет алмый колагына киертү белән,
Кеше күрсә, кире чигенеп сикерер имди.

Ул кәҗәнең аерыладыр тояклары.
Бакча эчендә гизәр аның аяклары,
Калмас андан кәбестә, суган кыяклары,
Һәркайсының башын кыркып йөрер имди.

Алмагачның кимерәдер ул кабыгыны,
Гел сайлыйдыр яшь яфраклы аныгыны.
Һич сөймидер рәнҗегәнне, арыгыны,
Агачларның бәпкәләрен чүпләр имди.

Ялтырыйдыр үткен күзләре ут кебек,
Мөгезе сыйса, үзе дә кичәр ук кебек,
Хуҗа килсә, уйлар бернәрсә юк кебек,
Әллә кайчан бакчадан тыш булыр имди.

Аны күреп, бакча иясе чабар ботын,
Сугыйм дисә, күрсәтер ул аңа сыртын,
Ләгънәт укыр бакчачы ушал көнен,
Каргыш төшеп, җабагасын кояр имди.

Йөрер үзе киртәнең буе белән,
Ашлыкка керүнең уе белән,
Ялгыз йөрмәс, ул йөрер туе белән,
Чүмәләне үрә торып ашар имди.

И яраннар, ул кәҗәне асрамагыз,
Асрасагыз, ачык-тишек калдырмагыз!
Ат алдыннан солыгызны алдырмагыз!
Солы күрсә, җанын фида кылыр имди.

Бәгъзесе ятыр аның печәнлектә,
Бәгъзесе ятыр аның начальникта,
Караклыкны үгрәнер ул кечеклектә.
Акча биреп, иясе түләп алыр имди.

Ул кәҗәнең тәкәсе мөрәүвәтле,
Үзе чиркин сыйфатлы, кабих затлы,
Суйсаң, аның тиресе бик кыйммәтле,
Читек тексәң, биш елга чыдар имди.

Дәхи мирза диерләр тәкәсенә.
Мәхәббәтле басып торыр һәммәсе дә,
Түрәмен дир куй сарыкның барчасына,
Аларны кырдан башлап кайтыр имди.

Төшкән чакта көтү күлгә су эчәргә,
Алдан китәр ышыкка тизрәк күчәргә,
Ирек бирмәс кешеләргә юл кичәргә,
Читән буена тезелешеп ятар имди.

....

М.ӘПКӘЛИ
(Фаил Шәфигуллин, 1939-1982)

Өлкән бүренең фаҗигале язмышы
Гыйльми трактат

Без үзебезнең бер фәнни хезмәтебезне Г.Тукайның «Кәҗә белән сарык» әсәрендәге ботка проблемасын күтәрүгә һәм бүреләр казанында нинди ботка пешүен ачыклауга багышлаган идек. Инде, ниһаять, өлкән бүре проблемасы көн тәртибенә килеп басты. Бу аңлашыла да. Чөнки шагыйрь моннан ничәмә-ничә дистә еллар элек, ягъни урман-кырлар төрле ерткыч-җанварлар, албастылар белән мыжлап торган чагында ук бүреләр язмышы белән кызыксынган икән, бүген, табигатьне, шул исәптән бүреләрне саклау проблемасы көн кадагында торганда, без һич кенә дә бу мәсьәләгә битараф карый алмыйбыз.

«Кәҗә белән сарык» әкиятендә өлкән бүре беренче тапкыр 73 нче юлда телгә алына. 19 нче строфада да шул ук өлкән бүре башлык дип искәртеп кителә. Димәк, бу бүре, һичшиксез, көтүнең башында йөргән булырга тиеш. Димәк, ул рядовой бүре кебек бернинди хәбәр-хәтәрсез югалырга да тиеш түгел.

Иң элек безгә ике сорауны ачыклап китү тиештер. Өлкән бүре сарык белән кәҗәдән куркып киткәнме, әллә булмаса чынлап та боткага су кирәк булганмы? Минемчә, бу сорауларның берсенә генә уңай җавап биреп була. Өлкән бүре сарык белән кәҗәдән куркып китмәгән. Ни өчен дигәндә, яшь бүреләр тыныч кына учак янында утырып кала. Югыйсә, бүре халкы бик сизгер бит ул. Аз гына куркыныч янаганын сизде исә, көтүе белән сыпырту ягын карый. Аучылар җәмгыятендә инде бу аксиома итеп кабул кылынган.

Шулай булгач, өлкән бүре боткага су алырга киткән булып чыга. Монысы инде бик яхшы аңлашыла. Чөнки кәҗә белән сарык, ни әйтсәң дә, бүреләр табынына кунак булып килделәр бит. Кунаклар алдында оятка калмасын өчен өлкән бүре ботканы тәмлерәк итеп пешерергә тырыша. Аннан соң өлкән бүренең, барлык эшләрне дә яшь бүреләрдән эшләттерә икән бу, дип уйламасын әле кунаклар дип, фикер йөртүе ихтимал. Һәрхәлдә, өлкән бүренең су алырга китүе бәхәссез.

Ә менә ни өчен ул су алырга киткән җиреннән әйләнеп кайтмаган? Монысы — икенче мәсьәлә. Әлбәттә, төрлечә гомән кылырга мөмкин:

1. Өлкән бүре бәхетсезлеккә дучар булган (аучы, җәдрә).

2. Юлда буран чыгып, адашкан.

3. Төлкегә очрап, бер-бер мәкер корбаны булган.

Хәзер инде берәм-берәм бу версияләрне йә кабул итик, йә кире кагыйк:

1. Кәҗә белән сарык та, яшь бүреләр дә мылтык аткан тавыш ишетмәде.

2. Бүре нинди генә дуамал бураннарда да адашмый.

Димәк, беренче ике версияне кире кагып, өченчесен кабул итәбез. Бүрегә юлда төлке очрый. Юл уртасында җәелеп яткан да балык кимерә. Исәнлек-саулык сорашалар болар. Өлкән бүрегә су кирәк бит инде. Сүз арасында гына төлкедән су юлын сорый бу. Төлке өйрәтеп бирә. Шулай, шулай, авыл читендә бәке бар, бәкедә — су, суда балык бар. Ул койрыгыңны тыгып утырасың да берьюлы чиләк ярым су, пот ярым балык тартып чыгарасың, ди. Бүрегә балык чуртымамыни, аңа су булса, җиткән.

Бүре бәке читенә барып, койрыгын суга тыга. Бераздан тикшереп карый. Су бик аз эләккән койрыкка. Кәҗә белән сарык алдында оятка калырмын, су күбрәк җыелсын дип, койрыгын тагын суга батыра бу. Шул килеш таң беленеп, авыл хатыннары суга төшә башлаганчы утыра. Торып качарга уйлый да соңыннан, ләкин койрыгы бозга катып өлгергән була. Ары талпына өлкән бүре, кире талпына. Әмма файдасыз. Әкият түгел бу сиңа — койрыкны өзеп качып булмый. Этләр өреп чыга, сәнәк күтәреп бер агай килә...

Шулай итеп, кәҗә белән сарыкның итагатьсезлеге аркасында өлкән бүренең язмышы фаҗигале рәвештә тәмамлана.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан, 1980 ел.)

....

Фәрит Вахитов шаржы

Шәүкәт ГАЛИЕВ
(1928 – 2011)

РИФМА

Урман күрде Шәвәли,
Эчкә керде Шәвәли.
— Әйт әле, — ди дәү әни,
Агачларга ни булган?
Ботакларга ни сарган?
— Бөреләр, — ди дәү әни,
— Бүреләр, — ди Шәвәли.
— Бө-ре-ләр, —ди дәү әни,
— Шү-ре-ләр, — ди Шәвәли.
Ачулана дәү әни:
— Сүзне бозма, Шәвәли!
— Ачуланма, дәү әни...
Рифма эзли Шәвәли. ■

Мирасворд

Гарәп язуы төре

Ашлык, он саклау әрҗәсе

... Бәйрә-мова

Тарих-чы ... Хуҗин

Ял иту өчен тук-талыш (бор.)

Ярыш, көндәш-лек (иск.)

«... вә Димнә»

Кабо - ... (Африка иле)

... Дару (иск.)

Гарәп хәрефе

Ике ишкәкле кечкенә көймә

Язучы ... Зәйнул-лин

... Юзиев

... - том

1906-1907 елларда Оренбургта чыккан сатирик журнал

Гарәп язмаларында Көнчыгыш славян кабиләләре атамасы

Актриса ... Найтли

Амудәрья-ның борынгы исеме

«Туган ...» (Г.Тукай)

«Яма-шев» трилогия-сенең авторы

Аллага якын, изге кеше (иск.)

... Бикчән-таева

Урта гасыр болгар шәһәре

Кытай (иск.)

Актер ... Норрис

Теркәгеч

Как-шамас, чыдам

... карлы-гачы

Рус рәссамы

Көч, куәт

Ачык, билгеле (иск.)

Камыштан ясалган үзбәк курае

Урта гасырда яшәгән төрки тел-ле халык

1991-1995 елларда Казанда чыккан газета

... мәйданы

Ирекле, азат

... чәчәк

Өлкән кыз туган



Элекке ад-министра-тив-тер-риториаль берәмлек

... - сызу

Совет ис-требителе

Борынгы «ком-байн»

Рәис Габдулла төзеде.

9 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Котб, «Аң», «Асар», торф, болдыр, Әюп, Мар, Ирек, ода, Ама, Айя, па, хәер, Күлтәси, елу, аем, Наил, КФУ, Чокрый, төк, Мина, күфи, Һәнүз, бат, Вәли.

Өстән аска: Фәезханов, мән, По, Иктин, «Шахта», дарелфөнүн, май, указ, арба, якут, Оксфорд, Плано, Баруди, Әте, ыра, Әмир, үтә, Рем, фал, Кари, «Айбиби».

Борнай мәчете. XX гасыр башы.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / ОКТЯБРЬ

● 785 ел элек (1229)

Каракорымда (Жучи Олысының башкаласы) корылтай җыела. Олысның бөек ханы итеп Чыңгызханның өченче улы Үгәдәйне (1186-1241) сайлап куялар.

● 220 ел элек (1794)

Шагыйрь, дин эшлеклесе Һибәтулла Салихов (1794-1867) дөньяга килә.

● 190 ел элек (1824)

Татар теле галиме, мәгърифәтче, каллиграф-хаттат, тәрҗемәче, китап миниатюрасы остасы Мөхәммәтгали Мәхмүдов (1824-1891) дөньяга килә.

● 140 ел элек (1874)

24 октябрьдә Казанда беренче суүткәргеч эшли башлый.

● 120 ел элек (1894)

3 октябрьдә күренекле шагыйрь Сәйфи Кудаш (1894-1993) дөньяга килә.

● 110 ел элек (1904)

22 октябрьдә Казан елга техникумы ачыла.

● 95 ел элек (1919)

Оренбургта танылган артист һәм журналист Габдерахман Мангушев (1887-1919) вафат була.

● 80 ел элек (1934)

6 октябрьдә «Литературная газета»да Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасыннан «Похождения Карахмета» исеме белән өзек басылып чыга.

28 октябрьдә татар халык шагыйре Мәҗит Гафури (1880-1934) вафат була.

● 75 ел элек (1939)

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырыла.

● 70 ел элек (1944)

20-23 октябрьдә Татар дәүләт академия театрында Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» исемле комедиясе куела.

● 65 ел элек (1949)

Татарстан китап нәшриятында Ләбибә Ихсанованың «Җир астында җиде көн» исемле повесте китап булып басылып чыга.

● 50 ел элек (1964)

«Совет әдәбияты» журналында Нурихан Фәттахның «Бала күңеле далада» романы басыла башлый.

● 45 ел элек (1969)

В.И.Качалов исемендәге Казан дәүләт академия рус Зур драма театрында Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» комедиясе куела. Режиссёры — Шириаздан Сарымсаков.

ЭЛЬМИРА МОСТАФИНА

Көнчыгыш базары.
Кәгазь, темпера. 2010 ел

Эльмира Әмир кызы Мостафина 1977 елда Татарстанның Чистай шәһәрендә дөньяга килә. Казан сәнгать училищесын (1998), Санкт-Петербургтагы И.Е.Репин исемендәге рәсем сәнгате, сынчылык һәм архитектура институтын (2004) тәмамлый.

2005 елдан — Санкт-Петербургның Рәссамнар берлеге, Санкт-Петербург акварельчеләренең Император җәмгыяте әгъзасы. Аның иҗаты Татарстан Президентының, Мәскәү Мәдәният министрлыгының стипендияләре һәм бертуган Носкиннар (танылган коллекционерлар) исемендәге премия белән билгеләп үтелә.

Эльмира Мостафина шәһәр пейзажы, натюрморт, тарихны тасвирлау жанрларында иҗат итә. Аның әсәрләре Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Чикаго (АКШ) шәһәрләрендәге күргәзмәләргә куела, Россиянең шәхси һәм дәүләти тупланмаларында саклана.

Алтын көз.
Кәгазь, темпера. 2012 ел

«Болгар». Алтын, оргалит, майлы буяу. 2013 ел

ИНДЕКС:
Татарстанда – 54132
Чит төбәкләрдә – 70275

Тәртип
93.5 FM
халык радиосы
12+

Тәртип FM – үз илемдә үз көем!

«Халкыбызның җыр-моңнарына уралып эфирга тәртип килде...»
93.5 FM ешлыгы тәүге авазын шулай ирештерде... Әлеге буын яшәешенең аерылгысыз өлеше булса да, хәзерге буынның күбесенә инде исемнәре бөтенләй ят легендар җырчыларыбыз Усман Әлмиев, Фәхри Насретдинов, Рәшит Ваһапов, Җәвәһирә Сәлаховаларның үлемсез җырлары, гармун, курай моңнары FM ешлыгында да матур яңгырый икән ләбаса! Шагыйрь-шагыйрәләребезнең күңел энҗеләре – шигъри талгешләре дә
Айрат Арсланов авазларында, кабатланмас тавышлы Фәнис Җиһанша, Наил Дунаев, Фоат Галимуллин, Гөлчәчәк Хафизовалар укыганда йөрәкнең иң нечкә кылларын тибрәтә.
Зыялы шәхесләребез алып баруында «Тузмый торган бүләк», «Тел диган дәрья бар», «Безнең мирас» кебек тапшырулар халкыбызның бай мирасы, тарихы, гореф-гадәтләре, дине, мәдәнияте турында сөйли.
«Тәртипне» олысы да, кечесе да тыңлый. Ул позитив радио буларак тәртипкә, яхшы эшләр, изге гамәлләр кылырга, яшьләрне хәрәкәт итәргә чакыра.

4 612750 670172